«ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ»

# МӨХӘММӘДЬЯРНЫҢ «НУРЫ СОДУР» ӘСӘРЕ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2025

**УДК 930.2+821.512.145-1**
**ББК 63.212+84(2=632.3)-5**
**М 98**

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
*Раиф Мәрданов*

**М 98** Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2025. – 316 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 35 нче китап).

Китапта XVI гасыр татар шагыйре Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» әсәренең тулыландырылган һәм төзәтелгән тексты нәшер ителде. 2024 елда табылган тулы текстлы кульъязмасы бу басма өчен нигез итеп алынды.

Кереш мәкаләдә «Нуры содур»ның XVII–XIX гасырларга караган 17 кульъязма күчермәсе, әсәрнең басылып чыккан текстлары һ.б. турында тәфсилле мәгълүмат бирелде.

**ISBN 978-5-88473-111-0**

**УДК 930.2+821.512.145-1**
**ББК 63.212+84(2=632.3)-5**

© Мәрданов Р.Ф., 2025
© «Милли китап» нәшрияты, 2025

# «АТАМ – МӘХМҮД, ДОГАЧЫ – МӨХӘММӘДЬЯР»

Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән мәшһүр татар шагыйре Мөхәммәдьярның зур күләмле ике әсәре – «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмалары мәгълүм. Шагыйрьнең үзе һәм иҗаты турында галимнәр тарафыннан күп язылды, китаплар нәшер ителде, поэмалары мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә урын алды. 1541 елда иҗат ителгән «Нуры содур» поэмасы – татар әдәбиятының иң кыйммәтле җәүһәрләреннән.

«Нуры содур» поэмасының XVIII гасырга нисбәтле кулъязма күчермәсен 1940 елның җәендә Казан шәһәрендә табып, аны иң беренче өйрәнеп, авторын билгеләп, эчтәлеген шәрехләп язган кеше – әдип һәм галим Нәкый Исәнбәт (1899–1992) булган[1]. Аның шактый киң мәгълүматны эченә алган мәкаләсендә Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» болай тасвирланган: «Әсәр үзенең композицион төзелеше буенча шактый эзлекле һәм нык үзәкле. Моның белән автор үзенең көнчыгыш феодализм әдәбияты һәм аның мәшһүр әсәрләре белән таныш булып, аларның алымнары белән дә файдалана белүен күрсәтә. Чөнки Иран шагыйре Шәйхе Сәгъдинең «Гөлестан» һәм «Бостан»нарында, Низаминың һәм аңа ияреп язган Хәйдәрнең «Мәхзәнел-әсрар»ында һәм башкаларда без шундыйрак калып һәм алымнар куллануны күрәбез. Язучы мисалга китергән хикәяләрендә дә гомуми көнчыгышта таралган мотивларны файдаланган. Шулай булса да, башка-

---

[1] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры әдәбиятыннан Мөхәммәдъяр Мәхмүд углы әсәрләре // Совет әдәбияты. – 1941. – №4. – Б. 68–78.
Мөхәммәдьяр исеменең хәзерге алфавитта татарча язылышы 80 елдан артык

ларга ияру һәм күчерү юлын гына тотмаган, бәлки боларның һәммәсендә дә үзенчәлекләргә ия булган үзбашлы әсәр барлыкка китергән»[2]. Нәкый Исәнбәтнең әлеге мәкаләсен «Нуры содур» поэмасын киләчәктә киңрәк өйрәнү өчен программа рәвешендә дип атарга да мөмкин.

Борынгы татар әдәбияты белгече, галим Шакир Абилов (1915–2004) –Мөхәммәдьяр иҗатын 1950 нче еллар уртасыннан башлап дистә еллар буена тирәнтен өйрәнгән, китаплар һәм күпсанлы мәкаләләр бастырган, зур хөрмәткә ирешкән шәхес. Ул «XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьяр иҗаты» темасына 1960 елда филология фәннәре буенча кандидатлык диссертациясен яклаган[3]. «Шакир аганың гыйльми эшчәнлеге шактый бай һәм күпкырлы. Әмма аның үзәгендә, йөзек кашы кебек, Мөхәммәдьяр тора»[4], – дип бәяләде филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегулов. Ул Ш.Абиловның фәнни эшчәнлеген киң яктыртып, болай язды: «1997 елның августында ЮНЕСКО карары белән Татарстанда гына түгел, гомумән, татар дөньясында, Мөхәммәдьярның тууына (якын-

---

дәвам итеп килә. Бу исемнең ахырындагы «яр» өлешен аеру өчен калынлык яисә нечкәлек билгесе кую мәсьәләсендәге төрлелекне хәл итәргә кирәклеге турында галимнәр ярты гасыр чамасы элек үк әйткәннәр. Ләкин ул соңгы заманга хәтле төрлечә языла. Мәсәлән, татар телендәге энциклопедиядә «ъ» билгесе белән, ә русчасында «ь» белән бирелгән. Ике телдә чыккан кайбер басмаларда киресенчә – русчасы «ъ» белән, татарчасы «ь» белән. Бер үк телдәге китап яки мәкаләләрдә, ваемсызлык нәтиҗәсендә, ике төрле язылган очраклар да бар.

Без бу китапта, татар исемнәре белгече Гомәр Саттаров хезмәтендәгечә, «Мөхәммәдьяр» дип (Саттар-Мулилле Г. Татар исемнәре ни сөйли? Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге. – Казан: «Раннур» нәшр., 1998. – Б. 183) яздык. Шагыйрьнең 1997 һәм 2021 еллардагы китапларында, татар әдәбияты тарихы күптомлыкларының 1984, 2014 һәм 2022 еллардагы басмаларында да бу исем шулай ук язылган.

[2] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры әдәбиятыннан Мөхәммәдъяр... – 1941. – №4. – Б. 72.

[3] Абилов Ш. Творчество татарского поэта Мухаммедьяра (XVI в.) / КГУ. Автореф... канд дис. филол. наук. – Казань, 1960. – 16 с.

[4] Миңнегулов Х. Әдәбиятны өйрәнү юлында: фәнни һәм публицистик язмалар, чыгышлар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2018. – Б. 100.

ча) 500 ел тулу киң күләмдә билгеләп үтелде, төрле чаралар үткәрелде. Бөек шагыйрь юбилеен гыйльми әзерләүдә, иҗатын халыкка җиткерүдә башлап йөрүче һәм төп йөкне тартучы Шакир ага Абилов булды. Гомумән, ул гомеренең ахырына кадәр Мөхәммәдьярдан аерылмады. Бу мөхтәрәм галимнең күпьеллык эзләнүләре нәтиҗәсендә Мөхәммәдьяр киң катлауга яхшы таныш, аның әсәрләре антологияләргә, дәреслек-хрестоматияләргә кертелде»[5].

Әдәбият белгечләре белән берлектә, тел, тарих, фәлсәфә галимнәре дә шагыйрь Мөхәммәдьяр әсәрләренә мөрәҗәгать иттеләр. Мәсәлән, Вахит Хаков, Фазыл Фәсиев, Мәдинә Җәләлиева, Яхъя Абдуллин, Мәсгуд Гайнетдинов, Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтҗанов, Хатыйп Миңнегулов, Фәрит Яхин, Энҗе Кадыйрова һ.б. М.Җәләлиева хезмәтендә, башка әсәрләр белән бергә, Мөхәммәдьярның поэмалары да тикшерелгән[6]. М.Госманов әдипнең әсәрләрен ул иҗат иткән чорга бәйләнештә өйрәнгән. Галим Яхъя Абдуллин шагыйрьнең әсәрләрен анализлап, Мөхәммәдьярның фәлсәфи карашлары һәм гомумкешелек гуманизмы турындагы фикерләре белән уртаклашты[7]. Вахит Хаков Мөхәммәдьяр әсәрләренең теле турында: «Шагыйрь киң планда халык теленә нигезләнеп яза, үзенең поэмаларында тел байлыгыннан уңышлы файдалана. Ул, халык авыз иҗаты әсәрләренә таянып, художестволы-сурәтләү чараларын куллануга да зур игътибар итә. Мөхәммәдьяр җанлы һәм җансыз предметларны, табигать күренешләрен чагыштырып күрсәтә»[8], – дип язды.

---

[5] Шунда ук. – Б. 101.

[6] Җәләлиева М. Борынгы татар әдәбиятында кеше образы. – Казан: Татар. китап нәшр., 1968. – Б. 47–89.

[7] Абдуллин Я. Мәгърифәт нуры ачар...: татар иҗтимагый фикере тарихыннан сәхифәләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – Б. 29–40.

[8] Хаков В. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. – Казан: ун-т нәшр., 1972. – Б. 43. Мөхәммәдьяр әсәрләренең тел байлыгы турында В.Хаковның соңрак язган күзәтүләре дә кызыклы (Хаков В. Мөхәммәдьяр теле: әдәби телебезнең инкишафында Казан ханлыгының тоткан урыны // Мирас. – 1997. – №6. – Б. 17–25).

«Нуры содур» поэмасын Э.Фазыловның чагатай теленә нисбәт итүе һәм текстын үзенчәлекле транскрипцияләве тел галиме Фазыл Фәсиев тарафыннан нигезле рәвештә кире кагылган[9]. Фазыловның «Мәхмүд Мөхәммәдьяр» дип, поэма авторы исемен ялгыш бирүе дә аның бүтән фикерләренә ышанычны какшата. Гомумән, Мөхәммәдьяр әсәрләренең теле галимнәр тарафыннан өйрәнелгән, Энҗе Кадыйрова тарафыннан диссертация дәрәҗәсендә этрафлы итеп тикшерелгән[10].

Татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә гомерен багышлаган олпат галимебез Хатыйп Миңнегуловның Мөхәммәдьяр иҗатын өйрәнү буенча хезмәте бик зур. Ул, мәкаләләр язу белән беррәттән, шагыйрьнең иҗатын мәктәп дәреслекләре өчен дә хәзерләде. Аеруча әһәмиятле мәкаләләре галимнең җыентыкларында[11] тупланган, Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1997 һәм 2021 еллардагы басмаларында урын алган.

Галим Марсель Әхмәтҗанов «Нуры содур»ның кульязма күчермәләрен табуы белән беррәттән, Мөхәммәдьярның биографиясенә караган кызыклы мәгълүматлар белән уртаклашты. Мәсгуд Гайнетдинов һәм Фәрит Яхинның «Нуры содур» турында аңлатма-шәрехләре, тарихка һәм ханнарга бәйләп тасвирлаган фаразлары үзенчәлекле булуы белән игътибарны җәлеп итә.

«Нуры содур» әсәренең күчермәләре ара-тирә төрле төбәкләрдә табыла килде. 1999 һәм 2004 елларда табылган ике кульязмада әсәрнең тәнкыйди басмасына (1997 ел) кермәгән һәм укучыларга билгесез булып килгән дүрт икеюллыгы барлыгы ачыкланды[12].

---

[9] Фасеев Ф. Старотатарская деловая письменность XVIII в. – Казань, 1982. – С. 54.

[10] Кадирова Э. Поэмы Мухаммедьяра «Тухфа-и мардан» и «Нур-и содур»: лексика. – Казань: РИЦ «Дом печати», 2001. – 232 с.

[11] Мәсәлән: Миңнегулов Х. Дөньяда сүземез бар... – Казан: Татар. китап нәшр., 1999. – Б. 88–111.

[12] Мәрданов Р. «Бу китап хан догасы берлә тәмам...» // Казан утлары. – 2005. – №7. – Б. 164–166; Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмалары / төз.-авт. Р.Мәрданов.

Фарсы теле белгече, галим Сәлим Гыйләҗетдинов, «Нуры содур»ны авторы «тәрҗемә кыйлып парсы телен...» иҗат иткәнлеген белдергән булса да, Мөхәммәдьяргa фарсы әдәбиятының йогынтысы махсус тикшерелмичә калуына игътибар юнәлтеп, бу мәсьәләдәге кызыклы фикерләрен җиткерде[13].

***

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» һәм «Төхфәи мәрдан» әсәрләре урта гасырларда Шәрык-мөселман әдәбиятында киң таралган дидактик жанрга карый. «Нуры содур»ны Н.Исәнбәт «тезмә әсәр» дип атаган. «Татар поэзиясе антологиясендә» шагыйрьнең ике әсәре дә «шигъри хикәяләр бәйләме» дип билгеләнгән. Галим Х.Миңнегулов болай дип яза: «Һәм «Төхфәи мәрдан», һәм «Нуры содур» поэмалары үзләренең поэтик корылыш-төзелешләре (аларның һәр икесе дә – «тартмалы композицион» жанрда), әхлакый-фәлсәфи-иҗтимагый мәсьәләләрне үзәккә куюлары, лиро-эпик табигатьләре, фәлсәфи-лирик чигенешләре белән бер-берсенә охшаш. Һәр икесендә дә әүвәл куелган мәсьәлә-проблемаларның төп асылы яктыртыла, алга таба аларга иллюстрация рәвешендә төрле хикәятләр китерелә»[14]. Галим шулай ук «Һәр өч әсәре дә лиро-эпик характерда, шигъри формада. Шуңа күрә, аларны хәзерге фәндә еш кына поэма дип билгелиләр»[15] дип аңлатма кертә.

Бу мәсьәләдә М.Гайнетдин фикере башкача иде. Ул болай язды: «Бүгенге голәма Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» әсәрләрен «поэмалар» дип атап йөртүне гадәткә керткән. Бу аталма әсәрләрнең жанр билгеләмәсе була ал-

– Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 8–9.

[13] Гилязутдинов С. Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX в). – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ, 2011. – С. 92–108.

[14] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь / төз. Ш.Абилов; фән. мөх. Х.Миңнегулов. – Казан: Татар. китап нәшр., 2021. – Б. 9.

[15] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / төз. һәм фәнни мөх. Г.Дәүләтшин. – Яңарт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2022. – Б. 126.

мый. Аларда поэма жанрының әсәре дә юк. Алар урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятындагы, Низаминың «Мәхзәнел-әсрар» (1175, «Серләр хәзинәсе»), Сәгъдинең «Бостан» (1256) кебек, халыкның тормыш, мәдәният традицияләре белән тыгыз бәйләнештәге әхлакый үгет һәм шул киңәшләрнең нигезлелеген исбатлауга каратылган хикәятләрдән торган дидактик характердагы шигъри әсәр»[16].

Жанры ничек дип тәгаенләнсә дә, «Нуры содур»ның мәгънәви кыйммәте, һичшиксез, югары. Әдәбият галиме Резеда Ганиева язганча, Мөхәммәдьяр әсәрләренә төрки, гарәп һәм фарсы әдәбиятларында аңарчы иҗат ителгән алдынгы фикерләр тупланган, аңа Фараби, Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Низами, Сәгъди, Нәвои кебек мәшһүр фикер ияләренең һәм әдипләрнең йогынтысы булган[17]. Мәсгуд Гайнетдин «Нуры содур» әсәрендә «жанр структурасының «Мәхзән»нәр, «Бостан»нар кебек классик стандартларга якынлаштырылуын үсеш, яңа казаныш дип билгеләп була» диде[18].

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре – киң мәгънәсендәге гаделлеккә дан җырлау икәнлеге галимнәр тарафыннан тәфсилләп аңлатып язылды. Мәкалә исемнәре үк моның ачык дәлиле: М.Госманов 1968 елгы мәкаләсен «Гаделлек җырчысы Мөхәммәдьяр» дип атаган, Ш.Абилов мәкаләсе (1997 елгы басмада) «Мөхәммәдьяр – гаделлек җырчысы» дип исемләнгән, 2021 елгы китапта Х.Миңнегулов мәкаләсе «Гаделлек җырчысы Мөхәммәдьяр» исеме астында урын алган. Шагыйрь иҗатын иң яхшы белгән галимнәребездә «Нуры содур» поэмасының төп асыл сыйфатын билгеләүдә уртак фикер күптән урнашкан.

---

[16] Гайнетдин М. Мөхәммәдьяр Мәхмүд улы // Әд-дин вәл-әдәп. – 2009. – Май. – Б. 13.

[17] Ганиева Р. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: изд-во ун-та, 1988. – С. 145.

[18] Гайнетдин М. Мөхәммәдьяр Мәхмүд улы... – 2009. – Май. – Б. 14.

***

«Нуры содур» әсәренең фәнгә мәгълүм күчермәләренең саны 1960 нчы елларда дүрт булган. Төрле күләмдәге кульязма күчермәләре табылуы дәвам ителеп, 2013 елга барлыгы 13 нөсхәгә җиткән иде[19]. 2022 һәм 2024 еллардагы археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә поэманың тагын дүрт кульязмасы табылды һәм ачыкланды. Шулай итеп, хәзерге вакытка (2025 ел башына) әсәрнең төрле күләмдәге 17 күчермәсе билгеле. Шулардан 2024 елның җәендә табылган тулы нөсхәсе бу китапны хәзерләп бастыру өчен төп сәбәпләрнең һәм төп нигезләрнең дә берсе булды.

Гарәп хәрефләре белән күчерелгән 17 берәмлек кульязма истәлектә Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре саклангانлыгы соңгы 83 ел эчендә ун археограф: Нәкый Исәнбәт, Бәкер Яфаров, Зәйнәп Максудова, Эргаш Фазылов, Альберт Фәтхи, Миркасыйм Госманов, Дамир Гарифуллин, Габдуллаҗан Могыйнов, Марсель Әхмәтҗанов һәм Р.Мәрданов тарафыннан ачыкланып, фәнни әйләнешкә кертелде.

Табылу урыннары төгәл билгеле булганнары: Казан һәм Ижевск шәһәрләре, Татарстанның Арча, Актаныш, Әгерҗе, Әтнә, Кама Тамагы, Кукмара һәм Сарман районнары, Пермь өлкәсенең Барда районы, Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы. Әйтелгәннәр арасыннан икесе Арча районыннан (Югары Курса һәм Наратлык авылларында) табылган булуы белән бергә, Ижевск күчермәсенең дә элекке чорда Арча төбәгеннән чыккан нәселдән алынганлыгын искәртик. Урыннары төгәл билгеле булмаса да, гомуми күзаллаганда, Петербургта саклана торганнарның берсе Урта Азиядә, икенчесе Идел буе төбәкләренең берсендә һәм өченчесе Фәннәр академиясенең 1934 елгы археографик экспедициясен уздырган Сәед Вахиди һәм Вәли Зәбиров тарафыннан Әтнә районында табылган. Татарстан Республикасы Милли музеендагы нөсхәсенә дә З.Максудова Казан шәһәрендә яисә Татарстан районнарының

[19] Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы кульязмалары // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 32–39.

берсендә юлыккандыр дип, Уфа күчермәсен Башкортстан җирлегенә бәйле дип фаразларга мөмкин.

Киләчәктә археографик эзләнүләрне дәвам иткәндә, «Нуры содур»ның моңарчы билгесез күчермәләре табылуы бик ихтимал. Шулай ук, кульязма истәлекләр тупланган китапханәләрдә һәм музейларда хәзергәчә игътибардан читтәрәк кала килгән шигъри җыентыклар эчендә фрагмент хәлендәге кыскача өзекләре ачыклануы да мөмкин. Гомумән, берничә битле фрагмент кына килеп чыкса да, алар кайчандыр тулы кульязма китаптан калган кыйтгалар булачак бит.

Моңа кадәрге тәҗрибә күрсәткәнчә, һәрбер күчермәдә, хәтта фрагментта да яңалык өсти торган һәм катлаулы текстологик мәсьәләләрне хәл итүгә ярдәм итә торган урыннары була. «Нуры содур» поэмасының кульязмаларын Ш.Абилов әзерләп чыгарган тәнкыйди тексты белән чагыштырганда эре һәм вак аермалар, күп кенә үзенчәлекләр барлыгы күренә.

## Әсәрнең исеме һәм авторы

Тирән мәгънәгә ия булган «Нуры содур», ягъни «Күңелләр нуры» дигән исеме әсәр текстның өч урынында (54, 628, 794 нче бәйтләрендә) белдерелгән. Суфичылык әдәбиятында «Күңел кешенең рухи, мәгънәви дөньясын чагылдыра, ул – инанулар һәм хис-тойгылар чыганагы. Суфи – күңел әһеле, акыл әһеле түгел. Кеше үзенең күңел сафлыгы турында кайгыртырга тиеш. Күңел – Аллаһының тәхете...» дип аңлатыла[20]. Татар әдәбиятында суфичылык рухы хөкем сөргән чорда яшәгән автор әсәрен «Күңелләр нуры» дип атап, ислам диненең төп нигезе булган Коръән һәм хәдисләрне, дин өйрәткән әхлакый һәм тирән мәгънәле сыйфатларга ия булуны күздә тоткан. «Нуры содур» текстының бөтен өлешләрендә хак мөселман өчен иң газиз Коръән сүзләре һәм хәдисләр дәлил-нигез буларак үзәккә куелган. Мөхәммәдьярның китапларда язылып килгән гума-

[20] Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре: төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар, атамалар. – Казан: «Заман» нәшр., 1998. – Б. 211.

низмы аның шәхси сыйфаты гына булмыйча, беренче нәүбәттә, ислам диненең кешелеклелеге һәм гаделлек тәгълиматыннан килгән. Шагыйрь аларны сәнгатьчә нәфис һәм үз телебездә үтемле итеп, оста тасвирлаган. Ислам диненең асыл сыйфатлары белән бергә, Мөхәммәдьяр туган телгә дә мәдхия җырлаган.

«Нуры содур» поэмасы авторының исеме текстта шулай ук өч урында аталган. Башта һәм ахырда (36 һәм 775 нче бәйтләрдә) ул үзен Мөхәммәдьяр дип белдергән, ә 61 нче бәйттә «Атам – Мәхмүд, догачы – Мөхәммәдьяр» дип, әтисенең исемен дә күрсәткән.

Бу әсәр багышланган кеше – Сахибгәрәй ханның исеме – бер урында (19 нчы бәйттә) аталган. Тарихтан билгеле булганча, Сахибгәрәй Миңлегәрәй улы (1501–1551) Казан ханлыгы белән 1521–1524 нче елларда һәм Кырым ханлыгында 1532–1551 нче елларда идарә иткән. Сахибгәрәй хан Кырым ханы булып торган чорда аның хакимлек сәләте һәм идарә итүенең уңай алымнары тарихчылар Михаил Худяков, Миркасыйм Госманов һ.б. тарафыннан яхшы аңлатыла[21].

Әсәрнең 70–71 нче бәйтләрендә Мөхәммәдьяр «Нуры содур»ның «Болгар шәһре Казан дәрвазәсендә», «Мөхәммәдәмин хан каберендә мөҗавир» хәлендә язылганын белдергән. Поэманың кульязма күчермәсен табып, җәмәгатьчелеккә иң беренче буларак таныткан Нәкый Исәнбәт «Болгар шәһәренең Казан капкасында (яки Болгар шәһәре булган Казан капкасында дип тә аңлап була) Мөхәммәд Әмин хан каберендә мөҗавир булган» дип, фаразларын тәкъдим иткән. «Мөхәммәд Әмин ханның 1518 елда үлеп, шәһре Болгарга күмелүе турында сүзләр булганлыктан, без дә Мөхәммәдьярның югары юллардагы сүзеннән, ул бу әсәрен Болгарда язган дип аңлыйбыз», – дигән. Н.Исәнбәт шулай ук «Ихтимал ки, Сахибгәрәй хан, ул вакытта үзе Казанда булмаса да, агасы Мөхәммәд Әмин хан каберен зиярәт итәргә

[21] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. Репринт. воспр. издания 1923 г. – Казань: Фонд ТЯК, 1990. – С. 88–89; Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь / төз. Ш.Абилов. – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – Б. 324–325.

дип Болгарга килгән булыр һәм шул вакытта анда кабер каравылчысы булган Мөхәммәдьяр аңа бу әсәрен багышлап тапшырган булыр. Юк исә, Мөхәммәдьярның ул вакытта турыдан-туры үз ханы булган Сафагәрәйне мактау урынына, бу әсәрен Сафагәрәй өчен дә сюзерен (төп хан) булган Сахибгәрәйгә багышлап язуы ачык аңлашылмый»[22] дигән фаразларын һәм фикерләрен белдергән.

Фәрит Яхин «Болгар шәһре Казан дәрвазәсендә» мәсьәләсе буенча галимнәр арасында булган фикерләр турында әйтеп, ачыклык керткән иде[23].

Казан кирмәненең Сөембикә манарасы янәшәсендәге борынгы төрбә урыннары археологлар тарафыннан тикшерелеп, аларның берсе Мөхәммәтәмин ханныкы дип фаразланганын[24] да искәртик. Һәрхәлдә, Мөхәммәдьяр «Нуры содур»ны, «Төхфәи мәрдан» әсәрен дә Казан каласында иҗат иткән. Соңгысында ул «Газан шәһрендә» дип ачык белдергән[25].

«Нуры содур» әсәре язылган вакытында Казан ханы Сафагәрәйгә багышланган булып, күчерүчеләр тарафыннан ялгыш Сахибгәрәй исеме язылмаган микән дигән сорау да туарга мөмкин. Ләкин «Нуры содур»ның ул бәйтләре сакланган биш кулъязмада (Югары Курса, Олы Мәңгәр, СПб-1, СПб-2 һәм Барда[26]) Сахибгәрәй хан исеме теркәлгән булуы күчерүчеләр ялгышкан дигән шиккә урын калдырмый. Шулай ук, әсәр текстындагы:

---

[22] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры... – 1941. – №4. – Б. 69, 74.

[23] Яхин Ф. Урта гасырлар татар әдәбияты: татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: «Раннур» нәшр., 2003. – Б. 317.

[24] История татар: с древнейших времён. В семи томах. Т. IV: Татарские государства XV–XVIII вв. – Казань: Инст. ист. им. Ш.Марджани АН РТ, 2014. – С. 533.

[25] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь / төз. Ш.Абилов. – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – Б. 89.

[26] «Нуры содур» күчермәләренең мондый рәвештәге – табылган яисә саклану урыннарына нисбәт ителгән шартлы исемнәре турындагы тулырак мәгълүмат шушы кереш мәкаләнең кулъязма нөсхәләренә багышланган бүлекчәсендә язылды.

«Кем мөбарәк Урдуга барсам үзем,
Ханның котлуг йөзене күрсә күзем»,

– дигән, 733 нче икеюллыктан аңлашылганча, «Урду»га (Урдага) барып ханны күрү дигәндә Кырым ханлыгы күздә тотылган дип аңлашыла. Чөнки Кырым ханнары XVI гасырдан башлап үзләрен «Олы Урда олы ханы» дип атаганнар.

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасыннан бер ел ярым чамасы әүвәлрәк кенә – 1540 елда иҗат ителгән «Төхфәи мәрдан» әсәрендә Сафагәрәй хан исеме теркәлгән. Күрәсең, «Төхфәи мәрдан»ны укып яисә тыңлап хушланган Сахибгәрәй хозурыннан шагыйрьгә яңа бер әсәр язарга тәкъдим ителгәндер дип фаразларга мөмкин.

Киеренке сәяси-иҗтимагый шартлар чорында иҗат ителгән «Нуры содур» әсәре Казан ханлыгының шул замандагы төп мәсьәләләренә тыгыз бәйлелеге турында Н.Исәнбәт мәкаләсендә үк аңлатылган[27]. Казан ханлыгында ул вакытта хәлләрнең ничек куерганлыгы, поэманың ил тормышыннан аерылгысызлыгы галимнәр (Н.Исәнбәт, Ш.Абилов, М.Госманов, М.Гайнетдинов, Х.Миңнегулов, Ф.Яхин һ.б.) тарафыннан тәфсилләп язылган, ул мәсьәләгә киңәеп тукталу ихтыяҗы юк.

1997 елда Мөхәммәдьярның 500 еллыгы билгеләп үтелгән иде. Ул мәсьәләдә Шакир Абилов: «Киң күләмдә татар мәдәнияте һәм әдәбияты тарихына Мөхәммәдьяр исеме белән аталачак ул дата – 1996 ел. Мәхмүд Хаҗи улы Мөхәммәдьяр 1496 елда туган дип исәпләнә»[28], – дип язды. Аннан соң «Республика Министрлар Кабинеты бөек шагыйрь Мөхәммәдьярның тууына 500 ел тулу уңаеннан 1997 елны «Мөхәммәдьяр елы» дип игълан итте»[29] дигән хәбәр булды. Әлеге дата турында галим Х.Миңнегулов болай ди: «Шагыйрьнең туган елы һәм урыны хакында хәзергә мәгълүматлар юк. «1497 ел» – фәнни-

[27] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры... – 1941. – №4. – Б. 69–74.
[28] Абилов Ш. Ул – халкы йөрәгендә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 13 октябрь.
[29] Абилов Ш. Мөхәммәдьяр турында яңадан язарга кирәк // Шәһри Казан. – 1998. – 11 сент.; Шул ук // Мирас. – 2003. – №7. – Б. 156.

мәдәни җәмәгатьчелек белән килештерелеп алынган шартлы дата гына. Әмма ул тарихи хакыйкатькә шактый якын булырга тиеш»[30]. Мөхәммәдьярның туу һәм вафат даталары – «1496 (яки 1497) – 1549» рәвешендә энциклопедияләрдә дә урын алып, рәсмиләште дияргә мөмкин[31].

Марсель Әхмәтҗановның бер мәкаләсендә шагыйрь Мөхәммәдьярның тылмач булган хәлендә рус әсирлегенә төшкәнлеге турындагы кызыклы документаль мәгълүмат чыккан иде. Анда болай язылган: «Нугай Урдасы идарәчесе, Сөембикәнең атасы Йосыф мирза 1549 елның июнендә Иван Грозныйга хат җибәргән. Хатында ул Мәскәүгә әсир төшкән татарларны кайтаруны үтенә. Шул хаттагы бер җөмлә кызыклы: «Да прошу у тебя: из Казани попал толмачь, Магмед-Яром зовут, и ты бы его к нам прислал...» Казан илчелегендә тылмач булып барган Мөхәммәдьяр шул ук исемдәге шагыйрь булган дип уйларга тулы нигез бар»[32]. Бу мәгълүмат, һичшиксез, әһәмиятле.

Әлеге мәкаләдә М.Әхмәтҗановның шагыйрь Мөхәммәдьярны Нугай Урдасына, Ык елгасы буендагы Шәехдирбеш шәҗәрәләренә нисбәт итеп, аларның берсендәге Йармөхәммәд (Миркамал бине Булач бине Миралай бине Йармөхәммәд) исемен шагыйрь Мөхәммәдьяр белән тәңгәлләштерү омтылышы ышанырлык түгел. Чөнки шәҗәрәдә исеме күрсәтелгән Миркамал, тарихи чыганаклардан билгеле булганча, үзе дә Мөхәммәдьярның чордашы – XVI гасырда гомер иткән[33].

---

[30] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 2021. – Б. 7.

[31] Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 4: М–П. – Казань: Ин-т Татар. энцикл., 2008. – С. 315; Татар энциклопедиясе: 6 томда. Т. 4: М–П. – Казан: ТР ФАнең Татар энцикл. ин-ты, 2014. – Б. 277.

[32] Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Идел. – 1995. – №11. – Б. 51–52.

[33] Шәҗәрәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 87–88. Шәехдирбеш Миркамал улының исеме XVI һәм XVII гасырлардагы архив документларында теркәлгән (Мәрданов Р. Саралы Мең ыруы татарлары // Безнең мирас. – 2019. – №2. – Б. 26–31). Мөхәммәдьярның М.Әхмәтҗанов тәкъдим иткән шәҗәрәсе нигезсез булуы турында элегрәк Ф.Яхин да язган иде (Яхин Ф. Урта гасырлар..., 2003. – Б. 313).

Әхмәтҗанов мәкаләсендәге шәҗәрәдә исә Йармөхәммәд – Миркамалның әтисе Булачның бабасы итеп, якынча XV гасыр урталарында яшәгән кебек күзаллана.

Соңгырак хезмәтләрендә М.Әхмәтҗанов «Шәҗәрә бабаларыннан Шәйех Дирбештән башлап кына нәселнең реаль тарихы башлана»[34], – дип язды. Шунда ук үзенә каршы килеп һәм, Шәехдирбештән әүвәлгерәк буындагы Йармөхәммәд исемен күздә тотып, «Без бу шәҗәрәне Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр Мәхмүд хаҗи [улы] нәселенә (1497–1549) бәйле дип саныйбыз»[35], – дип тә белдерде.

Кыскасы, Мөхәммәдьярның әлеге нәсел шәҗәрәсенә нисбәтле түгеллеге ачык аңлашыла. Ә архивлардагы хәзергәчә билгесез документлардан шагыйрь шәхесенә бәйле мәгълүматлар киләчәктә, бәлки, табылыр.

## Язылган елы

«Нуры содур» әсәренең иҗат ителгән вакыты текстның 69 нчы бәйтендә төгәл итеп:

Тарих тукуз йөз кырык сәкезендә,
Мөбарәк мөхәррәм уникесендә,

– диелгән һәм 777 нче бәйтендә елы тагын бер кабатлап әйтелгән.

Һиҗри 948 елның 12 мөхәррәм көне хәзергечә (милади ел исәбе буенча) – 1541 елның 8 май көненә туры килә. «Нуры содур» тексты теркәлгән кульъязмаларның берничәсендә (Югары Курса, СПб-1) әсәрнең 948 елда мөхәррәмнең уникесендә, ә башкаларында (Олы Мәңгәр, Исәнбәт, СПб-2, Барда, Сарман) мөхәррәмнең унсигезендә дип күрсәтелгән. Болардан 948 нче һиҗри елның 18 мөхәррәм көне 1541 елның 14 маена туры килә.

«Нуры содур» турында язылган иң беренче мәкаләдә дә «1541 елда» дип төгәл күрсәтелгән[36]. Шакир Абиловның

---

[34] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре: 1 т. – Казан: Татар. китап нәшр., 2012. – Б. 257.

[35] Шунда ук. – Б. 269.

[36] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры... – 1941. – №4. – Б. 69.

мәкаләләрендә дә «милади 1541 ел, май аеның 12-сенә туры килә»[37] дип белдерелгән иде. Тик, шуларга карамастан, фәнни хезмәтләрдә һәм мәкаләләрдә хәзерге вакыткача «Нуры содур» әсәренең иҗат ителгән елы ике төрле – 1541 һәм 1542 дип язылып килә. (Төрле даталар күрсәтү хәтта бер үк китап һәм мәкалә эчләрендә дә бар). Мәсәлән, 1542 елны белдергән хата 1963 елда чыккан «Борынгы татар әдәбияты» китабыннан ук килә, анда «Һиҗридән 948 ел мөхәррәменең 18е милади белән 1542 елның 15 нче маена туры килә» дип басылган. Шагыйрьнең 1966 елда дөнья күргән беренче басма җыентыгында да (7 нче битендә) шул ук дата күрсәтелгән.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1997 елгы тәнкыйди басмасында[38] (9 нчы биттә) – 1541 елның 12 май көне, 303 битендә кайбер кулъязмаларда 18 мөхәррәм дип язылганлыгы һәм аның 18 майга туры килүе искәртелгән. Әмма шул ук китаптагы бер үк мәкалә эчендә ике төрле: 325 нче биттә «Мөхәммәдьяр үзенең «Нуры содур» поэмасын язган чакта, 1541 елда...», ә 332 нче битендә «”Нуры содур” әсәре, кат-кат искәртелгәнчә, 1542 елда язылган» диелгән.

Тәнкыйди текст нәшер ителгән елда ук басылып чыккан альбомда исә 1541 елның 15 маенда язылган дип басылган иде. Шул ук дата башка хезмәтләрдә дә кабатланды[39].

Ялгыш «1542» дигән дата озын гомерле булып чыкты – ул китаптан-китапка күчеп[40] хәзергәчә килеп җитте. Э.Кадыйрова хезмәтендә ике төрлесе дә бар: 4 нче биттә «1542» диелсә, 23 нче битендә: «1541» дип басылган. Татар энциклопедиясендә

---

[37] Абилов Ш. Ул – халкы йөрәгендә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 13 октябрь.

[38] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – 336 б.

[39] Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.) – Казань: изд-во «Фэн», 1999. – С. 134.

[40] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т. 1: Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 297; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 71; Гайнетдин М. Хакыйкать юлыннан: әдәби тәнкыйть. – Казан: Татар. китап нәшр., 2001. – Б. 97, 101.

– 1542 ел күрсәтелгән[41], Татар тарихының җиде томлыгында шулай ук «1542» ел[42].

Әсәрнең язылган елына бәйле буталчыклар турында моннан егерме елдан артык элек үк игътибар итеп язучылар һәм аннары да шуны искәртүчеләр булды. Мәсәлән, әдәбият галиме Фәрит Яхин, аерым алганда, «Нуры содур» поэмасы авторы тарафыннан күрсәтелгән һиҗри 948 елның 12 мөхәррәм датасын – 1542 елның 14, 15 май көннәренә яисә 1541 елның 12 маена туры килә дип, бүтән галимнәрнең хезмәтләрендә шушы хаталарның төрлечә кабатланып йөрүенә игътибар юнәлтте. Чынлыкта, ул дата 1541 елның 8 май көненә туры килә, дип язды[43]. Даталар мәсьәләсендә элегрәк без дә искәрткән идек[44].

Мөхәммәдьяр әсәрләренең 2021 елгы басмасында (7 нче биттә) «Нуры содур» иҗат ителгән вакыт «946 (1541/1542) елның мөхәррәм аенда» дип язылган. Бу очракта һиҗри елы ялгыш күрсәтелүе өстенә, ай исеме төгәл билгеле була торып да, милади елы тәгаенләнмәгән. Татар әдәбияты тарихы сигезтомлыгының 2022 елда дөнья күргән иң соңгы басмасында да «Нуры содур» 1542 елда иҗат ителгән дип хаталы язылган[45].

Бу мәсьәләнең торышын күзаллар өчен китерелгән мисаллар җитәрлек. Мөхәммәдьяр тарафыннан төгәл итеп күрсәтелгән елның фән әһелләре тарафыннан ялгыш язылган мисалларының барысын да искә-исәпкә алу ихтыяҗы юк. Инде бу хаталар күпме заманнаргача дәвам итәр – анысын киләчәк буыннар күзәтерләр.

Ихтимал, 1541 яисә 1542 ел дип язылуында зур хикмәт юк дип уйлаучылар бардыр. Әмма әсәрнең авторы төгәл итеп күрсәткән дата бозылмаска тиеш. Андый гамьсезлек бетсен иде.

---

[41] Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 4: М–П..., 2008. – С. 315; Татар энциклопедиясе: 6 томда. Т. 4: М–П..., 2014. – Б. 277.

[42] История татар: с древнейших времён. В семи томах. Т. IV..., 2014. – С. 34, 794.

[43] Яхин Ф. Урта гасырлар..., 2003. – Б. 316.

[44] Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның... – 2013. – №6. – Б. 38.

[45] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т. ..., 2022. – Б. 42, 126.

Югары Курса кульъязмасының ахырында 1668 (1669) елгы, күчерүче тарафыннан үзгәртелгән бәйт бар. Бу мәсьәлә бик кызыклы. Чөнки 1997 елда басылган китаптагы «Нуры содур» поэмасы ахырында да шундый ук икеюллык теркәлгән. Һиҗри 1079 (миладича 1668/1669) елда күчерелгән датасы, әсәрнең ахыргы шигъри юлларына бәйләп, гүяки, әсәр шул вакытта язып тәмамланган кебек мәгънәдә теркәлгән. 1997 елгы басма китап өчен нигез итеп алынган СПб-1 кульъязмасы XVIII гасыр ахырында күчерелгән[46], ә Югары Курсаныкы XVIII гасыр уртасына нисбәтле. Димәк, протографтагы 1668/1669 нчы ел 80–120 еллар соңрак язылган күчермә нөсхәләрдә кабатланган. «Нуры содур»ның ике кульъязмасында бер төрле күчерелү датасының теркәлгәнлеге – аларның башлангыч протографларына бәйле булган. Бу һәр икесе нәкъ бер үк протографтан алынган дигән сүз түгел. Ихтимал, башлангычтагы бер протографтан күчерелеп килгән башка нөсхәләр кулланылгандыр. Шигъри текстка өстәлгән дата шулай итеп бер кульъязмадан икенчесенә күчеп таралган. Мондый кызыклы күренеш татар археографиясендә сирәк очрый.

Поэма текстының ахырындагы 792 нче бәйттә:

Рамазан айының унбереси
Ки булды бу китабның интиһаси,

– дигән сүзләр дә бар. Бу, ихтимал, иң башта автор тарафыннан белдерелгән дөрес дата – 69 нчы бәйттәгечә «мөхәррәм уникесе» рәвешендә язылган булгандыр. Ә аннан соңгы күчерүчеләр үз эшләрен тәгалләгән даталарны күрсәткәннәрдер дип фаразларга мөмкин. 1997 елгы китапның 308 нче битендә дә «...айны күрсәтү соңгы күчерүчегә карарга мөмкин. Күчерүче биредә Мөхәммәдьярның безгә килеп җитмәгән шигъри юлларыннан файдаланган булса кирәк» дип аңлатылган.

792 нче икеюллыктагы дата Югары Курса күчермәсендә «рамазан айының унбересе» диелгән. Ә СПб-1 нөсхәсендә һәм

---

[46] Татар кульъязмаларының даталарын билгеләү уңаеннан бу турыда язылды: Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульъязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 77–78.

аңа нигезләнгән 1997 елгы китапта «рамазан айы, айның ахырысы», күпчелек кульязмаларда (Уразай, Урта Шөн һәм Сарман) «җөмадел-ахир айының йегермесе» дип теркәлгән. Әлеге һәм 1668/1669 елга туры килә торган һиҗри 1079 елны белдереп язылган даталар, чынлыкта да, әсәр авторының үзе язганнардан үзгәртелгән дип саныйбыз[47].

Галимнәр электән үк язып килүенчә, XIV–XV гасырларда яшәгән шагыйрь Лотфиның «Гөл вә Нәүруз» дастанындагы бетем өлеше, аерым сүзләре генә үзгәртелеп, «Нуры содур» поэмасының ахырына өстәлгән. Ягъни, Мөхәммәдьяр аны иҗади файдаланган[48]. 1968 елгы мәкаләдә «Нуры содур»га «Гөл вә Нәүруз»дан 10 икеюллык «үзгәрешсез күчерелгән дияргә мөмкин» дип язылган[49]. 1997 елгы китапта (306 нчы биттә) «Шушы 778 нче бәйттән башлап...» дип һәм «шушы күрсәтелгән 772 нче бәйттән алып, 783 нче бәйткә кадәрге шигъри юллар» Лотфи дастаныннан дип күрсәтелгән. Барлыгы 12 икеюллык. Китапта бәйт саннарын күрсәтүдә бераз ялгышлык киткән, дөресе – 778 нче бәйттән 789 нчы бәйткә кадәрге өлеше күздә тотылган. Бу тексттан да күренеп тора һәм Ш.Абилов тарафыннан 786, 788 нче бәйтләргә карата 241 нче биттә, 306–307 нче битләрдә бирелгән искәрмәләрдән дә аңлашыла. «Нуры содур»ның әлеге өлеше безнең бу басмада 781–791 нче бәйтләрдә. 1997 елгы басмада 788 нче бәйт итеп 1668/1669 елга туры килә торган икеюллыкны, гәрчә аның төп

[47] Күчерүчеләр елын гына үзгәртеп, ай һәм көне элеккечә (автордагыча) калган дип фаразлаганда, 948 елның 11 рамазан көне милади 1541 елның 29 сентябренә, ә 20 җөмадел-ахир – шул елның 11 сентябренә тәңгәл килер иде. Текстның үзендә «Нуры содур» мөхәррәм (май) аенда язылганлыкны белдерелгәнен исәпкә алганда, ахыргы бәйтләрдәге сентябрь мәгълүматлары, димәк, күчерүчеләр үзгәрткәннән калган. Ә 1079 елның 11 рамазан көне милади 1669 елның 12 февраль көненә, 20 җөмадел-ахир көне 1668 елның 25 ноябренә туры килә.

[48] Төхфәи мәрдан. Нуры содур. Поэмалар / төз. Ш.Абилов. – Казан: Татар. китап нәшр., 1966. – Б. 127–129; Абилов Ш., Максудова З. Лутфи Идел буйларында // Казан утлары. – 1968. – №8. – Б. 141–142.

[49] Абилов Ш., Максудова З. Лутфи Идел буйларында..., 1968 – Б. 142.

нигезе Лотфидан ук килгән дип аңлашылса да, шушы – 2025 елгы басмадагы төп текстка кертмәдек, ә искәрмәләр өлешендә бирдек. Чөнки аның күчерүчеләр тарафыннан үзгәртелгән датасы буталчык тудыра.

### Авторның мөҗавирлеге мәсьәләсе

«Нуры содур» әсәрендә (71 нче бәйттә) мондый юллар бар:

Мөхәммәд Әмин хан кабрендә, әй, йар,
Мөҗаувир ирүрмән бәсе булуб зар.

Мөхәммәдьяр әйткән «мөҗавир» сүзе фәнни әдәбиятта, нигездә, кабер сакчысы мәгънәсендә аңлатылды. Гүяки, Казан каласының үзәгендәге кирмән эчендә, ханнар сарае янындагы, таш белән төрелгән хан каберен саклау ихтыяҗы булган.

«Могҗизнамә» дип аталган, 1515 елда иҗат ителгән күләмле шигъри әсәрнең үзендә күрсәтелгән авторы Максуди Казан ханы Мөхәммәтәмин булган дип, әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдин раслаган иде. Әлеге әсәр 2004 елда китап итеп нәшер ителде[50]. М.Гайнетдин язуынча, «Алтын Урда яки Казан ханнарының кабере янында мөҗавир барлыгы турында хәбәр сакланмаган»[51]. Галимнең «Могҗизнамә» авторы Мөхәммәтәмин хан булган дип дәлилләве «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы басмаларында хупланмады да, кире дә кагылмады. Әдәбият тарихының 2014 елда дөнья күргән икенче томына Мәсгуд Гайнетдиннең «Могҗизнамә» әсәре һәм аның авторы турындагы күләмле мәкаләсе (72–94 битләр) урнаштырылса да, аңа карата мондый мөнәсәбәт белдерелгән: «Әдәбият галиме М.Гайнетдинов «Могҗизнамә» исемле Урта гасыр әдәби ядкяренең авторы дип нәкъ менә Мөхәммәд Әминне күрсәтә. Бу фикер фәнни нигезсез түгел, шулай да әлеге әсәрне өйрәнү һәм аны әдәбият тарихында чагылдыру галимнең үз

[50] Мөхәммәт Әмин. Могҗизнамә. – Казан: Татар. китап нәшр., 2004. – 295 б.
[51] Шунда ук..., 2004. – Б. 11.

ихтыярындагы эше булып кала»[52]. Менә шундый – табышмаксыман – сүзләр әйтелгән.

Мәсгуд Гайнетдин, аерым алганда, Мөхәммәдьяр Мөхәммәтәминнең иҗатына ияргәнен һәм ике автор әсәрләре арасында тыгыз бәйләнеш барлыгын раслады. М.Гайнетдиннең дәлилләрен куәтләп, бигрәк тә Мөхәммәдьяр иҗаты белән «Могҗизнамә» әсәре арасындагы уртаклыкларны аерым мисаллар белән күрсәтеп, без дә язган идек[53]. Шунда ук Мөхәммәдьярның «мөҗавир»леге «кабер сакчысы» мәгънәсендә түгеллегенә дә тукталдык.

Гарәп телендә «мөҗавир» сүзенең мәгънәләре күп, арада «остазның рухи шәкерте, дәрвиш» дигәннәре дә бар бит. Шагыйрьләрнең образлы тасвирга һәвәс булганы, бигрәк тә, суфичылык әдипләрендә «мөҗавир» сүзенең күчерелмә мәгънәдә кулланылуына әһәмият бирелмәде. Бу – әлбәттә, суфичылык тәгълиматындагы мәгънәләр серен белеп бетермәү һәм санга сукмаудан туган зур хата. Мөхәммәдьярны «кабер сакчысы» яки «күзәтүчесе» дигән фикер әдәбият тарихына караган хезмәтләрнең берсеннән-икенчесенә күчеп, хәзергәчә дәвам итә. Мондый карашның хаксызлыгын әйтеп язган галим Фәрит Яхинның китабы[54] нәшер ителгәнгә дә ике дистә елдан артык вакыт узды инде. Тик, шуңа карамастан, гыйльми һәм хәтта иң җитди фәнни хезмәтләрдә дә хата фикер язылып килә[55].

«Мөхәммәдьяр ханны түгел, нәкъ менә Мөхәммәт Әмин шагыйрьне үзенең рухи остазы итеп таный. Әсәрләрен төзүдә,

---

[52] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2: XV–XVIII гасырлар / төз. Р.Рахмани. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б. 29. Мондагы «үз ихтыярындагы эш» дигән сүзләр «шәхси фикере» дигән мәгънәдә әйтелгән булса кирәк.

[53] [Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2016. – Б. 42, 49–53.

[54] Яхин Ф. Урта гасырлар..., 2003. – Б. 317–318.

[55] Татарская энциклопедия. Т. 4: М–П..., 2008. – С. 315; Татар энциклопедиясе: 6 томда. Т. 4: М–П..., 2014. – Б. 276; История татар: с древнейших времён. В семи томах. Т. IV..., 2014. – С. 533.

сюжетлар әзерләүдә ул «Могҗизнамә»гә таяна» дип, Мәсгуд Гайнетдин шул әсәрдән Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасына кертелгән хикәятне мисал итеп китерә. Сүзен дәвам итеп ул: «Ике әсәр арасында турыдан-туры бәйләнеш барлыгы бәхәссез. Әмма ике шагыйрь әсәрләре арасында болай күзгә бәрелеп тормаган аваздашлыклар, Мөхәммәт Әмин хан әсәрендәге мотивларны үзгәртеп «яңартулар» тагын да күбрәк» дип яза[56]. Ул Мөхәммәтәмин әсәренең сюжетларын Мөхәммәдьяр сукырларча кабатлаган булуын да искәртеп, «Төхфәи мәрдан»да китапның бетем өлеше язылганнан соң тагын хикәят язылу мисалын әйткән[57]. Шундый ук алымны – бетем өлешеннән соң да авторның «хикәят»ләр өстәгәнен «Нуры содур»да да күрәбез.

Хәзерге вакытка тексты тулы сакланмаган, бердәнбер күчермәдәге башка бер шигъри әсәрнең дә авторы шул ук – «Могҗизнамә»не иҗат иткән Мөхәммәтәмин дип, шактый раслап язган идек. Ул әсәрне шартлы рәвештә «Гыйлем Хакка илтер» дип атадык. Дәлилләребезнең кайберләрен монда искә алыйк. «Могҗизнамә» әсәренә хас үзенчәлекләрнең Мөхәммәдьяр әсәрләрендә дә барлыгын, ләкин анда азрак микъдарда икәнлеген белдердек. Ике автордагы «кеше – эше, күз – сүз, белең – кылың, беләлем – кылалым, нигъмәт – дәүләт, эш – тәшвиш, гата – хата, кәрәк – кәрәк, могтәбәр – хәбәр, тәмам – хасс-у-гам» кебек уртак рифмалар, фикер һәм җөмлә төзелешләре бу әдипләр арасында тыгыз бәйләнеш булганлыгын күрсәтә.

«Гыйлем Хакка илтер» әсәрендәге 52 нче бәйтнең

Гыйлем илә дөнйа-у гокба алынур,
Икесендә гыйзз-ү дәүләт булынур[58],

– юлларындагы «дөнья–гокба» (ягъни, ахирәт) турында «Могҗизнамә»дә дә язылган (55, 133 битләр). Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында да моңа күп охшашлыклар бар.

[56] Мөхәммәт Әмин. Могҗизнамә..., 2004. – Б. 12.
[57] Гайнетдин М. Мөхәммәдьяр Мәхмүд улы... – 2009. – Май. – Б. 13.
[58] [Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер..., 2016. – Б. 67.

Мәсәлән, шул поэманың 203, 530 һәм 691 бәйтләрендә дөнья–гокба мәсьәләсе урын алган. «Нуры Содур» поэмасындагы (441 бәйт):

Бәс, вафа берлә сафа хасил булур,
Ул сафа берлә сәгадәт табылур,

– юллары да «Гыйлем Хакка илтер» әсәренең әйтелгән 52 нче бәйтенә аваздаш. Андагы борынгырак формадагы «булынур» («табылыр» мәгънәсендәге) сүзе Мөхәммәдьярда «табылур» диелгән.

«Гыйлем Хакка илтер» әсәренең 62 нче бәйтендәге:

Җан-күңел бу гыйльм илә рәушан улыр,
Бакдыгы йир күзенә гөлшан улыр[59],

– икеюллыгына Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасындагы (418 нче бәйт):

Кичә-көндүз даимән рәушан ирер,
Йаз-у-кыш галәм камуг гөлшан ирер,

– юллары аваздаш.

Мөхәммәдьярның шул ук әсәрендәге 139 һәм 652 бәйтләрендәге «йаз вә кыш» сүзләре «Гыйлем Хакка илтер» текстында 64 нче бәйттә дә бар[60].

Әсәрләрдәге бәйләнеш һәм охшашлыкка тагын берничә мисал китерик. «Гыйлем Хакка илтер» әсәренең 68 бәйтендәге «Бабе әүвәл уш Колак кем – ишедүр»[61] дигәнгә Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәрендәге 74 нче бәйтнең «Бабы әүвәл – гадел сүзләре ирүр» дигән юлы охшаш. Шулай ук «Гыйлем Хакка илтер» текстының 91 бәйтендәге (72 нче биттә) «Бу Борундыр бонда ул өчүнче баб» шигъри юлына «Нуры содур»ның «Сыйддикъ бабы ирүр сәкезенче баб» (81 нче бәйт) дигәне аваздаш.

Ике әдипнең әсәрләрендәге уртак тасвирларны һәм охшашлыкларны җентекләп өйрәнгәч, Мөхәммәдьяр поэмалары чирек гасыр соңрак язылганга нигезләнеп, Максуди аның

[59] Шунда ук. – Б. 69.
[60] Шунда ук. – Б. 69.
[61] Шунда ук. – Б. 69.

остазы булган дияргә ныклы нигез бар. Әсәрләрендә үзенең Казан шагыйре булганын язган Мөхәммәдьярга бәйле рәвештә Максудиның да шушы ук җирлек әдибе икәнлеге раслана. Элекке кулъязма җыентыкларда, гадәттә, бер чор-заман әсәрләре бергә тупланганлыгы турында элегрәк язган идек[62]. Моның ачык дәлилләренә мисаллар китердек[63].

Мөхәммәдьяр әсәрләрендәге тематик һәм тасвири чаралар аларда Максуди әсәрләренең иҗади тәэсирен белдереп тора. Мөхәммәдьяр Максуди иҗатыннан үрнәк алганлыгы һәм файдаланган булуы ачык күренә. Максудиның шигъри әсәрләре мәгънәви яктан куәтле һәм шигъри осталык җәһәтеннән шактый сыйфатлы булганга, аның башка әдипләргә йогынты ясаганлыгы табигый күренеш.

Шагыйрь Мөхәммәдьярның «мөҗавирлеге» бары тик «остазның шәкерте, дәвамчысы» дигән мәгънәдә генә аңланырга тиеш дип уйлыйбыз.

## «Нуры содур»ның кулъязма нөсхәләре

Әсәрнең кулъязма күчермәләре турында Ш.Абилов болай дип язган: «Нуры содур» поэмасына килгәндә эш болайрак тора. 1955 нче елда Мөхәммәдьяр иҗатына багышланган диссертация эшенә тотынганда минем кулда әсәрнең бер генә тулы кулъязмасы да юк иде. Күчермәләре дә мактанырлык түгел: аларның йә башламы, йә ахыры юк»[64].

1963 елда дөнья күргән «Борынгы татар әдәбияты» китабында һәм 1966 елда нәшер ителгән Мөхәммәдьяр әсәрләре китабында «Нуры содур»ның ул вакытка билгеле булган дүрт кулъязма (берсе Н.Исәнбәт нөсхәсе һәм өчесе Ленинградта саклanган) күчермәләре турында Шакир Абилов язды, тасвир-

[62] Кыз хикәяте / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2012. – Б. 46.

[63] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы..., 2009. – Б. 119–123; [Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 3–4, 15, 119–121.

[64] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 32.

ламаларын бастырды[65]. Галим шулай ук болай дип тә белдерде: «Шагыйрьнең кайбер хикәяләре, аерым шигъри юллары башка җыентыкларда да очрый. Илебездәге зур шәһәрләрнең берсендә «Нуры содур» поэмасының тагын бер кулъязмасы саклануы турында кайбер мәгълүматлар бар»[66]. «Башка җыентыкларда очрый» дигәндә нәрсәләр күздә тотылганы билгесез, һәрхәлдә, Ш.Абиловның бу мәсьәләне ачыклабрак язган хәбәрләрен күрмәдек. Ә «зур шәһәрләрнең берсендә...» дигәндә, күрәсең, Уфа китапханәсендәге күчермә күздә тотылгандыр.

Мөхәммәдьяр әсәрләрен 1997 елда Татарстан китап нәшриятында бастырырга хәзерләгәндә «Нуры содур» поэмасының кулланылган 7 кулъязмасының исемлеге бирелгән[67]. Алар: Нәкый Исәнбәт архивындагы нөсхә, С.-Петербургта саклана торган өч күчермә, Казан дәүләт университеты китапханәсендәге, Башкортстан дәүләт китапханәсендәге һәм Дамир Гарифуллинда саклана торган кулъязмалар. Н.Исәнбәт архивындагы күчермә кулланылмаганлыгы искәртелгән. Болардан тыш, әсәрнең сигезенче күчермәсе – археограф Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан Әгерҗе районында 1978 елда табылган кулъязма исемлектә теркәлмәгән булса да, Мөхәммәдьяр әсәрләрен басмага хәзерләгән галим Шакир Абилов аны китапның 305 битендәге искәрмәсендә телгә алган. Кызганыч ки, бу китапта «Нуры содур» поэмасы күчермәләренең тасвирламалары бирелмәгән, аларның кайсы гасырларга караганлыгы, кайчан һәм кайдан табылулары да әйтелмәгән.

Марсель Әхмәтҗанов 1994 елда Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында тапкан тагын бер күчермә һәм Әгерҗе районындагы ике истәлек турында 1995 елгы мәкаләсендә язды[68]. «Нуры содур»ның әйтеп үтелгән тугыз күчермәсе тасвирлары

[65] Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 356–357; Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур..., 1966. – Б. 127–129.
[66] Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур..., 1966. – Б. 129.
[67] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 229.
[68] Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Идел. – 1995. – №11. – Б. 51.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең телен өйрәнгән галимә Энҗе Кадыйрова китабында 2001 елда басылган иде[69].

1999 елда «Нуры содур» әсәренең тагын бер күчермәсе, аннан соң 2004 елда янә берсе табылды. Шулай итеп, 2004 елга Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы төрле тулылыктагы 11 күчермәдә билгеле иде. Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклана торган бу ике кулъязманың текстлары (тулы булмасалар да) безнең тарафтан хәзерләнеп, 2009 елда «Татар археографиясе» сериясенең 4 нче китабы буларак нәшер ителде[70].

Казан дәүләт университеты һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Киров өлкәсенең Вятка Аланы районындагы Урта Шөн авылында 2002 елда табылган җыентыкта «Нуры содур»ның тагын бер (уникенче) күчермәсе булганлыгын ачыклап, кыскача мәгълүмат язып бастырдык[71].

«Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы кулъязмалары» исемле, 2013 елда чыккан мәкаләдә әсәрнең барлыгы 13 күчермәсе билгеле булуы турында язып, аларны кыскача тасвирладык[72]. Унөченче күчермәсе (фрагмент) Татарстан Республикасының Милли музеендагы кулъязмалар арасында ачыкланды. Әлеге мәкаләдә «Киләчәктә, Мөхәммәдьяр әсәрләренең яңа басмаларын хәзерләгәндә, бу кулъязмаларның һәммәсе дә файдаланылырга һәм текстологик яктан җентекләп өйрәнелергә тиеш. Чөнки текстларда аермалы һәм яңалык өсти торган урыннар бар»[73], – дип искәртелде.

«Татар әдәбияты тарихы» сигезтомлыгының 2014 елда басылып чыккан 2 нче томында «Нуры содур» күчермәләре дүрт кулъязмада билгеле[74] булуы турындагы мәгълүмат бик күптәнге

---

[69] Кадирова Э. Поэмы Мухаммедьяра..., 2001. – С. 12–14.
[70] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы..., 2009. – 128 б.
[71] Кыз хикәяте..., 2012. – Б. 13.
[72] Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 32–39.
[73] Шунда ук. – Б. 38.
[74] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2..., 2014. – Б. 109.

– 1966 елгы китапка нигезләнгән иде. Анда әсәрнең 1941, 1948, 1957 һәм 1959 елларда табылган (ачыкланган) күчермәләре искә алынган. Бу уңайдан 1959 елдан соңгы вакыт эчендә археография өлкәсендә табышлар булып торганлыгын һәм әдәбият тарихының 2014 елгы бу томы дөнья күргәнче «Нуры содур»ның 13 күчермәсе мәгълүм иде дип искәртеп яздык[75]. Татар әдәбияты тарихы сигезтомлыгының яңартылган икенче басмасында (Казан, 2022) «Нуры содур» поэмасының ничә күчермәсе барлыгы турында, гомумән, берни дә әйтелмәгән. Ш. Абилов тарафыннан хәзерләнеп, 1997 елда дөнья күргән хезмәт нигезендә 2021 елда яңадан бастырылган китапта да поэма күчермәләренең саны турында мәгълүмат юк. Хәлбуки, мондый фундаменталь хезмәтләрдә Казан ханлыгы чорында иҗат ителгән сирәк җәүһәрләрнең ничаклы һәм хәзергәчә нинди күчермәләрдә килеп ирешүләре турында берничә җөмлә язылса, гыйльми китапларның дәрәҗәсе артыр гына иде.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе хезмәткәрләре 2022 елгы археографик экспедиция вакытында Арча районыннан «Нуры содур» поэмасының тагын бер күчермә фрагментын таптылар. Шулай итеп, Мөхәммәдьяр әсәренең төрле күләмдәге 14 күчермәсе булды.

Милли китапханәнең 2024 ел җәендә Арча районында үткәрелгән археографик экспедициясендә (җитәкчесе – кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллин) «Нуры содур»ның тулы текстлы(!), XVIII гасыр уртасына караган кульъязмасы табылу – татар археографиясе һәм татар әдәбияты тарихы өчен аеруча истәлекле вакыйга дип бәяләнергә хаклы.

2024 елның сентябрь һәм декабрь айларында Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана торган кульъязма истәлекләр арасында «Нуры содур»ның тагын ике фрагментын ачыклау насыйп булды.

---

[75] Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 240–241.

Нәтиҗәдә, «Нуры содур» поэмасының хәзерге вакытка текстлары төрле күләмдә сакланган 17 күчермәсе фәнгә билгеле[76]. Аларның унөче Татарстанда (12 күчермә – Казанда һәм берсе Болгарда), өчесе С.Петербургта, берсе – Уфада саклана.

«Нуры содур» әсәренең тагын бер – Казан дәүләт университетының Миркасыйм Госманов җитәкчелегендәге археографик экспедициясе вакытында 1980 елда Свердловск өлкәсендә табылган дефектлы күчермәсе турында мәгълүмат бар. М.Госманов китабында ул: «1980 елны Свердловск өлкәсендәге Гәйнә авылында «Нуры содур»ның, дефектлы гына булса да, өченче күчермәсенә очрадык»[77] дип, кыскача гына искә алынган. Бу күчермә турында, кызганычка каршы, Госманов китабында язылган шушы хәбәрдән башка, берни дә белмибез. Мөхәммәдьяр иҗатын өйрәнгән галимнәр аны бер тапкыр да искә алмаганнар. Университет китапханәсенең картотекасында «Нуры содур»ның Гәйнәдә табылган бу кульязмасы аерып күрсәтелмәгән. Күрәсең, ул, дефектлы булганлыктан, җыентык эчендәге күләмлерәк башка бер әсәр исеме белән теркәлгәндер дип фаразладык. Бу нөсхә турында тулырак мәгълүмат булмаганга күрә, аны хәзергә әсәрнең унсигезенче күчермәсе итеп язмадык.

***

Әсәр күчермәләрен текстларының тулылыгы тәртибендә кыскача тасвирлап үтәбез. Аларның күпчелеген табылган яки саклана торган урыннарына нисбәт итеп, шартлы исемнәр белән атадык.

«Нуры содур» поэмасының кульязма текстлары арасында иң тулысы – Татарстан Республикасы Милли китапханәсе хезмәткәрләренә Арча районының Югары Курса авылын-

---

[76] Бу сан беренче мәртәбә белдерелде: Мәрданов Р. Гарәп хәрефле..., 2024. – Б. 33.

[77] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 47; Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыл. икенче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – Б. 71.

да Лилия Вахитова 2024 елның 17 июль көнендә тапшырган күчермә. (Ул 23 июльдә безнең тарафтан ачыкланды). Бу ядкяр Россиядә эшләнгән, 16,5х20,5 см зурлыгындагы кәгазьгә XVIII гасыр уртасында теркәлгән. Текстлар көрән төстәге язу карасы белән, һәр битендә уртача 15 юлда, 12х16 (16,5) см мәйданда, гарәп язуының нәстәгъликъ-шикәстә төрендә язылган. Хәзерге вакытта китапханәдә «8667т» шифры белән саклана. Кулъязманың «Нуры содур» теркәлгән өлеше 28 кәгазь күләмендә. Текстның иң өстендә «Һәза китаб Нуры содур» дип язып куелган. Кем һәм кайда, төгәл кайсы елда күчергән булуы турында мәгълүматлары юк. Кәгазендәге су билгесе буенча аның Россиядә 1739 елда эшләнгәнен ачыкладык. Кулъязманың соңрак иясе булган кешенең исеме теркәлгән. (Тулырак тасвирламасы бу китапның ахырындагы махсус мәкаләдә язылды). Әлеге кулъязмада «Нуры содур» әсәренең 789 бәйте (икеюллыгы) теркәлгән. Башка күчермәләрдә булган, текстның төрле урыннарындагы биш икеюллык Югары Курса кулъязмасында теркәлмичә төшеп калган. (Әсәр текстларының тулылыгы мәсьәләсе аерым бүлекчәдә тасвирланды). Әлеге күчермәдә бүлек исемнәре язылмыйча, текст эчендә буш урыннар калдырылган, бу мәсьәлә искәрмәләрдә җентекләп аңлатылды. Югары Курса кулъязмасындагы «Нуры содур» әсәре Татарстанда саклана торган һәм хәзергә иң тулысы булуы ягыннан аеруча зур әһәмияткә ия. Башка күчермәләр белән чагыштырганда, текстында хаталары азрак. Кулъязма турында кыскача мәгълүмат һәм бер битенең фоторәсеме «Татар археографиясе» сериясенең 34 нче китабында басылды[78]. Бу кулъязма нөсхә шушы китапта алга таба «Югары Курса» күчермәсе буларак телгә алыначак.

Тулылыгы ягыннан поэманың икенче күчермәсе Россия Фәннәр академиясенең С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кулъязмалары институтында «B4417» шифры белән саклана. Аның XVIII гасырның соңгы чирегенә нисбәтле икәнлеген

[78] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле..., 2024. – Б. 33, 55–57.

раслый торган 1780 нче еллардагы даталары бар. Җыентыкның 39б–68а кәгазьләрендә «Нуры содур» тексты теркәлгән. Дмитриева каталогында ул XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башыныкы итеп тәгаенләнгән. Каталогта 21х16 см зурлыгындагы рус кәгазенә көрән һәм кызыл каралар белән, нәстәгъликъ язуында теркәлгән булуы, Идел буенда күчерелгәнлеге һәм Зарифов коллекциясендә 1940 елда саклануга алынганлыгы күрсәтелгән. Һәр битендәге тексты 16х11 см мәйданда 14 юл күләмендә теркәлгән. Тышлыгы соңгы чорныкы (1956 ел) дип, җыентыкның 63–68 нче кәгазьләре өлешчә ертылган булуы да искәртелгән[79]. Шакир Абилов тасвирламасында бу кулъязма институтның гыйльми хезмәткәре А.Могыйнов тарафыннан 1959 елда ачыкланган булуы әйтелгән. Кәгазьдәге су билгеләренә һәм аерым битләрендәге даталарга карап, аны 1789–90 нчы елларда күчерелгән дип исәпләргә мөмкин. «Нуры содур»ның бу кулъязмасы бик бозылган нәстәгъликъ төрендә, калын европа кәгазенә кара төстәге язу карасы белән теркәлгән, диелгән. Дөрес, кәгазенең форматы Л.Дмитриева хезмәтендә күрсәтелгәннән аермалырак: «17х22,5 һәм тексты язылган мәйданы 10,5х14,5см»[80]. Бу кулъязмадагы текст Мөхәммәдьярның 1997 елда басылган китабы өчен төп нөсхә итеп кулланылган. Ш.Абилов бу күчермәдә «Нуры содур»ның 780 бәйте бар дип күрсәткән[81]. Безнең исәпләү буенча 786 икеюллык теркәлгән. Текст эчендәге кайбер икеюллыклары язылмыйча, төшеп калган. Кызганыч ки, тексты тулы диярлек сакланган булса да, поэманың башка күчермәләре арасында монысы – иң күп хаталар белән язылганы. Ш.Абилов та бу күчермә турында болай дигән: «...башы, ахыры булса да – бик кимчелекле... Гарәп-фарсы сүзләре белән беррәттән төркитатар сүзләре дә бик бозып, хаталы язылган»[82]. Әсәрнең исеме

[79] Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской Академии наук. – М: Вост. лит., 2002. – С. 300.
[80] Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур..., 1966. – Б.127.
[81] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 229.
[82] Шунда ук. – Б. 32.

39б кәгазендә хаталы итеп «Нур садаир» рәвешендә теркәлгән. Кулъязманың 57б һәм 58а кәгазьләренең факсимилесе Э.Кадыйрова хезмәтендә (229, 230 нчы битләрдә) бирелгән. Бу кулъязманы «СПб-1» дигән исем белән күрсәттек.

Поэма тексты тулырак сакланган өченче күчермә Татарстанның Сарман районы үзәге – Сарман авылында яшәүче һәвәскәр археограф, журналист һәм төбәк тарихчысы Дамир Гарифуллин тарафыннан ачыкланып, 1992 елда матбугат аша белдерелгән иде. Мәкаләдә болай диелгән: «Минем кулдагы кулъязма «Нуры содур» китабы унтугызынчы гасырның икенче яртысында күчерелгән булырга тиеш. Ул 17,5х22 см зурлыктагы 26 биттән гыйбарәт, текст урнашкан өлеше 10х14,5 см тәшкил итә. Миндәге кулъязмада бәйтләрнең саны 764-кә җитә. Кулъязманың баштагы берничә бите юк»[83]. Бу күчермәнең сакланган өлешендә башы әсәрнең 29 нчы бәйтенә туры килгәненә һәм һәр битендә ике баганалы 15–16 юл текст теркәлгәненә карaганда, кулъязманың башындагы беренче кәгазе генә җуелган. Ахыры бар. Ш.Абилов мәгълүматы буенча анда барлыгы 761 бәйт теркәлгән[84]. Безнең исәпләү буенча бу кулъязмада 760 икеюллык, аларның берничәсе икешәр тапкыр кабатланган. Текст караңгы көрән төстәге кара белән, гарәп язуының нәстәгъликъ төрендә теркәлгән. Кустодлары тотрыклы рәвештә. Хаталарының күләме, гомуми бәяләгәндә, уртача – бик күп түгел. «Нуры содур»ның Д.Гарифуллин карамагында булган бу кулъязмасы хәзерге вакытта Болгар Ислам академиясендә саклана. Бу күчермә «Сарман» дигән шартлы исем белән аталды.

Дүртенче кулъязма М.Әхмәтҗанов тарафыннан Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында 1994 елда табылган. Хәзерге вакытта ул Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

[83] Гарифуллин Д. Кулъязманың яңа нөсхәсе // Ватаным Татарстан. – 1992. – 17 апрель. Бу күчермәдәге бәйтләр исәбе Э.Кадыйрова китабында 623 дип күрсәтелгән (Кадирова Э. Поэмы Мухаммедьяра..., 2001. – С. 14). Кадыйрова бу очракта Н.Исәнбәт күчермәсенең күләме белән бутаган дип аңладык.
[84] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 229.

Язма мирас үзәгендә саклана (39 нчы фонд, 1 тасвир, 5996 нчы саклану берәмлеге). Кулъязма җыентыкның тасвирламасында «...30б–52б битләрендә XVI йөз татар шагыйре Мөхәммәдьяр Мәхмүд хаҗи улының (?–1549, июнь) «Нури-содур» поэмасы язылган. Кулъязма XVII гасыр башларында хәзерге Әтнә төбәге Олы Мәңгәр авылында язылып Закировлар гаиләсендә сакланган. Без бу ачышны 1994 елның 17 июлендә Олы Мәңгәр авылында ачтык. Әлеге текст шагыйрь әсәренең иң борынгы күчермәсе булып тора» дип яза М.Әхмәтҗанов[85]. Шунда ук күрсәтелгәнчә, кулъязманың кәгазе 15х19 см зурлыгында икәнлеге һәм бер биттәге тексты 17 юлда теркәлгәне белдерелгән. Бу күчермәдә барлыгы 750 икеюллык бар дип М.Әхмәтҗанов тарафыннан элегрәк язылды һәм әлеге кулъязма XVII–XVIII йөзләргә карый дип тәгаенләнгән иде[86]. Авторның 2000 елда дөнья күргән китабында да бәйтләрнең саны һәм вакыты шулай ук кабатланды[87]. Безнең исәпләү буенча бу күчермәдә әсәрнең 726 икеюллыгы теркәлгән. Э.Кадыйрова, М.Әхмәтҗанов сүзләренә нигезләнеп, бу күчермә XVII гасыр ахырына яисә XVIII гасыр башына нисбәтле дип язды[88]. Олы Мәңгәр күчермәсе, чынлыкта да, XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башына нисбәтле дип уйлыйбыз. Бу кулъязманың башындагы куш битенең фоторәсеме (30б–31а кәгазьләре) 1997 елгы альбомда бирелгән иде[89], аннан соң энциклопедиядә

[85] Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе. Соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары (1972–2012). Алтынчы кисәк. – Казан, 2016. – Б. 110.
[86] Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Идел. – 1995. – №11. – Б. 51.
[87] Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 71–72.
[88] Кадирова Э. Поэмы Мухаммедьяра..., 2001. – С. 14. Анда болай диелгән: «...найдена в 1994 году в деревне Большой Менгер Атнинского района Татарстана во время экспедиции сотрудником ИЯЛИ М.Ахметзяновым. По его мнению, данная рукопись относится концу XVII в. или к началу XVIII в.».
[89] Мөхәммәдьяр һәм аның чоры = Мухаммедьяр и его время = Mohammediar and his Time / төз.-авт. Абилов Ш., Әхмәтҗанов М., Измайлов И. Альбом. – Казан: «Гасыр» нәшр., «Рухият» нәшр., 1997. (Бит саннары куелмаган).

урын алды[90]. Тулы факсимиль күчермәсе Мәскәүдә чыккан китапта басылды[91]. Әлеге факсимиледән күренгәнчә, текстта хаталар чагыштырмача аз. Әсәрнең башы бар, ахыры юк, текст 732 нче бәйттә өзелә. Исеме беренче битенең югары өлешендә «Мөнаҗате Нуры содур» дип күрсәтелгән. Текст гарәп язуының нәстәгъликъ-шикәстә төрендә, көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. Бу күчермә шушы китапта «Олы Мәңгәр» кульязмасы буларак искә алына.

Бишенче кульязма танылган әдип, драматург, фольклорчы Нәкый Исәнбәт архивында сакланган. Гомумән, Мөхәммәдьярның «Нуры содур» исемле әсәре турында, 1940 елда үзе тапкан әлеге кульязма нигезендә, иң беренче булып Н.Исәнбәт мәкалә язган дип әйтеп үткән идек. «Совет әдәбияты» журналының 1941 елгы 4 нче санындагы мәкаләдә язылганга караганда, «Кульязма (манускрипт) форматы 16х20 см булып, барлыгы 38 бит... барлыгы 623 бәет булып, «Нуры сыдур» 1246 юл тезмәдән тора», исеме китап башында кәгазь читендә зәгъфран белән теркәлгән, тугызынчы битендә «1764 сәнә» дигән датасы белдерелгән. Н.Исәнбәт кульязманың бер бите читендә карандаш белән «Әтрәкле Гыймаз» дигән язу барлыгын искәрткән. Төп тексттан бер гасыр соңрак теркәлгән (карандаш кулланылуы шуңа ишарә итә) ул исем «Нуры содур»ның әлеге күчермәсен аерым бер төбәккә нисбәт итәрлек дәлил була алмый. Ш.Абилов та бу күчермәнең күләмен 623 икеюллыктан тора дип күрсәткән[92]. Н.Исәнбәт әсәрнең текстын тулы дип язган булса да, Абилов мәгълүматына караганда, ул кимрәк булган. 1941 елгы журналда бирелгән фоторәсеме буенча фикерләгәндә, язуы шактый төзек һәм хатасыз дияргә мөмкин. Ул гарәп язуының нәстәгъликъ-шикәстә төрендә теркәлгән. Хәзерге вакытта кульязма Н.Исәнбәтнең шәхси

---

[90] Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 4: М–П..., 2008. – С. 315; Татар энциклопедиясе: 6 томда. Т. 4: М–П..., 2014. – Б. 277.
[91] Мухаммедьяр. Произведения. Пер. с булгарского тюрки / сост. Р.Кадыров. – М: Булгар иле, 2007. – С. 367–410.
[92] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 229.

архивында (туганнары карамагында) саклана дип беләбез. Бу күчермәне «Исәнбәт» кулъязмасы буларак телгә алдык.

«Нуры содур»ның алтынчы күчермәсен Удмуртия башкаласы Ижевск шәһәрендә яшәүче Рәисә Дәүләтшина бу юлларның авторына 2004 елның җәендә тапшырган иде. Рәисә ханымның бабасы ягыннан туганнары, тулы бер династия рәвешендә, 1854 елдан алып 1930 нчы елларга кадәр Ижевск шәһәрендә указлы имамнар булып торганнар. Аларның төп чыгышлары хәзерге Татарстанның Арча районындагы Оры авылыннан булган[93]. Бу кулъязма хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2071т» шифры белән саклана. Поэма тексты, филиграньнәреннән күренүенчә, 1748–1756 елларда Ярославль шәһәрендәге Алексей Затрапезный мануфактурасында эшләнгән, 11x17 см зурлыктагы 59 кәгазьдә, караңгы коңгырт төстәге язу карасы белән язылган. Сакланыш сыйфаты уртача. Поэма текстының баш өлеше һәм ахыры җуелган. Кустодлары бар. Һәр биттәге текст мәйданы 7x12,5 см тәшкил итә. Дәфтәрнең һәр битендә унар юл. Кулъязманың 8–9, 14–15, 23–24, 53–54 кәгазьләре арасында, берәр кәгазьләре төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән. Башы поэманың 152 нче бәйтенә, ә ахыры 774 нче бәйткә туры килә. Сакланган өлеше 574 икеюллыкны һәм тагын өч бәйтнең берәр юлын тәшкил итә. Текст гарәп язуының нәстәгъликъ төренә якын рәвештә теркәлгән. Хаталары ягыннан бәяләгәндә язылышы уртача. Поэманың басма тәнкыйди тексты белән чагыштырганда бу кулъязманың кызыклы үзенчәлекләре булуы хакында элегрәк махсус мәкаләбез дөнья күргән иде[94]. Тексты һәм аерым битләренең фотокүчермәләре, шулай ук тулы тасвирламасы 2009 елгы китапта басылды[95]. Бу кулъязма кечкенә формат-

---

[93] Мәрданов Р. Иж шәһәрендәге татарлар тарихыннан. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2006. – Б. 65–72.

[94] Мәрданов Р. «Бу китап хан догасы берлә тәмам...» // Казан утлары. – 2005. – №7. – Б. 164–166.

[95] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы..., 2009. – Б. 3–13, 64–118, 124.

лы һәм һәр биттә берәр багана рәвешендә язылган булуы белән башка күчермәләрдән аерылып тора. Чөнки калганнары барысы да уртача зурлыктагы кәгазьләргә теркәлгәннәр. Китапта бу күчермәне «Ижевск» кулъязмасы буларак телгә алдык.

Җиденче кулъязма Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «3713т» шифры белән саклана. Ул 1974 елгы археографик экспедиция вакытында Пермь өлкәсенең Барда районындагы Каенавыл авылында Муллахыялый Бакуновтан[96] алынган. Текст 16,5x21 см[97] зурлыгындагы ачык яшкелт төстәге, Россиядә эшләнгән 17 кәгазьдә. Һәр битендә уртача 17 юл теркәлгән, язу мәйданы 10,5x16,5 см тәшкил итә. Кәгазендәге филиграненда Озеровлар кәгазь фабрикасында эшләнгәнен белдергән абррвиатура һәм «1811» дигән дата төшерелгән[98]. Ул караңгы көрән төстәге язу карасы белән, нәстәгъликтөрендә теркәлгән. Бүлек исемнәре кызыл төстәге кара белән язылган. Кустодлары тотрыклы. Сакланышы уртача. Текстның башы һәм ахыры юк. Башы поэманың 16 нчы бәйтенә, ә ахыры 717 нче бәйткә туры килә. Кайбер кәгазьләре төшеп җуелганлыктан, текстта өзеклекләр бар. Ш.Абилов тарафыннан бу күчермәдә поэма тексты 557 бәйтне тәшкил итә дип белдерелгән[99]. Безнең исәпләү буенча монда барлыгы 561 бәйт теркәлгән, шуның өчесе (99, 121 һәм 183 нче бәйтләр) икешәр мәртәбә кабатланган. Хатала-

---

[96] Бу фамилия Э.Кадыйрова китабында (14 нче биттә) «Вакунов» дип ялгыш басылган.

[97] Кадыйрова китабында (14 нче биттә) бу саннар текст размеры дип ялгыш күрсәтелгән.

[98] Кәгазьләрдәге филиграньнәргә багышланган махсус белешмәдә Озеров Петр Евграфович тарафыннан 1786 елда Вятка губернасының Малмыж өязендәге Никольское (Иске Бурец) авылында кәгазь фабрикасы оештырылганлыгы, XIX гасырда варислары әтиләренең эшен дәвам иткәнлеге турында язылган (Клепиков С.А. Филиграни и штемпели на бумаге русского и иностранного производства XVII–XX века. – М: изд-во Всесоюзной книжной палаты, 1959. – С. 42, 154. Иске Бурец авылы – хәзерге Киров өлкәсенең Малмыж районына керә, ул Татарстанның Кукмара районына чиктәш, Бөр елгасының Нократка койган урынында.

[99] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 229.

ры шактый. Тасвирламасы Э.Кадыйрова хезмәтендә (14 нче биттә) басылган иде. Бу кулъязманы шартлы рәвештә «Барда» күчермәсе дип атадык.

Сигезенче кулъязма Россия Фәннәр академиясенең С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кулъязмалары институтында «В3690» шифры белән саклана. Андагы текстның күләме, Ш.Абилов белдергәнгә караганда, 562 икеюллыктан гыйбарәт[100]. Безнең исәпләү буенча 554 бәйт. Әлеге кулъязманың тасвирында аның XIX гасыр башында (1804–1805 еллардан соң) 20х15 см зурлыгындагы рус кәгазенә кара һәм көрән төсләрдәге язу каралары белән, гарәп язуының нәстәгъликъ төрендә, Идел буенда күчерелгән булуы, поэма тексты җыентыкның 72а–89б кәгазьләрендә[101] бер битендә 16х10 см мәйданында теркәлгәнлеге белдерелгән. Җыентык катыргы һәм күн белән тышланган. Язма ядкярнең кәгазе дымнан һәм пычрактан зарарланганлыгы, 1934 елгы археографик экспедициядә табылган булуы күрсәтелгән. Текстның башыннан 4 юлы[102] һәм ахырында 8,5 кәгазе сакланмаганлыгы белдерелгән[103]. Чынлыкта, әсәрнең башындагы 3 икеюллыгы җитми. Текст һәр биттә икешәр итеп сызылган кысаларга алынган, кустодлары бар. Текстның башы 4 нче бәйткә, ахыры 569 нчы бәйткә туры килә. Ш.Абилов тасвирламасында бу кулъязманы институтның өлкән гыйльми хезмәткәре А.Могыйнов 1957 елда ачыклаган булуы, «Нуры содур» җыентыкның һәр битендә уналтышар[104] икеюллык итеп, 11х13,5 см мәйданда теркәлгәнлеге, бу җыентыкның

---

[100] Шунда ук. – Б. 229.

[101] 1966 елгы китапта (128 нче биттә) һәм Э.Кадыйрова хезмәтендә (13 биттә) әсәр тексты 82а–99б кәгазьләргә теркәлгән дип ялгыш күрсәтелгән.

[102] 1966 елгы китапта (128 биттә) һәм Э.Кадыйрова хезмәтендә (13 биттә) башыннан 18 бәйте (36 юлы) җитми дип ялгыш язылган. Кадыйрова китабында: «Не хватает 18 беитов, т.е. 32 страницы с начала поэмы и 221 беитов с конца» диелгән. Бу җөмләдәге «страницы» сүзе ялгыш язылган, дөресе «строки» булырга тиешле иде.

[103] Дмитриева Л.В. Каталог..., 2002. – С. 138, 300.

[104] Л.Дмитриева каталогында һәр биттә 18 юл дип, ялгыш күрсәтелгән.

һиҗри 1215 (1800–1801) елда Мәмәш авылында мулла Йосыф улы Нигъмәтулла тарафыннан кызы Бибихәбибә өчен күчерелгәнлеге әйтелгән[105]. Кулъязмада әсәрнең тексты шактый төзек һәм хаталары аз. «Нуры содур»ның шушы күчермәсенең тексты Ш.Абилов тарафыннан хәзерләнеп, «Борынгы татар әдәбияты» китабында бераз кыскартылып бастырылган[106], шул ук китапның 403 нче битендә 75а кәгазенең фоторәсеме бирелгән. Кулъязманың 77а һәм 77б кәгазьләренең факсимилесе Э.Кадыйрова хезмәтендә (227, 228 нче битләрдә) урын алган. Бу күчермәне «СПб-2» дип атадык.

Әлеге кулъязманың 1934 елгы экспедициядә табылуына карата мәгълүмат өстәргә тиешбез. Сәед Вахидинең 1934 елгы экспедициядә Әтнә районындагы Олы Әтнә, Югары Бәрәскә, Күлле Киме, Иске Тазлар, Иске Өҗем авылларында булып, кулъязмалар җыйганлыклары турындагы хатирәсе бар[107]. Димәк, «СПб-2» кулъязмасы шул авылларның берсендә табылган.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1966 елда чыккан китабында (128 биттә) кулъязмалар тасвирламасы өлешендә Ш.Абилов Мәмәш авылы Казан губернасында булгандыр дип фаразын белдергән һәм Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтенә ишарә иткән. «Мөстәфадел-әхбар...»нең ул битендә Мәмәш түгел, ә Мамыш авылы телгә алынган. (Мамыш авылы хәзерге Әтнә районында). Шул ук тасвирламада «...китапның иясе аны күчереп язган Нигъмәтулла улы мөфти[108]» икәнлеге күрсәтелгән. Баштагы катыргының эчке ягына «ушбу китап мөфти бин Нигъмәтулла мәрхүмнең торыр» диелгән.

---

105 Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур..., 1966. – Б.127.

106 Борынгы татар әдәбияты..., 1963. – Б. 399–412.

107 Духовное наследие: поиски и открытия. Вып. 4 / сост.: Л.Гарипова, Г.Ханнанова, Л.Давлетшина, А.Мубаракшина. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – С. 93–103. *Иске Тазлар* – хәзерге Ташчишмә авылы.

108 Бу очракта «мөфти» – дини вазифа түгел, ә Мөфтәхетдин исемнең кыскача варианты булганлыгы аңлашыла. Патша заманында мөфти булып торган затлардан берсенең дә этисе Нигъмәтулла түгеллеген дә искәртик.

Үзебездән өстәп әйтсәк, кулъязма җыентыкның 69б кәгазендә «1215 сәнәи нәбәвия маһе җөмадел-ахир фи карьяи Мамыш. Бибихәбибәгә мөбарәк булсын» дип, 8а кәгазендә дә бу китапның Бибихәбибәгә багышлап, Аллаһ ризасы өчен күчерелгәнлеге әйтелгән. 1215 елның җөмадел-ахир ае миладе буенча 1800 елның октябренә туры килә. Кулъязманың 9а кәгазендәге «ошбу китап Мөфтәхетдиннеңдер» дигән язмасыннан 1966 елгы китап тасвирындагы «мөфти» (мөфти бине Нигъмәтулла) атамасының нәкъ шул Мөфтәхетдин исеменең кыскача әйтелеше икәнлеге ачыклана. Әлеге кулъязмада Мамыш авылы исеме теркәлгән булуы – бу ядкярнең Әтнә төбәгенә нисбәтле икәнен раслый.

«Нуры содур»ның күләм тулылыгы ягыннан тугызынчы урындагысы Кукмара районының Уразай авылында табылган кулъязма ядкяр. Ул хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1116т» шифры белән саклана. Бу җыентык китапханәгә Татар дәүләт гуманитар институты студенты Гөлназ Гариповадан 1999 елның 11 маенда алынды. Ул аны туган авылы Уразайда яшәүче Имаметдин Ибраһим улы Ибраһимовтан алган. Ибраһимовлар гаиләсенә әлеге кулъязмалар бабалары – Галиулла улы Ибраһимнан калган. Бу кулъязма җыентык 1701–1710 елларда Һолландиядә эшләнгән, 15,5х19,5 сантиметр зурлыктагы кәгазьдә, күпчелек өлеше караңгы көрән, ә кайбер урыннары ачык көрән төстәге кара белән, нәстәгъликъ-шикәстә төрендә язылган. Шулай ук кызыл кара белән язылган урыннары да бар. «Нуры содур»ның 5–9 нчы баб-бүлек исемнәре (12б, 14б, 16б, 18б һәм 20а кәгазьләрдә), 18б кәгазьдә баб исеме астындагы Коръән аятьләре һәм өч урында (15б, 17б һәм 20б кәгазьләрдә) «Хикайәт» сүзе кызыл кара белән теркәлгән. Сакланышы уртачадан начаррак: күп кенә битләренең түбәнге өлешләре теткән һәм җуелган. Шактый урыннарында язу карасы юка кәгазьне бозып, тишкәләгән. Төбен теккән җебе сүтелгән һәм бөтен битләре дә диярлек берберсеннән аерылган. «Нуры содур» поэмасы кулъязманың

12а–28б кәгазьләрендә теркәлгән. Әсәрнең башы сакланмаган, төп өлеше һәм ахыры бар. Дефектлы кәгазьләре булганлыктан, текстка өзеклекләр кергән. Башы 268 нче бәйткә туры килә. Гомуми күләме 516 бәйтне тәшкил итә. Тексты бер биттә 16 юл булып, 9,5х15 см мәйданында язылган. Кустодлары тотрыклы. Хаталары күп түгел. Поэманың әлеге күчермәсе турында матбугатта хәбәрләр бастырган идек[109]. Бу күчермәнең тексты һәм аерым битләренең фотокүчермәләре, шулай ук тулы тасвирламасы 2009 елгы китапта бирелде[110]. Кульъязманың бер куш бите (15б һәм 16а кәгазьләре) фоторәсеме нәфис альбомда[111], икенче куш бите (20б һәм 21а кәгазьләре) журналда дөнья күрде[112]. Бу күчермә «Уразай» кульъязмасы дип телгә алына.

Әсәрнең унынчы күчермәсен Казан университеты һәм Татарстан Милли китапханәсенең берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Киров өлкәсенең Вятка Аланы районындагы Урта Шөн авылында Маһинас Хәлим кызы Мулламөхәммәтова 2002 елда тапшырган. Хәзерге вакытта Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «5228т» шифры белән саклана торган шигъри җыентыкның 1а–12б кәгазьләрендә «Нуры содур» поэмасының тексты язылган булуын 2009 елның 30 октябрендә ачыклаган идек. Ул турыда беренче мәртәбә 2012 елда кыскача белдерелде[113], 2013 елгы мәкаләдә тасвирламасын бастырдык[114]. Текст XVIII гасырның икенче яртысы-

[109] Мәрданов Р. Кыйммәтле кульъязма // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2001. – №1. – Б. 36; Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда // Казан утлары. – 2002. – №3. – Б. 128.

[110] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы..., 2009. – Б. 3–13, 16–63, 119–123.

[111] Татар китабы = Татарская книга / төз.-авт.: Р.Мәрданов, И.Һадиев; рәсс. Ш.Насыйров. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 93; Шул ук фоторәсем татар әдәбияты тарихы сигезтомлыгының икенче томнарындагы (2014, 2022) фототупламнарда кабатлап басылды.

[112] Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның... // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 33.

[113] Кыз хикәяте..., 2012. – Б 12–13.

[114] Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның... // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 36–37.

на нисбәтле, 16х20 см зурлыгындагы рус кәгазендә, төп өлеше көрән төстәге, бүлек башлары кызыл язу каралары белән, һәр битендә икешәр баганалы 16 юл итеп, нәстәгъликъ-шикәстә төрендә теркәлгән. Һәр биттәге текстның мәйданы – 11(11,5) х14 см. Башы 417 бәйткә туры килә, ахыры бар. Күчермәдә поэманың күләме 374 бәйтне тәшкил итә. Кулъязманың гомуми сакланышы уртачадан түбән, текстында хаталар бик күп түгел. Бу нөсхә шушы китапта «Урта Шөн» исеме белән искә алына.

Унберенче күчермә Россия Фәннәр академиясенең С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кулъязмалары институтында «В343» шифры белән саклана. Бу кулъязманың 113а–123а кәгазьләрендә «Нуры содур» поэмасының төрле өлешләре әсәр текстындагы тәртибенчә түгел, ә бутабрак язылганнар. Дмитриева каталогында кулъязма җыентыкның XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башына каравы турында һәм башка тасвир мәгълүматлары теркәлгән. Каталогта әлеге кулъязманың 19,5х16 см зурлыгындагы рус кәгазенә, бер битендәге тексты 15х12,5 см мәйданда[115] һәм 12 юл итеп, кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәстәгъликъ төрендә теркәлгән булуы, Радлов коллекциясендә 1890 елда тапшырылганлыгы һәм Урта Азиягә нисбәт ителүе күрсәтелгән. Тышлыгы соңгы чорныкы (1954 ел) һәм аңа элекке көнчыгыш тышлык өлешләре ябыштырылганлыгы искәртелгән[116]. Заманында Урта Азиядә табылган булса да, палеографик үзенчәлекләренә караганда, ул күбрәк Идел буенда күчерелгән кулъязмаларга якын. Аның Урта Азиядәге татар кешеләреннән алынган булуы ихтимал. Ш.Абилов әлеге кулъязманы 1948 елда Б.Яфаров тасвирлаганын, 155 нче битендә «1168» (милади 1755/56) дигән ел күрсәтелгәнен әйткән[117]. Кулъязма җыентыкта мондый дата

[115] 1966 елгы китапта (127 нче биттә) кәгазе 17,8х23 см, тексты 15,5х19,5 см мәйданда диелгән. Кадыйрова хезмәтендә (13 нче биттә) кәгазе 16,5х20,5 см дип күрсәтелгән.

[116] Дмитриева Л.В. Каталог..., 2002. – С. 203.

[117] Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур..., 1966. – Б.127.

теркәлгән булуы текстының XVIII гасырның өченче чирегенә нисбәтле икәнлеген белдерә һәм аның Дмитриева күрсәткән вакыттан элеккерәк чорга каравына ишарә итә. Ш.Абилов аны 246 бәйттән тора дип белдерелгән, Кадыйрова хезмәтендә дә шул сан күрсәтелгән[118]. Безнең исәпләү буенча, бу күчермәдә «Нуры содур»ның 242 бәйте теркәлгән. Текстының башы 158 нче бәйткә, ахыры 706 нчы бәйткә туры килә. Зур өзеклекләргә ия бу җыентыкта әсәрнең 158–217 нче бәйтләре (113а–115б кәгазьләрдә), 447–471 бәйтләре (115б–116б кәгазьләрдә), 218–244 нче бәйтләре (116б–117б кәгазьләрдә), 472–495 нче бәйтләре (117б–118б кәгазьләрдә), 323–385 нче бәйтләре (118б–121а кәгазьләрдә), 654–706 нчы бәйтләре (121а–123а кәгазьләрдә). Бу өлешләр арасындагы кайбер икеюллыклары төшеп калган. Әсәрнең билгеле булган күчермәләре арасында монысы иң хаталы язылганнарының берсе. Бу кулъязманың (114б кәгазенең) фоторәсеме кайбер китапларда басылды[119]. Әлеге кулъязманы «СПб-3» дип атадык.

Уникенче күчермә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгендә саклана (39 фонд, 1 тасвир, 5995 саклану берәмлеге). Аның тасвиры бу рәвештә басылган: «Казан ханлыгы дәверендә иҗат иткән татар шагыйре Мөхәммәд Мәхмүд хаҗи углының «Нуры Содур» поэмасының фрагменты: 1–5 кәгазь; 160х210 мм; 120х165 мм; 16 юл. Кулъязма XVIII йөзнең соңгы чирегенә карый. Ул коңгырт төстәге кара белән һәр биттә икешәр баганада 15 юл поэтик текст булып тора. Кустодлар куелган. Әсәр бүлекләргә бүленеп аларга исемнәр куелган «Гафу агафу» (2б бит), «Әлхикәйәт» (3а бит). Кулъязма археограф М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан археографик экспедиция барышында 1978 елның 21 июлендә Татарстанның Әгерҗе төбәге[120]

---

[118] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 229; Кадирова Э. Поэмы Мухаммедьяра..., 2001. – С. 13.

[119] Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур..., 1966. – Б.109; Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.1..., 1984. – Фототуплам.

[120] Китапта «Әтнә төбәге» дип ялгыш басылган.

Яңа Аккуҗа авылында Мөхәммәтша Вәлиев агадан (1901 елда туган) бүләк рәвешендә алынды һәм соңыннан М.Әхмәтҗанов тарафыннан тасвирланды»[121]. Язуы бозык нәтәгъликъ төрендә дияргә мөмкин, шактый хаталы. Сакланышы уртача. Бу күчермәдә «Нуры содур»ның 282 шигъри юлы, ягъни 141 икеюллыгы теркәлгән булуы турында элегрәк язылган иде[122]. Безнең исәпләү буенча, анда барлыгы 143 бәйт. Текстның башы һәм ахыры юк, сакланган өлешендәге башы 498 нче бәйткә, ахыры 668 нче бәйткә туры килә. Бу кулъязмадан куш битенең (4б һәм 5а кәгазьләренең) фотокүчермәсе Мөхәммәдьярга багышлап нәшер ителгән нәфис альбомда басылып чыкты[123], ә 1б һәм 2а кәгазьләренең факсимилесе Э.Кадыйрова хезмәтендә (225–226 нчы битләрдә) бирелгән. Бу кулъязма шартлы рәвештә «Яңа Аккуҗа» дип исемләнде.

«Нуры содур»ның унөченче урындагы күчермәсе Уфада – Башкортстан Республикасының Әхмәтзәки Вәлиди исемендәге Милли китапханәсендә сакланган. Аның тексты галим Эргаш Фазылов тарафыннан өйрәнелеп, 1974 елда[124] һәм 1982 елда басылып чыккан. Соңгысында, кызганыч ки, кулъязманың тулырак тасвиры бирелмәгән. Анда язылганга караганда, кулъязманың 20х16 см зурлыгындагы 8 биттән торганлыгы, һәр битендә 13–14 икеюллык кара төстәге язу карасы белән нәстәгъликъ төрендә теркәлгәнлеге, 5 нче һәм 6 нчы кәгазьләре зарарланганлыгы әйтелгән[125]. Күчермәнең кайсы гасырга караганлыгы

---

[121] Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе... Алтынчы кисәк. – Казан, 2016. – Б.110.

[122] Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Идел. – 1995. – №11. – Б. 51; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы..., 2000. – Б. 71.

[123] Мөхәммәдьяр һәм аның чоры..., 1997. (Бит саннары куелмаган).

[124] Бу турыда мәгълүмат бар: Фасеев Ф. Старотатарская деловая письменность XVIII в. – Казань, 1982. – С. 54; Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 229.

[125] Фазылов Э. Дидактическая поэма Махмуда Мухаммедъяра «Нур-и садур» из рукописной коллекции Башкирии // Письменные памятники Башкирии: историко-филологические исследования. – Уфа: БФАН СССР, 1982. – С. 163–173.

белдерелмәгән. Бу кульязмада әсәрнең 107 бәйте теркәлгән. Шакир Абилов 1966 елгы китапта «Илебездәге зур шәһәрләрнең берсендә «Нуры содур» поэмасының тагын бер кульязмасы саклануы турында кайбер мәгълүматлар бар»[126], – дип язганында нәкъ шушы – Уфадагы күчермә күздә тотылган дип аңлашыла. Димәк, бу кульязма 1960 нчы елларда ачыкланган дип уйларга мөмкин. Әлеге күчермәне «Уфа» кульязмасы дип атадык.

Ундүртенче күчермәнең фрагменты Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана. Ул XVII гасырның уртасында күчерелгән кульязма китаптан калган, Европада эшләнгән ике кәгазьдә. Бу кәгазьләр соңрак икенче бер кульязма китапка битләрдән ябыштырып ясалган тышлык итеп кулланылганнар. Әлеге ядкяр музейдагы Зәйнәп Максудова фондында «ГОМРТ 18369-211» шифры белән саклана. Бу кульязма уңаеннан З.Максудова әсәр һәм аның авторы турында теркәп куйган язма да бар. Зурлыгы 15х21 сантиметрга тиң кәгазь битләрендә шигъри текст икешәр баганада унөчәр юл итеп язылган. Текстының мәйданы 10,5х13,5 см тәшкил итә. Кустодлары бар. Язу төре нәстәгъликъка якын, хаталары аз. Әлеге фрагмент әсәрнең 448–499 бәйтләреннән (52 икеюллыктан) гыйбарәт. Әлеге ядкярне 2012 елның ноябрь аенда ачыкладым. «Нуры содур»га багышланган хезмәтләрдә һәм мәкаләләрдә әсәрнең бу фрагменты телгә алынмаган – димәк, фән өчен ул билгесез кала килгән иде[127]. Аның турында 2013 елда беренче мәртәбә мәгълүмат биреп, кыскача тасвирын бастырдык[128]. Алга таба әлеге күчермә «Музей» кульязмасы буларак искә алыныр.

Унбишенче күчермә фрагментын Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә 2024 елның 4 сентябрендә ачыкладык. Бу ядкяр китапханәдә «8419т» шифры белән саклана. Әлеге кульязма 1838 елда Мөхәммәделәмин Дауд улы (Мөхәммәделәмин

[126] Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур..., 1966. – Б. 129.
[127] Зәйнәп Максудова китапханәсенә багышланган махсус китапта (Мәскәү, 2019) «Нуры содур»ның бу фрагменты турында шулай ук язылмаган.
[128] Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның... // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 37.

бине Дауд бине Чәнәй) тарафыннан теркәлгән. Кульязма җыентыкның 5а–6а кәгазьләрендә «Нуры содур» поэмасының сигезенче бабындагы тел тыюга багышланган хикәят һәм 10 нчы бабның башындагы унбер икеюллыгы теркәлгән. Гомуми күләме 43 бәйттән тора, башы 497 нче бәйткә, ахыры 574 нче бәйткә туры килә. Текст 17х21 см зурлыгындагы рус кәгазендә, һәр битендә 11х16,5 см мәйданда ике баганалы 17 юл итеп, көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. Язуы нәстәгъликъка якын, хаталары күп түгел. Текст икешәр кат итеп сызылган кыса-рамка эченә алынган. Кульязманы китапханәгә тапшырган кеше турында Альберт Фәтхи кулы белән «Кравец Ганка Трофимовна (1910 елгы, Укр. ССР, Днепропетровская обл., (дер. Косивка). Чынык авылы» дигән мәгълүмат язылган. Аңлашылуынча, әлеге кульязманы А.Фәтхи Актаныш районының Чынык авылында яшәгән Г.Кравецтан алган. Ләкин төгәл елын күрсәтмәгән. Фәтхинең язмаларыннан ачыклануынча, ул Чынык авылында 1970 елгы археографик экспедициясендә (9 июльдән 14 сентябрьгә кадәрге арада) булган. А.Фәтхинең үз мәкаләләрендә һәм интервьюларында, шулай ук «Нуры содур»га багышланган хезмәтләрнең берсендә дә әсәрнең бу фрагменты телгә алынмаган. Ягъни, ул фән өчен билгесез кала килгән. Бу күчермәне шартлы рәвештә «Актаныш» дип исемләдек.

Уналтынчы кульязма фрагменты Татарстан Республикасының Милли китапханәсе тарафыннан Арча районына 2022 елда оештырылган археографик экспедициядә (җитәкчесе – Айрат Заһидуллин) Наратлык авылында Әнисә Сафинадан 10 сентябрь көнендә алынган. Аның «Нуры содур» поэмасының фрагменты булуы безнең тарафтан ачыкланды. Бу истәлек хәзерге вакытта китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «6348т» шифры белән саклана. Ул XVIII гасырның икенче яртысында күчерелгән китапның 16х21 см зурлыгындагы бер кәгазеннән гыйбарәт. Текст мәйданы 10,5х15,3 см тәшкил итә һәм ул нәстәгъликъ төрендә, көрән төстәге язу карасы белән, бер битендә 16, икенчесендә 17 юл күләмендә

теркәлгән. Икенче баб исеме кызыл кара белән язылган. Хаталары аз. Тексты «Нуры содур»ның 133–165 нче бәйтләренә туры килә (барлыгы 33 икеюллык). Кулъязма турында кыскача мәгълүмат бирелеп, фоторәсеме басылган иде[129]. Бу күчермәне «Наратлык» дип атадык.

«Нуры содур»ның унҗиденче күчермә фрагментын Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә археограф Сәед Вахиди туплаган кулъязмаларны өйрәнгәндә, 2024 елның 16 декабрендә ачыкладык. Ул китапханәдә «8480т» шифры белән саклана торган, XVIII гасыр башына караган, төбе ак җеп белән тегелгән җыентыктагы бер кәгазьнең ике ягына (4а, 4б) гарәп язуының нәсех төрендә, караңгы көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. 16х20 см зурлыгындагы һолланд кәгазенең филигранендә Амстердам шәһәренең гербы сурәтләнгән һәм ул 1700 нче елга карый. Язу юллары 4а кәгазьдә ундүрт (башындагы өч юлы намаз турындагы башка текст), 4б кәгазьдә унҗиде; текст язылган мәйданы 12х15 см. Хаталары аз. Тексты бу китаптагы 654–684 нче бәйтләргә туры килә, барлыгы – 31 икеюллык. Сакланышы уртачадан түбән: аерым юллары язу карасы белән үтәли тишкәләнгән. 4б кәгазенең уң читендә соңгырак чорга – XVIII гасыр ахырына караган язмалары бар: «Сәйфулла, Сәйфулла Корманай угылыдыр. Рабигыль-әүвәл ... Казан намиснасының»[130]. Җыентыкның 2а кәгазендә карандаш белән латин хәрефләрендә «Кыртапа» дип язылган. Бу язу, ихтимал, Сәед Вахиди кулы белән теркәлгәндер һәм ул кулъязманың табылган урынын белдерә дип аңладык. Сәед Вахидинең хәзерге Татарстандагы Кама Тамагы районы Кыртапа исемле авылда булганлыгы безгә мәгълүм түгел. Үзе анда бармаса да, бу кулъязманы шул авылдан алып килеп тапшырганнардыр. Бу күчермә фрагменты алга таба «Вахиди» кулъязмасы дигән шартлы исем беләнискә алыначак.

---

[129] Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2022. – Б. 198.

[130] *намиснасы* – наместничествосы, ягъни губернасы.

Гомуми бер нәтиҗә ясасак, кульязмаларның уналтысы уртача форматлы кәгазьләрдә, шигъри икеюллыклары парлы багана итеп теркәлгән, ә берсе – Ижевск нөсхәсе – кече форматлы кәгазьдә бер баганалы шигъри юллар итеп язылган.

«Нуры содур» күчермәләренең башы һәм ахыры (тулы текстлы диярлек) булганнары икәү (Югары Курса, СПб-1). Исәнбәт нөсхәсен дә боларга кушып карарга ярыйдыр. Әсәрнең башы һәм төп өлеше булып, ахыры сакланмаганы – Олы Мәңгәр күчермәсе. СПб-2 нөсхәсенең дә башыннан өч бәйте генә юк. Әсәрнең шактый күләмдәге төп өлеше һәм ахыры өч күчермәдә: Сарман, Уразай, Урта Шөн кульязмаларында бар. Текстлары аз күләмле (иң күбе – 52, иң азы – 31 бәйтле) булган Музей, Актаныш, Наратлык һәм Вахиди күчермәләрен фрагмент дип атау дөресрәк. Соңгылары уңаеннан Мөхәммәдьяр әсәрләрен киләчәктә дә эзләү, «гыйльми китапханәләрдә, архив һәм музейларда тупланган кульязма мирасыбызны җентекләп тикшерү уңай нәтиҗә бирергә мөмкин, тулы текстлары булмаса да, өзекләр рәвешендәге фрагментар күчермә нөсхәләре табылуы мөмкин»[131], – дип, моннан егерме ел элек язылган юлларны искә төшерү урынлы булыр. Чынлыкта да, Урта Шөн, Музей, Актаныш һәм Вахиди күчермәләре нәкъ менә тәфсилләп тикшерү нәтиҗәсендә ачыкландылар.

[131] Мәрданов Р. Бу китап хан догасы... – 2005. – № 7. – Б. 166.

«Нуры содур» поэмасы теркәлгән күчермәләр
(хронология буенча)

| *№* | *кулъязманың шартлы исеме* | *күчерелгән вакыты* | *саклана торган оешма исеме* |
|---|---|---|---|
| 1. | Музей | XVII г. уртасы | Татарстан Республикасы Милли музее (Казан) |
| 2. | Вахиди | филигрань «1700» | КФУ Фәнни китапханәсе (Казан) |
| 3. | Олы Мәңгәр | XVII г. ахыры – XVIII г. башы | ТФА Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘһСИ, Казан) |
| 4. | Уразай | филигрань «1701–1710» | Татарстан Республикасы Милли китапханәсе (ТР МК, Казан) |
| 5. | Югары Курса | филигрань «1739» | ТР МК (Казан) |
| 6. | Ижевск | филигрань «1748–1756» | ТР МК (Казан) |
| 7. | СПб-3 | XVIII г. III чиреге | РФА Көнчыгыш кулъязмалары институты (ККИ, С.-Петербург) |
| 8. | Исәнбәт | XVIII г. III чиреге | Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивы (Казан) |
| 9. | Наратлык | XVIII г. II яртысы | ТР МК (Казан) |
| 10. | Урта Шөн | XVIII г. II яртысы | КФУ Фәнни китапханәсе (Казан) |
| 11. | Яңа Аккуҗа | XVIII г. соңгы чиреге | ТӘһСИ (Казан) |
| 12. | СПб-1 | XVIII г. соңгы чиреге | ККИ (С.-Петербург) |
| 13. | Уфа | [XVIII г.] | Башкортстан Республикасының Ә.-З. Вәлиди ис. Милли китапханәсе (Уфа) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14. | СПб-2 | 1800 ел | ККИ (С.-Петербург) |
| 15. | Барда | филигрань «1811» | КФУ Фәнни китапханәсе (Казан) |
| 16. | Актаныш | 1838 | КФУ Фәнни китапханәсе (Казан) |
| 17. | Сарман | XIX г. II яртысы | Болгар Ислам академиясе (Болгар) |

Бу таблицадан күренүенчә, «Нуры содур»ның хәзергәчә төрле дәрәҗәдә сакланган күчермәләренең күпчелеге XVIII гасырныкы, өчесе исә XIX гасырга карый. Бу, үз нәүбәтендә, «Нуры содур» поэмасы элеккерәк чорда күбрәк күчерелгән һәм таралган дип нәтиҗә ясарга нигез булып тора. XVI–XVII гасырларда булган күчермәләре тарихи һәм табигый сәбәпләр аркасында юкка чыккан[132].

XIX гасырда исә борынгы чорның әлеге әсәренә игътибар кими төшкән дип фаразларга мөмкин. Чөнки XIX гасыр татар кульязмаларының, гомумән, күбрәк сакланганлыгын исәпкә алганда, әгәр дә «Нуры содур» ул чорда күпләп күчерелгән булса, хәзерге вакытка кадәр ирешкән нөсхәләре тагын булыр иде. Татар кульязма китабының тарихында борынгы әсәрләр репертуары үзгәреп торганлыгы: аерым әсәрләр (мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф») киң таралыш алганлыгы, ә кайберләре азлыгы турында археограф Альберт Фәтхи дә әйткән[133].

[132] Гомумән, татар кульязма истәлекләренең XVIII гасырдан элеккерәк чорларда иҗат ителгәннәре аз сакланып калганлыгын һәм аның сәбәпләрен, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының да өч йөздән артык күчермәләре барысы да диярлек XVIII һәм XIX гасырлардагы кульязмаларда сакланган, ә XVII гасырга караганнары берничә генә дип язган идек (Мәрданов Р. Гарәп хәрефле..., 2024. – Б. 31).

[133] Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Тамга» нәшр., 2007. – Б. 146.



اول نبوت معدنينك جوهري — اول رسالات تنكزينينك گوهري
جناب معراج صدر انبيا — فخر عالم چور رسولى مصطفى
اول مبارک لفظی لا ایدی ادنی — ایشتینکیز بو ایودرایغان سوزنی
تعظیم برلا ایتاليم سز سما آتنی — غیب قیلمانکیز بو سوزدا ایزمنی
آدم اغلی اویغانی ب قوبپارهان — هر صباح یاتقان یریندین اناکهان
تیلکا ایتور بو تموغ اندا ملاری — حال تلی برلا ایتیتکیل هریری
کیم ایرور سین بن کا ای تیل سین اولوغ — سین توزاتسانک توزاتور بز تموغ
ایکری بولسانک سین توزاتماغدین ای تیل — بارچه میز ایکری بولور میز آنی بیل
بیز کیلیا بشقا بیل تیلدین کیلور — آدمیغه نه که قیلسه تیل قیلور
لشی یلغان سوزنیله تابماس نجات — توغری سوز برلا تابار دایم حیات
بر حکایت تنکلا ایمدی ای اولوغ — سوزلارینی تعظیم قیلا یین قموغ
بر زمان اچندا بار ایردی مکره — بر سلطان ایشتینکیز بو خبر
اوغلی حالین تیلدی انلارغه بیان — فکر قیلدی بیک وزیرلار ااول زمان

زمان

*Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана торган күчермә фрагменты («Музей»)*



*Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана торган күчермә фрагменты («Вахиди»)*



بسم الله الرحمن الرحيم

*Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгендә саклана торган күчермә («Олы Мәңгәр»)*



*Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган күчермә («Уразай»)*



*Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган күчермә («Югары Курса»)*



*Россия Фәннәр академиясенең С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кулъязмалары институтында саклана торган күчермә («СПб-3»)*


34

بو حدیث منی سن آنکلا ییکت

هر کم تورتنی تیلنی تقو تدلدی اول

تیلنی تورتماغان اوشنی تورتبدلدی اول

چون ایشتتی ایرسا لالاسی بو حادث

شاه سقونچی تیو باردی اول زمان

شاه سقونو بیردی خلعت لار آنکا

ایدی کیم شاه ۱۷۵ آدمی کیلتور منکا

کیلدی ایرسا شاه ۲۰۱۵۰ اوزینکا

منتظر ایردی شاه آنینک سوزی ینکا

نچه کیم شاه لطف ایتب سوزدی سوزین

*Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә*
*саклана торган күчермә («Ижевск»)*



*Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган күчермә фрагменты («Наратлык»)*



*Казан федераль университетының*
*Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана*
*торган күчермә («Урта Шөн»)*



*„Нуры сыдур“ кулъязмасының 4 нче бите*

*Нәкый Исәнбәт күчермәсе*



*Россия Фәннәр академиясенең С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кульязмалары институтында саклана торган күчермә («СПб-1»)*



*Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгендә саклана торган күчермә («Яңа Аккуҗа»)*



*Россия Фәннәр академиясенең С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кульязмалары институтында саклана торган күчермә («СПб-2»)*



8

اول حرم ایچره شاه بیوردی آنکا کیم
سن تقی هم بو سوزنی اغیل ای حکیم

ایمدی منکا تیکدی نوبت ایتایم
بو وزیرلار سوزینی شرح ایتایم

سوزوم اولدر عادل قیلسنکا ایلکا سز
کم آنکل خبرینی سوزیکره بلکای سز

بو وزیرلار سزکا ایغان سوزنی قموغ
عدل ایچنده حاصل اولغای ای اولوغ

ایتایم بارچه سنی خوش تنکلا نکیز
فکر ایتیب شاه عالم آنکلا نکیز

عدل بیرله ایل عمارت بولغای اوش
اول عمارت دنیا کیلور کوب مال خوش

توتوب آنکل سوزنی شاه جهان
عدل قیلوب آشلادی نوشیروان

عدل بیرله توتدی دنیا قموغ
تا نیدی عدل بیرله کیچک هم اولوغ

بولدی معمور ایل لاری بارچه روان
هیچ خراب یر قلمادی آنکلا جوان

کیوداریره ایل اولوسی ودنیا کون کیشی
حال توره آلتون کموش یاندی قشی

کافر ایردی عدل قیلدی ایرمیان ی
سوزلانور موکون جهاندا اوشبو سوز

ایکنجی باب رحیم شفقت سوزلارنی بیان قیلور

رحیم شفقت قیلغوچی عالم ایچره خوش
لطفینکز دنیا توتار امید بارچه اوش

یارلی ایلکا رحیم و شفقت قیلغای سز
تنکری دینکا آنلاردن رحمت بولغای سز

کم آسایش قیلغان ایل اولوش قموغ
راحت ایچره تینغان اول کچیک اولوغ

تنکلانکز سوزوم بارچه اوش تمام
رحیم و شفقت قیلغای سز مدام

رحیم شفقت بیانینی یاد ایتایم
اهل ایمان کونکلونی شاد ایتایم

حق تعه

*Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана торган күчермә («Барда»)*



*Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана торган күчермә фрагменты («Актаныш»)*



*Болгар Ислам академиясендә саклана торган күчермә («Сарман»)*

«Нуры содур» поэмасы теркәлгән кулъязмаларның табылган еллары һәм урыннары, ачыкланган вакытлары (ачыклау елы буенча хронологик тәртиптә)

| № | *кулъязманың шартлы исеме* | *табылган һәм ачыкланган елы* | *табылган урыны* | *кем тарафыннан ачыкланган* |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Исәнбәт | 1940 | Казан шәһәре | Нәкый Исәнбәт |
| 2. | СПб-3 | 1890 (1948)[134] | [Урта Азия] | Бәкер Яфаров |
| 3. | СПб-2 | 1934 (1957) | Татарстанның Әтнә районы | Габдуллаҗан Могыйнов |
| 4. | СПб-1 | 1940 (1959) | [Татарстан] | Г.Могыйнов |
| 5. | Уфа | [1960 нчы еллар] | [Башкортстан] | [Эргаш Фазылов] |
| 6. | Музей | [1960 нчы еллар] | [Татарстан] | Зәйнәп Максудова; Раиф Мәрданов (2012) |
| 7. | Барда | 1974 | Пермь өлкәсенең Барда районындагы Каенавыл авылы | Миркасыйм Госманов |
| 8. | Яңа Аккуҗа | 1978 | Татарстанның Әгерҗе районындагы Яңа Аккуҗа авылы | Марсель Әхмәтҗанов |
| 9. | Сарман | 1992 | Татарстанның Сарман районындагы Сарман авылы | Дамир Гарифуллин |

[134] Кулъязманың табылган һәм ачыкланган еллары төрлечә булганда, ачыклану елы җәяләр эчендә күрсәтелде.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10. | Олы Мәңгәр | 1994 | Татарстанның Әтнә районындагы Олы Мәңгәр авылы | М.Әхмәт-җанов |
| 11. | Уразай | 1999 | Татарстанның Кукмара районындагы Уразай авылы | Р.Мәрданов |
| 12. | Ижевск | 2004 | Удмуртия Республикасының Ижевск шәһәре | Р.Мәрданов |
| 13. | Урта Шөн | 2002 (2009) | Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Урта Шөн авылы | Р.Мәрданов |
| 14. | Наратлык | 2022 | Татарстанның Арча районындагы Наратлык авылы | Р.Мәрданов |
| 15. | Югары Курса | 2024 | Татарстанның Арча районындагы Югары Курса авылы | Р.Мәрданов |
| 16. | Актаныш | 1970 (2024) | Татарстанның Актаныш районындагы Чынык авылы | Альберт Фәтхи; Р.Мәрданов (2024) |
| 17. | Вахиди | 1930 нчы еллар (2024) | Татарстанның Кама Тамагы районындагы Кыртапа авылы | Р.Мәрданов |

Әлеге таблицадан күренгәнчә, «Нуры содур»ның бер күчермәсе XIX гасырда, уникесе XX гасырда һәм дүртесе XXI гасырда табылган.

«Нуры содур» күчермәләренең табылган урыннары билгеле булганнары буенча нәтиҗә ясаганда, аларның берсе Ка-

зан шәһәрендә, алтысы Казан арты районнарында, өчесе төньяк-көнчыгыш төбәкләрдә (Әгерже, Ижевск, Барда) табылган. Боларны бергә кушып караганда – 10 кулъязма – димәк, күпчелеге Татарстанның күбрәк төньяк өлешендә һәм төньяк-көнчыгыштагы Ижевск, Барда якларына нисбәтле. Икесе Татарстанның көнчыгышында һәм берсе шул якка чиктәш Башкортстанда. Бер күчермә республиканың Тау ягында – Кама Тамагы районында табылган.

Татар кулъязма истәлекләренең таралыш географиясе төгәл нәтиҗәләр ясап, фикер йөртергә шартлы рәвештә генә нигез була ала. Чөнки кулъязмалар күчерү күбрәк мәдрәсәләр эшчәнлеге белән тыгыз бәйле булган. Ә Казан артындагы татар-мөселман уку йортларына төрле, хәтта бик ерак төбәкләрдән дә килеп белем алганнар. Шәкертләр үзләре мәдрәсәдә укыган вакытта күчереп язылган әсәрләрне туган төбәкләренә алып киткәннәр. Ләкин «Нуры содур» күчермәләренең шактый өлеше Казан артында табылу факты – әлеге төбәкнең Казан ханлыгы чорында татарлар яшәгән төп үзәкләрдән берсе булуы һәм Казан яулап алынганнан соң татар халкының күпчелек белем йортлары шунда урнашканлыгы белән аңлатыла.

«Нуры содур» әсәре таралыш алган төбәкләр турында М.Әхмәтҗановның фикерен искә алырга кирәк. Ул «Мөхәммәдьярның әсәрләре язылган кулъязмаларның табылу географиясенә күз салсаң, алар хәзерге Татарстанның күбрәк көнчыгыш төбәкләрендә табылалар: Татарстанның Актаныш, Сарман, Әгерже, Әтнә төбәкләре һәм Пермь өлкәсенең Барда төбәге. Бу җирләр, Әтнә төбәгеннән башкасы, XV–XVI гасырларда татарларның Нугай урдасы карамагында булганнар»[135], – дип язган иде. «Нуры содур»ның хәзерге вакытка фәнгә билгеле булган кулъязма күчермәләренең табылган урыннары андый фикерне расламый.

---

[135] Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Идел. 1995. – №11. – Б. 52; Шул ук фикер кабатланды: Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы..., 2000. – Б. 74. Актаныш дигәндә М.Әхмәтҗанов археограф А.Фәтхи тарафыннан табылган күчермәне күздә тоткан дип аңладык.

Алдарак СПб-1 кульъязмасының хаталары аеруча күп дигән идек. Моның дәлиленә йөзләрчә сүзләрне мисал итеп китерергә мөмкин, монда кайберләрен язып үтәбез.

| *тексттагы урыны* | *дөрес варианты* | *СПб-1 кульъязмасында теркәлгән* |
|---|---|---|
| 19 нчы бәйт | олуг | угъ |
| 34 нче бәйт | Кадыйр, Гани | кадугыни |
| 42 нче бәйт | көчсезгә тигермәс | көчсенгә тиклүрмәсен |
| 81 нче бәйт | табар | шийар |
| 143 нче бәйт | асайыш | эш |
| 146 нчы бәйт | күңүлдә | күлдә |
| 173 нче бәйт | өреттең | үлтүрдең |
| 201 нче бәйт | иртәсе | аркасы |
| 232 нче бәйт | хәләл | хәламил |
| 265 нче бәйт | күзәсе | күзәсиха |
| 330 нчы бәйт | уртасында | аутасында |
| 331 нче бәйт | көмүш | гуш |
| 289 нчы бәйт | вәзире | вәзе |
| 436 нчы бәйт | кәһәфнең | кәминнең |
| 485 нче бәйт | игелүр | әликәр |
| 516 нчы бәйт | мәңа | җәна |
| 538 нче бәйт | мөнбәр | миз |
| 693 нче бәйт | лика | лаек |
| 719 нчы бәйт | тигмә | тикнәм |
| 737 нче бәйт | көчүм | җүм |
| 750, 753 нче бәйтләр | каләм | кыйлым |

Күчермәләрдә булган бөтен хаталар да аерым бер кульъязманы күчергән кешенеке түгеллеген дә онытмаска кирәк. Чөнки язылыштагы хаталарның шактые, гадәттә, элеккерәк протографлардан күчә-күчә килгән.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, «Нуры содур» поэмасының хәзерге вакытта фәнгә мәгълүм кульязма күчермәләрендәге текстлар төрле күләмдә һәм алар сакланышлары, шулай ук имлялары төрле дәрәҗәдә булуга карамастан, һәрберсе кыйммәтле ядкәр. Һәр кульязма истәлек уникаль, алар әсәрнең текстына нинди дә булса яңалык өсти һәм төгәллек төсмере бирә.

## Кульязмалардагы текстлар күләме

«Нуры содур»ның авторы Мөхәммәдьяр текстның 778 нче бәйтендә үзе иҗат иткән әлеге әсәрнең күләме «Сикез йөз иллек биш бәйт» дип белдергән. Ә хәзерге вакытта «Нуры содур»ның билгеле бәйтләренең, ягъни икеюллыкларының саны 794. Димәк, автор әйткән 855 бәйтнең 61 икеюллыгы мәгълүм түгел. Әсәр ахырындагы, күчерүчеләр тарафыннан үзгәртелгән һәм 1668/1669 елны белдергән икеюллыкны да өстәп караганда, барлыгы 795 бәйт билгеле һәм автор әйткән саннан 60 икеюллык мәгълүм түгел дип тә исәпләргә мөмкин. (1668 ел язылган икеюллык турында мәкаләбез башындарак сүз булды). Ләкин ул икеюллык шактый үзгәртелгәнгә күрә, аны хәзергә исәпкә кертмәдек.

Бу катлаулы мәсьәләнең торышын күзаллап үтик. Мөхәммәдьяр әсәрләренең тәнкыйди текстлары буларак хәзерләп чыгарылган 1997 елгы басмада «Нуры содур»ның барлыгы 792 икеюллыгы урын алган. Китапның аңлатмалар өлешендә «...чынлыкта исә анда 786 бәйт – 1572 шигъри юл. Ягъни, 69 бәйткә – 138 шигъри юлга ким» дип язылган[136]. Димәк, китапны төзүче Ш.Абилов «Нуры содур» әсәре текстының ахырындагы 6 икеюллыкны исәпкә кертмәгән. Һәрхәлдә, ул китаптагы саннан бер бәйтне киметергә кирәк. Чөнки 1997 елгы китапта бер төрле үк икеюллык ике мәртәбә 52 һәм 56 нчы бәйтләрдә (СПб-2 күчермәсенә ияреп) кабатланган.

Поэма ахырындагы икеюллыкларны Ш.Абиловның исәпкә кертмәвен хупламыйбыз. Чөнки текст ахырындагы берничә

[136] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 306.

икеюллык, колофоннарга хас шигъри бетем рәвешендә булса да, 793 нче бәйттәге «әһле дилләрдин» сүзтезмәсе һәм 794 нче бәйттәге «Тәмам булды «Нуры содур» китабы» дигән юл Мөхәммәдьяр әсәреннән аерылгысыз икәнлеген күрсәтә. Әсәр текстының ахыргы өлеше сакланган бөтен кулъязмаларда да соңгы бәйтләренең тотрыклы булуы – аларны кайсыдыр бер дәвердә күчерүчеләр өстәгән дип уйларлык нигез бирми.

Әсәрнең 1999 һәм 2004 елларда табылган кулъязма күчермәләрендә 1997 елгы тәнкыйди текстка кермәгән дүрт бәйте барлыгын ачыклап һәм аларның тәнкыйди текстта булырга тиешле урыннарын күрсәтеп язган идек[137]. Әлеге дүрт бәйт безнең шушы китаптагы 301, 320, 606 һәм 642 нче икеюллыклар. Алар поэма тексты теркәлгән кулъязмаларның кайберләрендә тулаем һәм өлешчә бар. Ягъни, Уразай, Олы Мәңгәр, Сарман күчермәләрендә дүртесе дә, Югары Курсаныкында өчесе (301, 320, 642 бәйтләр), Ижевск һәм Барда кулъязмаларында өчесе (320, 606, 642 бәйтләр) бар. Соңгы ике күчермәнең битләре сакланмаганга өзеклекләр булганлыктан, берсе билгесез. СПб-2 күчермәсенең тексты сакланган кадәр өлешендә 301 һәм 320 нче бәйтләр теркәлгәнлеген күрәбез. Шулай ук текстларының сакланган өлешләрендә Урта Шөн белән Яңа Аккуҗа кулъязмаларында 606 һәм 642 нче икеюллыклар бар. Болардан Яңа Аккуҗа нөсхәсендә 606 нчы бәйт кызыл кара белән язылган.

Шунысы да мөһим – 1997 елда басылып чыккан тәнкыйди текст өчен нигез итеп алынган СПб-1 кулъязмасының 51а кәгазендә 320 нче бәйт хатасыз-нисез теркәлгән. Шулай ук тәнкыйди текстны басмага хәзерләгәндә Ш.Абилов файдаланган Сарман кулъязмасында бәйтләрнең дүртесе дә, Барда нөсхәсендә өчесе, СПб-2 күчермәсендә икесе була торып, ни сәбәптәндер, кертелмичә калдырылганнар һәм алар турында искәрмәдә берни дә әйтелмәгән.

---

[137] Мәрданов Р. Бу китап хан догасы... – 2005. – № 7. – Б. 164–166; Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы..., 2009. – Б. 8–9.

Кулъязма текстлар эчендә шул ук дүрт бәйтнең бөтенләй теркәлмичә калганнары: СПб-1 күчермәсендә 301, 606 һәм 642 нче икеюллыклар төшеп калган, Югары Курса кулъязмасында һәм Уфаныкында 606 нчысы теркәлмәгән. Менә бу мәгълүматларга нигезләнеп фикер йөрткәндә, сүз бара торган дүрт икеюллык әсәр күчермәләренең күбесендә булганга күрә, алар һич тә күчерүчеләр өстәмәсе түгеллеге, ә автордан ук килгәнлеге аңлашыла.

301 нче бәйтнең бүтән кулъязма нөсхәләрдә төшеп калуына һәм, нәтиҗәдә, 1997 елгы китапка кертелмәвенә, күрәсең, янәшәсендәге өч икеюллыкның да (300–302), шулай ук 320 һәм 321 нче бәйтләрдә дә нәкъ шундый ук «Кем газа...» сүзләре белән башланулары сәбәп булган. Ягъни, янәшәдәге бәйтләрнең бер төрле сүзләрдән башлануына карап, текстны күчергән кешеләр, ул бәйтне күчерелде дип исәпләп, төшереп калдырганнар. Шуңа охшаш фаразны 642 нче бәйткә карата да әйтергә мөмкин, 641 нче бәйт «Гафир» дип, ә 642 нчесе «Гафу» дип башланган. Язылыштагы охшашлыкларга күрә, әсәрне күчергән кешеләр буталганнар һәм текст шул хәлендә бер кулъязмадан икенчесенә күчеп килгән.

«Нуры содур» поэмасының яңа бәйтләре ачыклану фәнни яктан, һичшиксез, зур әһәмияткә ия иде[138].

Поэма тексты сакланышының тулылыгы җәһәтеннән караганда, бәйтләр санының гомуми күләме һәм алар эчендәге төшеп калганнары түбәндәгечә.

---

[138] Марсель Әхмәтҗанов «Нуры содур»ның 1978 елда үзе тапкан кулъязмасында да яңа строфалары булуы турында язды. (Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Идел. 1995. – №11. – Б. 51; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы..., 2000. – Б. 71). Ләкин ул 1966 елгы (кыскартылган – әсәрнең 2/3 өлешеннән кимрәк чыккан) басмада булмаган строфаларны күздә тоткан.

## «Нуры содур» поэмасы теркәлгән күчермәләр
## (текст күләме буенча)

| № | *кульъязманың шартлы исеме* | *беренче һәм соңгы бәйтләре* | *Текст эчендә төшеп калган һәм өзеклек кергән икеюллыклары* | *текст күләме (икеюллыклар саны)* |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Югары Курса | 1–794 | 355, 528, 606, 645, 722 | 789 |
| 2. | СПб-1 | 1–794 | 76, 102, 126, 271, 301, 585, 606, 642, 671 | 786 |
| 3. | Сарман | 29–794 | 46, 188, 241, 341, 476, 492, 585, 603, 685 | 760 |
| 4. | Олы Мәңгәр | 1–732 | 223, 241, 476, 585, 685, 724 | 726 |
| 5. | Исәнбәт | 1–794(?) | *билгесез* | 623 |
| 6. | Ижевск | 152–774 | 229 (икенче юлы)–239 (беренче юлы), 298–307, 397–405, 649, 707–715 (беренче юлы) | 574 |
| 7. | Барда | 16–717 | 55, 87, 210–310, 426, 466, 476, 510–543, 566, 584, 591, 592, 685 | 561 |
| 8. | СПб-2 | 4–569 | 125, 241, 410, 476, 518, 565–568 | 554 |
| 9. | Уразай | 268–794 | 470, 471, 476, 485, 486, 563, 564, 585, 586, 685, 726, 742 | 516 |
| 10. | Урта Шөн | 417–794 | 476, 585, 685 | 374 |
| 11. | СПб-3 | 158–706 | 166, 245–322, 329, 350, 355, 386–446, 496–653, 683–685, 687 | 242 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12. | Яңа Аккуҗа | 498–668 | 525–549, 576, 596 | 143 |
| 13. | Уфа | 500–607 | 606 | 107 |
| 14. | Музей | 448–499 | | 52 |
| 15. | Актаныш | 497–529, 563–574 | 517, 571 | 43 |
| 16. | Наратлык | 133–165 | | 33 |
| 17. | Вахиди | 654–684 | | 31 |

Югары Курса кульъязмасында биш бәйтнең теркәлмәгән булуы, башка күчермәләр белән чагыштырганда, иң азы. Чөнки тексты тулы дип исәпләнгән СПб-1 нөсхәсендә тугыз икеюллык төшеп калган. Шактый тулы күчермәләрнең сакланган текстлары эчендә җитешмәгән бәйтләр байтак, мәсәлән, Сарманныкында – 9, Барданыкында – 10-нан артык.

Монда язылганнардан тыш, кайбер күчермәләрдә бер үк икеюллыкның ялгыш кабатлап язылган урыннары һәм янәшәдәге ике бәйтнең юллары (берсенең беренче юлы һәм икенчесенең икенче юлы) бергә кушылып, бер икеюллыкны тәшкил итеп, калган өлешләре бөтенләй теркәлмичә калган очраклар бар. Мәсәлән, СПб-2 кульъязмасындагы кабатланган бер үк икеюллык 52 һәм 56 нчы бәйтләр буларак 1997 елгы басмага да күчкән. Шул ук бәйт Олы Мәңгәр күчермәсендә дә кабатланган. Олы Мәңгәр, Барда һәм Сарман нөсхәләрендә 121 нче бәйт 125 нче бәйттән соң һәм 183 нче бәйт тагын бер бәйт аша кабатлап язылган. Сарман күчермәсендә 362 белән 363 нче бәйтләр, 470 һәм 471 нче бәйтләр бергә кушылганнар[139]. Кульъязмаларда хаталы теркәлеп сызылган бер һәм икеюллыклар да бар.

[139] Кульъязмалардагы икеюллыкларның кабатланулары һәм урыннары төрлечә булуы, шулай ук сүзләрдәге үзгәрешләр турында галимнәр дә искәртте. Мәсәлән, Э.Кадыйрованың күрсәтелгән хезмәтендә болар турында 14–21 нче битләрдә язылган. Бу мәсьәләгә 2009 елда безнең тарафтан хәзерләп бастырылган китапта да игътибар ителде.

«Нуры содур» текстының автор белдергән күләмнән, ягъни 855 бәйтнең 61 икеюллыгы билгесезлеге хәзергәчә ачыкланмаган мәсьәлә булып кала бирә. Әсәрнең мәгълүм булган 17 күчермәсендә, алда әйтеп узылган өстәмә дүрт бәйттән башка, текстны тулыландырырлык бүтән өлешләре юк.

Һәрхәлдә, 61 икеюллык күләмендәге текст билгесез булса да, поэманың бөтенлегенә зур зыян килмәгән. Чөнки әсәрнең исеме, авторы һәм иҗат ителгән датасы кебек мөһим мәгълүматлары, эчтәлегенең башы, ун бүлектән торган төп өлеше һәм бетеме ачык билгеле. Һәрхәлдә, «Нуры содур»ның тугыз күчермәсен тасвирлап язган Э.Кадыйрова әйткәнчә, «күчермәләренең берсе дә тулы түгел»[140] дип, төшенкелеккә бирелү урынсыз. Мондый очракта, булганына шөкер итү дөресрәк. Бер заман әлеге мәсьәләгә дә ачыклык керүе ихтимал.

Хәзергә исә җитмәгән икеюллыклары турында кайбер фаразлар гына кора алабыз. Мәсәлән, Шакир Абилов әсәрнең 128 нче бәйтенә карата «бу бәйттән алда яуга чыгуның яки нәрсәдер өчен барлык халыкның яуга баруын сөйли торган берничә шигъри юл булырга тиешлеге аңлашылса да, текстта алар юк...»[141], – дип, өзеклек кергән булуы мөмкинлеген искәрткән.

Без дә әсәрнең шул ук Нәүширван хикәятендә текст өзеклеге бардыр дип фараз итәбез. Анда сөйләнгәнчә, Нәүширван җиде вәзирен киңәшкә чакырган. 119 нчы бәйттә аларның «һәрберебез бер сүз әйтәбез» дигәннәренә караганда, бөтенесенең киңәш сүзләре текстта чагылырга тиеш кебек. Ләкин текстта ике вәзирнең генә киңәше язылып, өченчесе шунда катнашкан «хәким» сүзе буларак тасвирланган. Әлеге хәкимне аерым бер кеше буларак күзалласак, тагын 5 вәзирнең киңәш сүзләре билгесез дип аңларга мөмкин бит. Бу урында сүз сөрешен автор үзе шулай корганмы, әллә текстка өзеклек кергәнме дигән сорау туа. Бәлки, текстның җитешмәгән бәйтләренең бер өлеше шушы урында булгандыр дип гөманлый алабыз. Өстәвенә, 130 нчы бәйттә:

---

[140] Кадирова Э. Поэмы Мухаммедьяра..., 2001. – С. 14–16, 126.

[141] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 303.

Ул дәм эчрә шаһ бойурды аңа кем:
«Сән тәкый һәм бер сүз айгыл, әй, хәким!»

– дип әмер итү турындагы юлларда «боерды аңа» гыйбарәсе, гүяки, бу хәким турында алдарак нәрсәдер язылган дигән мәгънә төсмеренә дә ия.

Автор иҗат иткән текст вариантын иң беренчеләрдән күчергән кешеләр тарафыннан ук аерым урыннары ниндидер сәбәп белән төшереп калдырылган дип тә уйларга ярый. Чөнки билгеле булган текстларда зур аермалар юк. Әсәр текстындагы 30 нчы бәйттән соң язылган дога сүзләренең бер өлеше, бәлки, иң беренче чорда күчерелгән вакытта төшеп калгандыр. 30 нчы бәйттән соң искәрмә рәвешендә теркәлгән «Пәйгамбәр галәйһиссәламгә дога әйделәр» гыйбарәсе, бер яктан карaганда, шулай уйлау өчен нигез бирә кебек. Дога тексты гарәп телендә булып яисә аеруча катлаулы гыйбарәләрне тәшкил иткәнгә, аны күчермичә, искәртеп кенә үткән булулары ихтимал. Шуңа охшаш хәл – әсәрнең баб-бүлек башларында гарәп телендә язылган Коръән аятьләренең һәм хәдисләрнең бөтен күчермәләрдә дә булмавы әйтелгән фаразны куәтли.

Һәрхәлдә, «Нуры содур»ның билгеле күчермәләреннән тупланган җыелма текст күләмен хәзергә «тулы текст» дип тану һәм шулай атау дөрес булыр.

## Күчермәләрнең текстологик һәм палеографик үзенчәлекләре

Поэма тексты сакланган кульязмалардан Югары Курсаныкы белән СПб-1 һәм Сарман күчермәләрендәге текстологик уртаклыклар (сүзләрнең язылышларында, хаталарында, палеографик хасиятләрендә һ.б.) күбрәк. Урта Шөн нөсхәсенең тексты да боларга якын. Әсәр тексты ахырындагы фарсыча шигъри икеюллык Уразай, Югары Курса, Урта Шөн һәм Сарманныкында булуы да күчермәләрдәге текстларның охшашлыгын күрсәтә.

Әсәр тексты теркәлгән кульязмаларда охшашлыклар белән бергә аермалы урыннар шактый. Бер үк сүз яки атама төрле

күчермәдә төрлечәрәк язылган. Мәсәлән, *аймас/аймаз, әйде/айды, әйтәйен/әйтәйем/әйтәлем, йуксыл/йуксыз, куни/күнү, күрмәс/күрмәз, тынайым/тынайын* һ.б. Мондый төрлелек һәм гадәти сүзләрне язгандагы орфографик тотрыксызлык мисаллары бик күп. Болардан «күни» һәм «күнү» дигәне бер үк кулъязмада да төрлечә, мәсәлән, Югары Курсаныкында 476, 477, 480 нче һ.б. бәйтләрдә «күни» дип, ә 478 нче бәйттә «күнү» һәм «күнүлек» дип язылган. Шундый ук төрлелек башка күчермәләрдә дә күзәтелә. Шул ук күчермәдәге 504 нче бәйтнең бер юлында «карчыга» диелсә, икенче юлында «карчага» рәвешендә теркәлгән. 289 нчы бәйттәге су (сыв) сүзе кайбер күчермәләрдә «сер» дип язылган. Әсәрнең 367 нче икеюллыгында Югары Курса күчермәсендә «дустлык» дип язылган сүз башка кулъязмаларда «дәүләт» дип теркәлгән. Югары Курса һәм Ижевск кулъязмаларында 536 нчы бәйттәге «Каннух» атамасы Уразай, Олы Мәңгәр, Урта Шөн, Сарман күчермәләрендә «Конуҗ» (Каннуҗ) дип, ә СПб-1 нөсхәсендә «Фатух» рәвешендә теркәлгән. 579 нчы һ.б. икеюллыклардагы бер үк исем Югары Курса, Олы Мәңгәр, СПб-1, Сарман кулъязмаларында «Ибне Әшгат» дип теркәлгән, ә Уразай, Ижевск, Урта Шөн, Уфа һәм Яңа Аккуҗа күчермәләрендә «Ибне Әшгас» рәвешендә язылган. 665 һәм 667 нче бәйтләрдәге «ураза» сүзе кулъязмаларда «уруҗ» һәм «уруч», «руҗ» һәм «рузә» дип, төрлечә теркәлгән.

Тагын берничә мисалга тукталыйк. Поэманың 720 нче бәйтендә «фарсы» сүзе татарча әйтелештәгечә «парсы» дип теркәлгән. Менә шул сүз Югары Курса күчермәсендә «барсы» дип, Уразай, Олы Мәңгәр һәм Сарман кулъязмаларында «парсы» буларак, ә Ижевск нөсхәсендә «парҗасы» рәвешендә бирелгән.

Кулъязмаларда «хан» сүзе шактый очракларда «җан» дип теркәлгән. 754 нче икеюллыктагы «галәм ханы» сүзтезмәсенең икенче сүзе бары тик бер – Ижевск күчермәсендә генә «ханы» дип дөрес язылган. Ә әсәр текстының ул өлеше сакланган биш кулъязмада да (Уразай, Югары Курса, СПб-1, Урта Шөн, Сар-

ман) «җаны» рәвешендә теркәлгән. Моңа охшаш мисалларның тагын берсе – кулъязмаларда (Югары Курса, Уразай, Олы Мәңгәр, Сарман ) «тағәт төнен» дип ялгыш теркәлгән сүзләрнең дөресе бер күчермәдә генә – Ижевск нөсхәсендә «тағәтемне» дип язылган.

Күчермәләрдә «бер» белән «бу», «һәр» белән «һәм», «сән» белән «сез», шулай ук «кем» белән «ки», «уш» һәм «хуш», «үзә» белән «үзрә» төрлечә язылган булулары белән иң беренче урында торалар дисәк, ялгышмабыз. Шулай ук, «төрки» белән «төрк», «бере» белән «берсе», «белә» һәм «берлә», «олыс» белән «өлеш», «һәр» белән «бер», «әй» белән «ул», «бәс» белән «бел», «булгай» белән «булыр» кулъязмаларда еш кына төрлечә теркәлгәннәр.

Кулъязмаларның протографларында «нун» хәрефенең сүз ахырындагы аерым язылышы шикәстә төрендәгечә сузынкы итеп теркәлгән булуына күрә күчерүчеләр аны «ны» яки «не» дип кабул иткәннәр һәм күп очракта шулай күчергәннәр.

Элекке чорда иҗат ителгән әсәрләр хәрәкәләр белән язылган булып, тора-бара алар кулланылыштан төшкән[142]. Ләкин аерым әсәрләрдә хәрәкәләр өлешчә сакланган яки элек кулланылган булуын шәйләргә мөмкин. «Нуры содур»ның бөтен күчермәләрендә дә кайбер сүзләрнең, аерым гыйбарәләрнең һәм җөмләләрнең хәрәкәләр белән теркәлгәнен күрәбез. СПб-2 кулъязмасында гади генә татар сүзләренең кайберләре тулаем хәрәкәләр белән язылган. Элек хәрәкәләр белән язылып, бу күчермәләрдә исә алардан башка теркәлгән сүзләр дә бар. Мәсәлән, Югары Курса һәм Барда кулъязмаларында «әһеле» дигән сүз берничә мәртәбә «әһел» дип теркәлгән, шулай ук «сүзене» дигән гыйбарә «сүзен» дип кенә язылган. Югары Курса кулъязмасында 389 нчы бәйттәге «вәзире» сүзе «вәзир» генә диелгән, 390 нчы бәйттәге «мотигы» сүзе «мотигъ» дип теркәлгән. Соңгысы «СПб-2» кулъязмасында тулаем хәрәкәләр белән язылган. Ягъни, сүз ахырларындагы «ы» һәм

[142] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле..., 2024. – Б. 156–159.

«е»не белдерү өчен иске текстларда «кәсрә» хәрәкәсе куелган булып, кайбер күчермәләрдә теркәлмичә калганнар һәм аларны алыштырырга «йа» хәрефе дә язылмаган. Мондый мисаллар, әлбәттә, тагын да бар һәм алар поэма текстының башлангыч чорда хәрәкәләр белән язылган булуыннан килә.

Архаиклашкан сүзләрне кульъязма күчерүчеләрнең, аңламыйча, бүтән гыйбарә белән алмаштырулары яисә, мәгънәсенә төшенгәндә, андыйларны аңлаешлы сүзләргә үзгәртү фактлары татар археографиясендә билгеле[143]. «Нуры содур» текстында да андый урыннарны күрергә мөмкин. Мәсәлән, 373 нче бәйттәге архаик язылышлы «азрылыб» (аерылып) сүзен күчерүчеләр аңламыйча, аны күпчелек кульъязмаларда (Уразай, Олы Мәңгәр, СПб-2, Барда, Сарман) «арзулаб» (теләп) дип, ә СПб-2-дә аңлаешлы итеп «айрылыб» дип теркәгәннәр. 383 нче бәйттә Сарман нөсхәсен күчерүче башта «көчай» (авыр) дип язып, үзе үк аны сызып, «кичкән» дип төзәткән. 246 нчы бәйттәге «озаккы» сүзе шул ук күчермәдә «әүвәл» диелгән. «Көчай» сүзе Барда нөсхәсендә «күчәр» дип язылган. 534 нче бәйттәге «йарыйур» (нурландырыр, яктыртыр) сүзе Ижевск кульъязмасында «нур ирер» дип теркәлгән. Югары Курса, Ижевск, Уфа һәм Яңа Аккуҗа кульъязмаларында 588 нче бәйттәге «сандәли» дигән сүз Уразай, Олы Мәңгәр, Урта Шөн һәм Сарман күчермәләрендә «мөнбәр» буларак язылган. 65 нче бәйттәге «йаричысы» дигән борынгы сүз Барда нөсхәсендә аңлаешлы итеп «ярдәмчесе» дип, 121 нче бәйттәге «пәнде» (нәсихәте, киңәше) гыйбарәсе «сүзе» дип алмаштырылган. Барда кульъязмасында борынгырак сүзләрне танымыйча, охшаш язылыштагы сүзләр теркәлгән очраклар күп.

Әсәрнең Сахибгәрәй ханны мактаган иң беренче бәйтенә игътибар итик, ул:

Олуг солтан могаззам Сахибгәрәй хан,
Әсаләт берлә ул хан ибне хан,

– дип теркәлгән. «Могаззам» сүзе «бөек», «хан ибне хан»

[143] Шунда ук. – Б. 122.

гыйбарәсе «хан улы хан» дигәнне белдерә. Ә «әсаләт» сүзе «асыллык, затлылык, аксөяклелек, даимилек, какшамас» кебек күп мәгънәләрне үз эченә ала. Менә бу сүз «Нуры содур»ның башка күчермәләрендә (Олы Мәңгәр, СПб-1, СПб-2, Барда) «рисаләт» дип язылган. «Рисаләт» сүзенең төп мәгънәсе – илчелек, пәйгамбәрлек. 1997 елгы тәнкыйди басмада да бу сүз «рисаләт» дип бирелгән һәм тәрҗемәсендә «пәйгамбәрлек» дип тәкъдим ителгән. Татар кульязмаларын күчерүчеләрнең «әлиф» һәм «ра» хәрефләрен ялгыш танып, үзара бутап язган очраклары бик күп. Ләкин Югары Курса нөсхәсендә «әсаләт» сүзендә хата киткән дип булмый. Чөнки андагы «с» хәрефе «сад» белән язылган, ә ялгышкан очракта «рисаләт» сүзендәгечә «син» хәрефе белән теркәлгән булыр иде.

Бер генә кульязмада теркәлгән булса да, мәгънәсе буенча фикер йөрткәндә, «әсаләт»нең дөрес икәнлегенең дәлиле мәгълүм: «рисаләт»-пәйгамбәрлекнең Сахибгәрәй ханга карата кулланылу ихтималы юк. Чөнки ислам динендә соңгы пәйгамбәрнең Мөхәммәд галәйһиссәлам булганлыгы һәркемгә билгеле.

1997 елда чыккан китаптагы 63 нче бәйттә (174 нче биттә) «алари» сүзе кайбер кульязмалардагы «иллә әй» дигәннән – «әй» сүзенең «әлиф» хәрефен күчерүчеләр «р» дип танудан бозылган. Басма өчен СПб-2 һәм Барда күчермәләрендәге ялгыш язылыш кулланылган. Гәрчә бу гыйбарә СПб-1 кульязмасында «иллә әй» рәвешендә – дөрес теркәлгән.

Шул ук китапта 71 нче бәйттәге рифмадаш «дәруазәсендә» һәм тәрҗемәдә «капкасында» дип бирелгән сүзләрнең икенче юлдагысы дөрес түгел. «Дәруазә» сүзе алдындагы «хирә» (тәрҗемәдә: хәйран) дигәне дә ялгыш. Әлеге сүзтезмә күчермәләрдә төрлечә: «хирәд рәвазәсендә» яки «хирә дәрвазәсендә» (Югары Курса, Сарман), «хирад дәвазәсендә» (СПб-1), «хәйердүр вәзасендә» яки «хәйер дүрвазәсендә» (Олы Мәңгәр, СПб-2, Барда) рәвешләрендә теркәлгән. Безнең фикеребезчә, бу бәйтнең икенче юлындагы ахыргы сүзне автор «дәрвазәсендә» дип язмаган. Фарсы телендәге «хирәд»

сүзе «акыл, зиһен, фикер» дигән мәгънәләрне белдерә. «Рәвазәсендә» дип язылган сүзнең беренче хәрефе – «р» күчерүчеләр тарафыннан «әлиф»не ялгыш танып язудан чыккан һәм, нәтиҗәдә, «авазәсендәге» сүзе шулай үзгәргән булса кирәк. «Нуры содур»ның 1966 елгы басмасында (83 биттә) бу сүз шулай «авазәсендә» дип бирелгән булган. Фарсы телендәге «авазә» сүзе – «көй, җыр, шөһрәт, хәбәр» мәгънәләрен белдерә. Ягъни, «Кеше күбдер хирәд авазәсендә» – «Акыллы сүзләр сөйләүче кешеләр күп» дип аңларга кирәк. Бу очракта хикмәтле-мәгънәле сүз осталары – шагыйрьләр күздә тотылган дип гөман итәбез. Чөнки бу шигъри юл Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» текстындагы:

Бер гаҗиб бу шәһәрнең эче тулуг:
Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг»,

– юлларына аваздаш һәм шул ук мәгънәне башкачарак кабатлау дияргә мөмкин.

Кульязмаларның күбесендә (Югары Курса, Олы Мәңгәр, СПб-1, Барда, Сарман) 95 нче бәйт ахырындагы «залим гован» һәм «зольм-ү-гован» дип язылган гыйбарә СПб-2 күчермәсендә «зольм-ү-һәман» дип теркәлгән. Соңгысыннан алынып тәнкыйди текстка (177 нче биттә) «золм һәман» дип бирелгән. Күпчелек кульязмалардагы «гован» сүзенең бер хәрефе – «дәл» төшеп калган һәм ул, дөреслектә,«годван» (дошманнар) дигәнне белдергән. Бу сүзләр кергән шигъри юлның дөресе – «Калмаз илдә фетнә вә зольме годван» (Калмас илдә фетнә һәм дошманнар золымы).

Утынчы турындагы хикәятнең 203 нче бәйтендә «изылмыш балык» сүзтезмәсе бар, аның хәзерге телгә күчермәләрдә «изелгән балык» дип бирелүе ялгыш. Чөнки «изылмыш» сүзе «йызыг» (ис) тамырыннан һәм әйтелгән сүзтезмә «исләнгән балык» дигәнне белдерә. Гарәп хәрефләре белән язылышта сүзнең башында «әлиф» белән белдерелүе – искергән палеографик үзенчәлек. Мәсәлән, элекке текстларда «елан» һәм «ерак» кебек сүзләрнең башларында «әлиф» язылып, «илан», «ирак» (ырак) дип теркәлгән.

«Нуры содур»ның 274 нче бәйтендә хәлифәгә су китергән гарәп турында сүз бара. Ул дөясен җан-фәрманга чаптырып, ниһаять, килеп җитә һәм кулъязмаларның күбесендә «Тәүәдин төшмәс иркән ул би-әдәб» диелгән[144]. Менә бу җөмләдәге «би-әдәб» сүзе «әдәпсез» дигән мәгънәдә аңлашыла һәм текст эчендә ул урынлы да кебек. Ләкин 1997 елгы тәнкыйди басма өчен нигез итеп алынган СПб-1 кулъязмасында бу сүз «йөдәб» дип архаик язылышта теркәлгән. Архаик дигәнебез «ө» авазын белдерү өчен язылган «уау» хәрефеннән соң «әлиф» язылган булуы. Мондый очракта «әлиф» хәрефе «ө» авазының озын әйтелешен белдерү өчен язылган һәм ул «ә» дип укылмый. Мондый палеографик үзенчәлек XIII–XIV гасырлардагы кабер ташларында, борынгырак чорда иҗат ителгән әсәрләрнең кулъязмаларында еш очрый, шулай ук XIX гасырга нисбәтле кайбер текстларда да бар[145]. «Йөдәб» сүзе поэманың контекстына да күбрәк туры килә. Көне-төне йокламыйча, бик ерактан хәлифәгә изге суны тизрәк тапшырыйм дип ашыккан гарәпнең «әдәпсезлеге» мәсьәләсенә караганда, бу очракта аның арып-йөдәп бетүен тасвирлау мөһимрәк.

Бу сүзнең язылышындагы архаиклашкан, озын сузыкларны белдерү өчен кулланылган «әлиф» хәрефе әсәрне күчерүчеләргә инде күптән аңлаешсызга әверелгәнгә, «йөдәб» сүзендәге «әлиф»не «ә» дип укып, «әдәб» сүзе дип кабул ителгән һәм шул рәвешле «би-әдәб» дип бер кулъязмадан икенчесенә күчеп, кабатланып килгән. Әлеге сүзнең Югары Курса, СПб-2 һәм Сарман кулъязмаларында «би-әдәб» рәвешендә теркәлгән булуы гаҗәп түгел.

Моңа охшаш язылышлы тагын бер сүзгә тукталыйк. Әсәрнең икенче бүлегендә Муса пәйгамбәрнең куйлар көтүе тасвирланган. 169 нчы бәйттә «Вакты берлә сөрәр ирдең һәрберен» (ягъни, «Вакыты белән куар идең һәрберсен»)

---

[144] 1997 елгы китапта 190 нчы биттә «би-әдәб» дип басылган сүз текстның 262 биттәге тәрҗемәсендә, ни гаҗәп, «йөдәп» дип бирелгән.

[145] Мәрданов Р. Гарәп хәрефле..., 2024. – Б. 136–138.

диелгән. Мондагы «сөрәр» сүзе Югары Курса, Олы Мәңгәр, Ижевск, СПб-1, Барда һәм Сарман күчермәләрендә ачык итеп «сөрәр» дип теркәлгән. Ә «СПб-2» нөсхәсендә «сөрүр» дип, архаик рәвештә язылган. Ягъни, бу сүздәге «ө» авазын белдергән беренче «уау» хәрефеннән соң «әлиф» язылган. Шушы очракта да «әлиф» хәрефе «ә» яки «а» буларак укылырга тиеш түгел. Бу сүздә архаик язылыш үзенчәлеге булган «әлиф» хәрефе бүтән кулъязмаларда (яисә аларның протографларында ук) төшереп калдырылган.

«Әлиф» белән язылган «сөрүр» сүзе 1997 елгы басмада (231 биттә) СПб-2 нөсхәсе буенча алынып һәм «суарур» дип укылып, «сугару» сүзе нигезендә «су эчерү»гә бәйләп ялгыш аңлатылган. Югыйсә, бу китап өчен төп нигез булган СПб-1 һәм төзүчесе кулланган Барда, Сарман кулъязмаларында шул ук сүзнең «сөрәр» дигән язылышы да теркәлгән бит. «Сөрү» сүзе – «куу» мәгънәсендә хәзер дә аңлаешлы, «сөрген» дигәне дә күп кулланыла. «Нуры содур»да мал-туарны куу мәгънәсендә бу сүз берничә мәртәбә очрый, мәсәлән, 169, 270, 274 нче бәйтләрдә.

Сүзләрдә «ө», «у» һәм «ү» авазларының озын әйтелешен белдерү өчен «уау»дан соң «әлиф» кую әсәр кулъязмаларында тагын да бар. Мәсәлән, 642 нче бәйтнең рифмадаш «гафу» һәм «рафу» сүзләрендә Олы Мәңгәр, Яңа Аккуҗа, Сарман күчермәләрендә ахыргы хәреф итеп «әлиф» язылган. Әлеге сүзләр дә һичничек «гафуа», «рафуа» дип укылырга тиеш түгелләр.

Мондый имля үзенчәлекләре әсәрнең башлангыч нөсхәсендә – автор кулъязмасында шулай теркәлгәннән үк килгәнлеге аңлашыла. Төрки-татарча текстларда озын сузыкларны белдерү өчен элек кулланылган язылышлар Мөхәммәдьяр яшәгән чордан ераклашкан саен палеографик архаизмга әверелгәннәр. Шунлыктан, андый үзенчәлекләрне аңлаучы-белүчеләр сирәгәйгән.

Хәлифәгә су китерү турындагы хикәяттә (289 нчы бәйтнең ахырындагы) гарәпкә карата әйтелгән «бираһ» (адашкан, юл-

дан язган) сүзе кулъязмаларның икесендә (Югары Курса, Ижевск) ачык һәм дөрес итеп теркәлгән. СПб-1 күчермәсендә ул хаталы рәвештә «нәһ», икесендә (Олы Мәңгәр Һәм Сарман) «җөда» диелгән, СПб-2 нөсхәсендә исә «җөдаһ» дип язылган. Тәнкыйди текстка да соңгысыннан алынып, хаталы «җөдаһ» язылышы бирелгән (191 нче биттә) һәм аңлатмасында «җөда» сүзе ахырына «һ»не шагыйрь «шаһ» сүзе белән рифмадаш булсын өчен куйган булса кирәк» диелгән.

Шул ук хикәяттә 293 нче бәйт башындагы сүзләр кулъязмаларда «безне йитеб», «безне тийеб» рәвешләрендә теркәлгән. Ләкин бу сүзләрнең беренчесе, чынлыкта, гарәп телендәге «биэр» (кое суы) булып, гарәп хәрефләре белән язылышта «б» хәрефеннән соң «һәмзә» билгесе күчерүчеләр тарафыннан нокта дип кабул ителгән һәм, нәтиҗәдә, «р» хәрефе «з» дип аңлашылган. «Без тийеб» (яки «без йитеб») сүзтезмәсен камилләштерү өчен «-не» кушымчасын ялгаганнар да хаталы язылыш килеп чыккан. Дөресе – бу шигъри юл «Биэр тәйеб килгән кем ирсә ойалыб» (Изге су дип килгән кеше оялып) рәвешендә булырга тиеш. «Биэр» дигәндә гарәп китергән су күздә тотылган. Зәмзәм суы хәзер дә гарәп телендә «Биэре зәмзәм» дип атала.

Кулъязмаларда 318 нче бәйттәге «алтендә» дип теркәлгән сүз дөреслектә «астында» булырга тиеш. Бу очракта гарәп язуындагы «с» хәрефе авыш итеп язылырга тиешле булып, күбрәк вертикаль рәвешкә кергәнлектән күчерүчеләр аны «л» хәрефе дип кабул иткәннәр.

Әсәрнең җиденче бүлегендәге Шәмгун турындагы хикәяттә 457 нче икеюллыкта:

> «Аның өчүн барчамыз йөк булалым,
> Вәгъдәсе йитсә, әда без кыйлалым»

– диелгән. Бу очракта «йөк» булу сүзе бурычка алучы килешенгән вакытта түли алмаса, аның өчен «йөкче» (поручитель) түләргә тиешле дигән мәгънәгә ия. «Нуры содур» текстында бурычка алу вакытында «йөкче» дип аталган җаваплы кешеләр турында сүз баруыннан – әлеге терминның Казан

ханлыгы чорыннан килгәнлеге ачыклана. Аның башлангычы тагын да әүвәлгерәк заманнан булгандыр[146.]

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләренә җитдирәк игътибар биргәндә, тексттагы кайбер сүзләрнең дөрес укылуына ирешергә мөмкин. Әмма, шул ук вакытта, кулъязмаларда кайбер катлаулы һәм хаталы язылышка ия булган гыйбарәләрнең төп автор текстында ничек булганлыгын төшенү читен.

Поэманың 789 нчы бәйтендәге «мәгъкуль сүзене белгән» дигән гыйбарә бар. 1997 елгы басма өчен нигез итеп алынган СПб–1 кулъязмасында әлеге сүз «могул» дип теркәлгән һәм тәнкыйди текстта да «мугул» дип бирелгән. Бу сүзгә карата искәрмә һәм аңлатмаларда (240, 306–307 нче битләрдә) «Нуры содур»ның бетем өлешендә шагыйрь Лотфиның «Гөл вә нәүрүз» әсәреннән файдаланган булуы тәфсилләп әйтелгән, шул исәптән «могул» сүзенә карата да фикерләр белдерелгән.

Әсәрнең шушы басмасы өчен без нигез итеп алган Югары Курса кулъязмасында да ул сүз «могул» рәвешендә теркәлгән. Димәк, «Нуры содур»ның билгеле булган күчермәләреннән икесендә «могул» дип теркәлгәнне күрәбез. Әмма, әлеге ике күчермәнең текстлары бер-берсенә якын булганлыгын (алда әйтеп үткән идек) һәм хәтта аларның элекке протографларын бер үк чыганакка бәйли торган ачык дәлиле – ахырларындагы 1668/1669 елда күчерелгән нөсхәдән килгәнлекләрен истә тотсак, «могул» язылышы борынгы дәвердәге бер күчермәгә нисбәтле икәнлеге аңлашыла. Ә «Нуры содур»ның өч күчермәсендә (Уразай, Урта Шөн һәм Сарман) «могул» сүзе урынында «мәгъкуль» дип язылган. Шунлыктан, хәзергә төгәл ачыкланып җитмәгән

[146] Татар телендәге XVIII–XIX гасырларга караган алыш-биреш язмаларында «йөкче» термины еш кулланылганга бәйләп, татарча документларның тарихлары тирәннән килгәнлеген элегрәк язган идек. (Килешү-хокук язмалары (XVIII–XX гасыр башы) / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2023. – Б. 3, 8).
1997 елгы басмадагы «йөк» сүзен М.Гайнетдиннең, дөрес бирелмәгән, ул «як» (йәк) булырга тиеш, дип язуы ялгыш.

ул сүзне күпчелек күчермәләрдәгечә «мәгъкуль» дип бирдек.

Киләчәктәге фәнни эзләнү-тикшеренүләр нәтиҗәсендә бу мәсьәлә ачыкланыр дип өметләник. Лотфи текстында ул сүз «могул» булса да, Мөхәммәдьяр тарафыннан «мәгъкул» дип үзгәртелүе бик ихтимал дип фаразларга мөмкин.

«Нуры содур» әсәрендәге бүлек исемнәре астында гарәп телендәге дини гыйбарәләр дә урын алган. Шулардан кайбер гарәпчә хәдис текстлары шигъри икеюллыкларда да кабатланган. Әсәрдәге 9 нчы бәйт фарсыча һәм гарәпчә язылган, 18 нче бәйтнең икенче юлы фарсы телендә, ә 780 нче бәйт үзе тулаем гарәп телендәге дога сүзләреннән тора. Фарсы телендә язылган кайбер шигъри юлларда татарчада күп кулланылган сүзләргә, кушымчаларга охшашлыклар нәтиҗәсендә күчерүчеләр үзгәрткән һәм текстологлар ялгыш аңлаган урыннар да бар. Мәсәлән, пәйгамбәрне данлау бүлекчәсендә 9 нчы бәйттәге – әсәрнең 1997 елгы тәнкыйди текстында 170 нче биттә «шаһиншаһлар» дип бирелгән сүзгә игътибар итик. Кулъязмаларда ул төрлечә: СПб-1 нөсхәсендә шактый хаталы рәвештә «шиһнашаһла», СПб-2 күчермәсендә «сәһшалар», Олы Мәңгәр кулъязмасында «шәһсәлар», ә Югары Курсаныкында «сипаһсалар» буларак теркәлгән. Соңгысы, чынлап та, дөрес. Фарсы телендәге «сипаһ-салар» сүзе иң югары хәрби дәрәҗәгә ия кеше, хәрби җитәкче мәгънәләренә ия. Ләкин бу гыйбарәнең ахырындагы «-лар» өлеше төрки-татарча кушымчага аваздашлыгы һәм күчерүчеләр тарафыннан бозып язылганлыгы нәтиҗәсендә фарсы телендәге «Сипаһ-салар мәйдани рисаләт» (Пәйгамбәрлек мәйданының гаскәр башы) рәвешендә Мөхәммәд пәйгамбәргә атап язылган мактау сүзләренең беренчесе урынына «шаһиншаһлар» дип язу мәгънә ягыннан һич сыешмый. Әсәр текстындагы 18 нче бәйтнең фарсыча язылган икенче юлын татарча уку да дөрес түгел.

Әлбәттә, аерым сүзләрнең дөрес укылышында шикшөбһәләр калды. Шул ук вакытта, гади генә язылган кайбер сүзләрнең дә автор варианты булганлыгы шик уята. Һәрхәлдә, әсәр текстында хәл ителеп һәм төгәл ачыкланып бетмәгән

гыйбарәләр бар. Андый текстологик мөшкел урыннар, «Нуры содур»ның киләчәктә тагын күчермәләре табылса, ачыкланырга мөмкин.

Йомгаклап әйткәндә, «Нуры содур» поэмасының күчермәләрендә хаталар һәм сүзләр үзгәртелүе, төрлечә язылышлар шактый булуы – әсәрнең гасырлар дәвамында күп нөсхәдә күчерелгәнлегенә – димәк, күп укылуына һәм популярлыгына ныклы дәлил булып тора.

Югары Курса күчермәсенең палеографик хасиятләре шушы китапның искәрмәләр өлешендә һәм кульязма тасвирламасына багышланган мәкаләдә тулырак күрсәтелде.

## Басмалар

### Иң беренче мәгълүмат

Шагыйрь Мөхәммәдьярның күләмле һәм татар әдәбияты тарихы өчен билгесез булган «Нуры содур» әсәре татар җәмәгатьчелегенә «Совет әдәбияты» журналының 1941 нче елгы апрель санында Нәкый Исәнбәт тарафыннан язылган күләмле мәкалә[147] аша ирешкән. Күп мәгълүматлы, тәфсилле бу мәкалә бүлекчәләргә бүленеп, алар: «Табылуы», «Китапның исеме, форматы, зурлыгы», «Нуры сыдур кем тарафыннан, кайда, кайчан язылган?», «Сахибгәрәй ханның нәселе һәм кыскача биографиясе», «Әсәрнең эчке төзелеше һәм эчтәлеге; идеологиясе», «Әсәрнең тезмәчелеге», «Теле», «Әсәрнең күчерелүе һәм орфографиясе», «Сөземтә» дигән исемнәр белән аталган. Мәкаләнең ахырында поэманың өченче бүлеге – «Өченче баб (сәха) сүзләрен бәян кылыр» һәм шул ук бүлектәге йөкчеутынчы турындагы хикәят – барлыгы 40 икеюллык күләмендә тәкъдим ителгән.

1541 елның май аенда иҗат ителгән «Нуры содур» әсәренә нәкъ 400 ел тулуга туры килүе белән бу мәкалә аеруча истәлекле.

---

[147] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры әдәбиятыннан Мөхәммәдъяр Мәхмүд углы әсәрләре // Совет әдәбияты. – 1941. – №4. – Б. 68–79.

## Шигърият антологияләре

Татар поэзиясенең 1956 елда татар телендә һәм 1957 елда русчага тәрҗемәдә басылган китапларында Мөхәммәдьяр турында мәгълүмат бирелеп, әсәрләреннән кыска үрнәкләр урын алган[148].

Татарча басманың кереш мәкаләсендә (6 нчы биттә) Мөхәммәдьяр әсәрләре турында «...төзелешләре ягыннан аерылып торалар. Монда тоташ бер вакыйга сюжет итеп алынмый, һәр ике әсәр аерым-аерым шигъри хикәяләр бәйләменнән гыйбарәт» диелгән. Бу китапта «Нуры содур»ның 24 икеюллык күләмендәге өзекләре басылган.

Рус телендәге антологиядә «Нуры содур» өзекләре 23 бәйт күләмендә, алар Р.Моран һәм Л.Пеньковский тарафыннан тәрҗемә ителгән.

1992 елда нәшер ителгән татар шигърияте антологиясендә Мөхәммәдьяр турында мәгълүмат бирелгән, «Нәсыйхәт» шигыренең тексты, поэмаларыннан өзекләр, шул исәптән, «Нуры содур»дан барлыгы 174 икеюллык (китапның 158–165 нче битләрендә) урын алган[149].

Быел (ягъни, 2025 елда) татар шигърияте антологиясенең яңа басмасы нәшер ителәчәк дип көтелә. Анда Мөхәммәдьяр әсәрләре автор иҗат иткәнчә, дөрес текстологик сыйфатта булыр дип өмет итәбез.

## «Борынгы татар әдәбияты» китабы

Әдәбият галимнәре М.Гайнуллин, Х.Хисмәтуллин һәм Х.Мөхәммәтов тарафыннан төзелгән, 1963 елда[150] Татар-

---

[148] Татар поэзиясе антологиясе / төз.: М.Гайнуллин, Х.Госман, Ә.Исхак, Ш.Маннур, Х.Мөхәметов, Ә.Юнус, Х.Ярми. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – Б. 55–68; Антология татарской поэзии. – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – С. 56–67.

[149] Татар поэзиясе антологиясе. 1 китап / төз. Г.Рәхим. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 152–166.

[150] Китапның титул битендә 1963 ел дип күрсәтелгән булса да, ул чынлыкта 1964 елда дөнья күргән. Китапның ахыргы битендәге «Басарга кул куелды 21/I–1964 ел» дигән мәгълүматы шуны белдерә.

стан китап нәшриятында басылып чыккан «Борынгы татар әдәбияты» китабында Мөхәммәдьяр иҗатына зур урын бирелгән (356–412 нче битләр). Анда шагыйрьнең иҗаты турында галим Шакир Абилов тарафыннан язылган мәкалә, «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларыннан өзекләр бастырылган. Мәкаләдә Мөхәммәдьяр кулъязмалары турында, «Нуры содур»ның ул вакытка мәгълүм дүрт: Н.Исәнбәт кулъязмасы һәм Ленинградтагы өч күчермәсенең кыскача тасвир мәгълүматы, шагыйрьнең тормыш юлы, әсәрләренең өлешчә эчтәлекләре һәм сәнгати үзенчәлекләре турында язылган[151].

Китапның 375–399 нчы битләрендә «Төхфәи мәрдан» әсәренең һәм 399–412 битләрдә «Нуры содур»ның кыскартылган вариантлары урын алган. «Нуры содур» тексты Ленинградтагы «В3690» (СПб-2) кулъязмасы буенча бирелгән. Анда әсәрнең барлыгы 192 икеюллыгы басылган. Китапның 403 битендә шул күчермәдән бер битенең фоторәсеме урын алган.

### 1966 елгы китап

Мөхәммәдьярның әсәрләре аерым китап булып беренче тапкыр 1966 елда Казанда басылып чыккан[152]. Ш.Абилов төзегән бу китапның 5–20 нче битләрендә Мөхәммәдьяр иҗаты турында мәкалә, 25–78 битләрендә «Төхфәи мәрдан» һәм 81–124 битләрдә «Нуры содур» поэмаларының кыскартылган текстлары урын алган. Китапның 22 нче битендәге искәрмәдә «Әсәрләрне матбугатка әзерләгәндә, урта гасыр әдәби традицияләре буенча алланы, пәйгамбәрне, хөкемдарны мактаган кереш, шулай ук дини фәлсәфәдән генә торган урыннар кыскартылды һәм күпнокталар белән күрсәтелде» диелгән.

Бу китапның «Кушымта» өлешендә (125–129 битләрдә) ике әсәрнең текстлары теркәлгән кулъязмаларның (шул исәптән,

---

151 Борынгы татар әдәбияты..., 1963. – Б. 356–375.

152 Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур. Поэмалар / төз. Ш.Абилов. – Казан: Татар. китап нәшр., 1966. – 150 б. Китапның ахыргы битендәге «Басарга кул куелды 27/XII–1966 ел» дип язылганга караганда, ул 1967 ел башында гына дөнья күргән.

«Нуры содур»ның дүрт күчермәсе) тасвирламалары бирелгән. 130–149 нчы битләрдә «Сүзлек» урын алган.

Китапта «Нуры содур» әсәренең гомуми күләме 500 икеюллыкны тәшкил итә. Ленинградтагы «В343» шифрлы кулъязманың 109 нчы биттә бирелгән фоторәсеме астындагы язуында «XVI–XVII йөзләр күчермәсе» дигән мәгълүматы ялгыш.

Матбугатта чыккан беренче рецензиядә бу китап «әдәби мирасны туплау юлындагы бер адым итеп каралырга тиеш» дип бәяләнгән. Шунда ук текстологиянең катлаулы мәсьәләләре турында да әйтелгән[153].

Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1966 елда чыккан китабына рецензиясендә М.Госманов хезмәтне бик югары бәяләгән һәм шулай ук кайбер кимчелекләрен күрсәткән. «Поэмаларның кайбер урыннарында акланмаган кыскартулар үзләрен нык сиздерәләр... Кызганычка каршы, поэмадагы иң мәгънәле, матур шигъри юллар төшеп калган, авторның ил-дәүләт турындагы олы кайгысы, тирән фәлсәфәсе дә бик нык зәгыйфьләндерелгән»[154]. Мәкалә авторы болар өчен китапны төзүче һәм басмага әзерләүче генә җаваплы түгеллеген әйтеп, реаль сәбәпләрен күрсәткән.

Миркасыйм Госманов бәяләмәсендә 4 мең данә тиражлы китапның берничә ай эчендә сатылып бетүе турындагы мәгълүматы кызыклы. Ә иң мөһиме – Мөхәммәдьярның «әсәрләре исә тагы да яхшырак сыйфат белән, янә дә тулырак хәлендә киң катлам укучылар өчен басылырга тиеш. Шагыйрьнең барлык мәгълүм әсәрләреннән югары сыйфатлы академик басма әзерләү мәсьәләсенә килсәк, бу инде көн кадагында торган актуаль бурычларның берсе», – дип белдергән М.Госманов.

---

[153] Хисмәтуллин Х. Әдәби мирасны туплау юлында // Социалистик Татарстан. – 1967. – 13 май.

[154] Госманов М. Гаделлек җырчысы Мөхәммәдьяр // Казан утлары. – 1968. – №2. – Б. 136.

Тәнкыйди текст басмасы

Мөхәммәдьярның билгеле булган әсәрләре: «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» поэмаларының, «Нәсыйхәт» шигыренең тәнкыйди текстлары һәм хәзерге татар әдәби теленә күчермәләре 1997 елда Казанда дөнья күрде[155]. Аннотациясендә «Шагыйрьнең 500 еллык юбилеена багышлана» дип белдерелгән.

Китап филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегуловның «Мөхәррир сүзе» белән башлана (3–5 нче битләр). Аннан соң китапны төзүче Ш.Абиловның «Мөхәммәдьяр – гаделлек җырчысы» дип аталган күләмле мәкаләсе (6–29 нчы битләр). 31–34 нче битләрдә әсәрләрнең тәнкыйди нөсхәләренә һәм хәзерге телдә бирелешләренә карата аңлатма тәкъдим ителгән.

Әлеге басманың 35–168 нче битләрендә «Төхфәи мәрдан» поэмасының тексты һәм хәзерге телгә күчермәсе, искәрмәләре бирелгән. 170–308 нче битләрендә «Нуры содур»ның текстлары белән искәрмәләре урын алган. 309–313 нче битләрендә «Нәсыйхәт» шигыре, 315–317 нче битләрдә библиографик исемлеге.

Китапның 318–334 нче битләрендә академик Миркасыйм Госмановның «Мөхәммәдьяр: бөеклек фаҗигасе» дип исемләнгән мәкаләсе урнаштырылган.

Форзацта һәм аерым битләрдә Мөхәммәдьяр әсәрләренең хаттат Нәҗип Нәкъкаш тарафыннан гарәп хәрефләре белән аерым үрнәкләре сәнгати итеп язылган.

Шунысын да искәртергә кирәк, Ш.Абилов тарафыннан хәзерләнү процессында булган китап басылып чыкканчы ук аны башка авторлар кулланганлыгы турында матбугатта язылган иде[156].

---

[155] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь / төз. Ш.Абилов. – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – 336 б.

[156] Абилов Ш. Мөхәммәдьяр турында яңадан язарга кирәк // Шәһри Казан. – 1998. – 11 сент.; Шул ук // Мирас. – 2003. – №7. – Б. 156–158.

Әдәбиятчы галим Мәсгуд Гайнетдинов бу китапка рецензия сыйфатындагы мәкаләсендә, басманың уңай яклары белән бергә, җитешсезлекләрен дә күрсәткән. Ул киләсе басмаларда төзәтелергә тиешле кайбер хаталарны туплап, «хәреф җыючылар ялгышы гына булса да, андыйлар да ачыкланырга, төзәтелергә тиеш» дигән[157].

## Альбом

Татарстан Республикасында шагыйрьнең 500 еллыгы уңаеннан «Бу вакыйгаларны каршылап, шагыйрь иҗатына һәм аның заманына багышланган альбом чыгару бурычы куелды»[158], – дип язган иде галим Шакир Абилов.

1997 елда «Мөхәммәдьяр һәм аның чоры» дип аталган, нәфис бизәлешле альбом татар, рус һәм инглиз телләрендә дөнья күрде[159]. Аның титул бите артында «ЮНЕСКО карары буенча 1997 елда Мөхәммәдьярның 500 еллыгы билгеләп үтелә» диелгән.

Альбомда Ш.Абилов һәм М.Әхмәтҗановның «Мөхәммәдьяр» дип аталган, тарихчы И.Измайловның «Шагыйрь яшәгән чор» исемле мәкаләләре, «Нуры содур» һәм «Төхфәи мәрдан» әсәрләреннән өзекләр, «Нәсихәт» шигыре бирелгән. Бу басма Казан ханлыгы чорын тасвирлаган картиналар, кульъязма китаплар, ханнарның скульптур бюстлары, Сахибгәрәй хан ярлыгы, археологик табылдыклар, сугыш кораллары, 1556 елгы карта һ.б. иллюстрацияләр белән бизәлгән. Анда шулай ук Татарстанның Әгерҗе районында 1978 елда һәм Әтнә районында 1994 елда табылган «Нуры содур» кулъязмаларының төсле фоторәсемнәре дә бар.

---

157 Гайнетдин М. Хакыйкать юлыннан..., 2001. – Б. 113.

158 Абилов Ш. Мөхәммәдьяр турында яңадан... – 1998. – 11 сент.; Шул ук // Мирас. – 2003. – №7. – Б. 156.

159 Мөхәммәдьяр һәм аның чоры = Мухаммедьяр и его время = Mohammediar and his Time: альбом / төз.-авт. Абилов Ш., Әхмәтҗанов М., Измайлов И. – Казан: «Гасыр» нәшр., «Рухият» нәшр., 1997.

## Рус телендәге басма

«Болгар Иле» нәшрияты тарафыннан «VII–VIII гасырлардагы болгар әдәбияты антологиясе» сериясендә Мәскәү каласында 2007 елда рус теленә тәрҗемәдә Мөхәммәдьяр әсәрләре басылып чыкты. Төзүчесе һәм мөхәррире – Рәшит Кадыйров. Поэмаларның «болгар төркичәсеннән» русчага тәрҗемәләре дә анык.

Китапның 172–299 битләрендә «Казан тарихы» дип аталган һәм, имеш, Мөхәммәдьяр тарафыннан язылган дип белдерелгән, елъязма рәвешендәге текст урнаштырылган. Мөхәммәдьярның уйдырмаларга нигезләнгән тәрҗемәи хәле Ф.Г.-Х.Нуретдинов тарафыннан язылган (301–317 битләрдә).

«Төхфәи мәрдан» белән «Нуры содур»ның кулъязма күчермәләре факсимилеләре (репродукцияләре) 367–428 нче битләрдә бирелгән. Аларның төп чыганаклары турында әйтелмәгән булса да, беренчесе – Казан университеты китапханәсендә саклана торган кулъязма, ә икенчесе – Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында саклана торган Олы Мәңгәр күчермәсе (367–409 нчы битләрдә).

Татар халкы оешуның катлаулы тарихи чынбарлыгын тар кабиләчелек кысасына гына бәйләп күрсәтергә тырышкан «болгарчылар» төркеменең уйдырмалар, мистификация белән шөгыльләнүләрен һәм аның сәбәпләрен фаш итеп галимнәр дистә еллар элек үк яздылар[160]. Шагыйрьнең «Төхфәи мәрдан» әсәрендәге, болгарчылык тарафдарлары күпертә торган гыйбарәсе нәрсәне аңлатканлыгы турында тарихчылар фикере дә басылган иде[161]. Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов

---

[160] Юзиев Н. Әдәбият чыганаклары белеме: әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре. – Казан: «Фикер» нәшр., 1998. – Б. 77–97; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы..., 2000. – Б. 20–52.
Язучы һәм публицист Локман Закир совет чорындагы кайбер тарих китапларында һәм аерым тарихчыларның карашларында Мөхәммәдьяр иҗатына бәйләп сәясәт тудырган фикерләрне бәян итте (Закир Л. Мөхәммәдьяр диссидент булганмы? // Мәдәни җомга. – 1997. – 14 март).

[161] История татар: с древнейших времён. В семи томах. Т. IV. ..., 2014. – С. 794–795.

та шул ук мәсьәләне күздә тотып, урта гасырдагы бер әдәби персонажның сүзе тарихи хезмәт түгеллеген һәм фаразларга нигез була алмавын кыскача һәм үтемле итеп аңлатты[162].

Мәскәүдә басылып чыккан Мөхәммәдьяр әсәрләре китабы да – нәкъ менә шул төркем эшчәнлегенең нәтиҗәсе. Андагы шигъри әсәрләрнең текстларыннан башка язмаларны хакыйкать дип кабул итүдән саклану зарур.

### 2009 елгы җыентык

«Нуры содур» әсәренең Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган ике кульязма күчермәсенең текстлары «Милли китап» нәшриятында җыентык рәвешендә нәшер ителде[163].

Китапханәдәге кульязмаларның берсе 1999 һәм икенчесе 2004 елда табылып өйрәнелгән иде. Алар икесе дә XVIII гасыр күчермәләре. Текстлары поэманың 1997 елда нәшер ителгән тәнкыйди басмасы белән чагыштырылып, аермалары һәм үзенчәлекләре тәгаенләп күрсәтелде. Китапның кереш мәкаләсендә кайбер мәсьәләләр аерып аңлатылды, тәнкыйди басмада булмаган дүрт икеюллык һ.б. турында әйтелде. Китаптагы текстлар «киләчәктә Мөхәммәдьяр әсәрләренең тулыландырылган яңа басмалары өчен материал буларак хәзерләнүе» белдерелде. Шулай ук, 2009 елгы китапта «Мөхәммәдьяр әсәрләренең шушы күчермәләре һәм алардагы яңа бәйтләр, бүтән үзенчәлекләре булуы – бөек әдип иҗатын өйрәнүне дәвам итү белән бергә, киләчәктә гамәли тикшеренү-эзләнүләрне дә туктатмаска кирәклеген искәртә. Әлеге юнәлештә гыйльми китапханәләрдә, архив һәм музейларда тупланган биниһая зур кульязма мирасны җентекләп тикшерү уңай нәтиҗә бирергә мөмкин. Һәрхәлдә, Мөхәммәдьяр әсәрләренең тулы текстлары булмаса да, өзекләр рәвешендәге фрагментар күчермә нөсхәләре табылуы ихтимал»[164], – дип язылды.

---

[162] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т. ..., 2022. – Б. 135–136.

[163] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульязмалары / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – 128 б.

[164] Шунда ук. – Б. 10.

2021 елгы китап

Мөхәммәдьярның әсәрләре соңгы мәртәбә моннан берничә ел элек кенә нәшер ителде[165]. Ул 1997 елгы басма нигезендә, бераз үзгәртеп чыгарылган. Төзүчесе дә шул ук – Ш.Абилов (1915–2004) дип күрсәтелгән. Анда Мөхәммәдьяр иҗат иткән өч әсәрнең дә башлангыч текстлары, хәзерге әдәби телдәге вариантлары һәм искәрмәләре урын алган. Берничә бите хаттат Нәҗип Нәкъкашнең гарәп хәрефле язмалары белән бизәлгән.

Китап фәнни мөхәррире Хатыйп Миңнегуловның «Гаделлек җырчысы Мөхәммәдьяр» дип исемләнгән кереш мәкаләсе белән башлана (5–12 нче битләр).

Хәзерге әдәби телдәге текст өлешләре әлеге китапта алдан бирелгән һәм 1997 елгы басмада булган, шигъри юлларның тәртибен күрсәткән саннар куелмаган. Ә текстлары үзгәрешсез басылган һәм, кызганыч ки, өстәмә мәгълүмат та бирелмәгән[166]. Өстәмә мәгълүмат дип, мисал өчен, «Нуры содур»ның егерме ел элек үк 1997 елгы китапка кермәгәнлеге ачыкланып матбугатта белдерелгән 4 икеюллыгы, шулай ук бүлек башларындагы Коръән гыйбарәләренең һәм хәдисләрнең соңгы басмада да булмавын күздә тотабыз.

1997 елда басылган китаптагы хата-кимчелекләрнең төзәтелмичә, аннан соң үткән чирек гасыр чамасы вакыт арасында Мөхәммәдьяр иҗатына кагылышлы фәнни хәрәкәтне исәпкә-санга алмыйча, күчереп кенә чыгару ысулын уңышлы дип булмый. Югыйсә, Казан ханлыгы чорының мәшһүр әдибе Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәре, үзенә лаеклы югары дәрәҗәдә, мөмкин булганча тулырак һәм дөресрәк рәвештә (бигрәк тә, дини гыйбарәләрен һәм 1997 елгы басмадан соң ачыкланган икеюллыкларын өстәп) замандашларыбызга тәкъдим ителүе зарур иде.

---

[165] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь / төз. Ш.Абилов; фән. мөх.-ре Х.Миңнегулов. – Казан: Татар. китап нәшр., 2021. – 272 б.

[166] Текстларның үзгәртелмәве нәтиҗәсендә, 1997 елгы китаптагы хаталар да төзәтелмәгән. Бу мәсьәлә моңарчы да искәртелде: Мәрданов Р. Гарәп хәрефле..., 2024. – Б. 199.

***

Монда басмаларның аеруча әһәмиятлеләре, текстлары күләмлерәк булганнары турында язу белән чикләндек. Мөхәммәдьяр әсәрләре инде 1960 нчы еллардан мәктәп дәреслекләрендә урын алып килә. Бөек шагыйрьнең иҗаты нигезендә гыйльми диссертацияләр дә якланган. Шулай ук, күптөрле фәнни җыентыкларда, журналларда һәм газеталарда авторы турында мәкаләләр, әсәрләреннән өзекләр басылып тора. Мөхәммәдьярның 500 еллыгы уңае белән республика матбугатында шактый материаллар чыккан иде. Гомумән, әдипнең шәхесе һәм әсәрләре белән кызыксыну кимеми, соңгы чор язучылары һәм шагыйрьләре дә аңа мөрәҗәгать итәләр, мисал өчен Әхмәт Рәшитнең «Мөхәммәдьяр» дип аталган драматик поэмасын әйтергә мөмкин.

## Әсәрдәге Коръән аятьләре һәм хәдисләр

«Нуры содур» поэмасының кульязмаларында кайбер баббүлек башларында шул бүлекнең эчтәлегенә туры килә торган хәдисләр һәм Коръән аятьләре, хәзергечә әйткәндә, эпиграф рәвешендә теркәлгән. Әсәрнең 1997 елда дөнья күргән тәнкыйди текстында аларның фәкать берсе генә – гаделлек турындагы беренче баб исеме астында Коръәннең «Нәхел» сүрәсендәге 90 нчы аятенең «Иннә Аллаһә йәэмүрү бил-гадли вәл-ихсани» дигән өлеше бирелгән.

Чынлыкта, «Нуры содур» поэмасының хәзерге вакытта фәндә мәгълүм кульязмаларында җиде бүлек-бабның исемнәре астында: дүртесендә Коръән аятьләре һәм өчесендә пәйгамбәр хәдисләре язылган. Поэманың бүлек башларында Коръәннән һәм хәдисләрдән өземтә бирү, әлбәттә, әдәби әсәрне бизи, аның мәгънәви җәһәтен тирәнәйтә һәм тәэсирен көчәйтә. Бер төрле үк гыйбарәләрнең төрле кульязмаларда теркәлгән булуы – аларның кульязма күчергән кешеләр тарафыннан гына өстәлгән очраклылык түгеллегенә ишарә итә. Димәк, поэманың авторы Мөхәммәдьяр төп нөсхәдә үк шулай язган булган.

Ихтимал, һәр бабның башында автор тарафыннан Коръән аятьләре һәм хәдисләр бирелгән булгандыр. Чөнки ун бабның өчесендә генә алар булганмы-юкмы икәнлеге мәгълүм түгел. Мантыйкый фикер йөрткәндә, автор аларында да аять яки хәдис теркәгән булгандыр дип фаразларга мөмкин.

Болардан тыш, Мөхәммәдьяр баб-бүлек эчләрендә дә Коръән һәм хәдис мәгънәләрен татарчага тәрҗемә итеп, шәрехләп язган.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең Ислам дине тәгълиматына нигезләнеп иҗат ителгән булуы галим Ш.Абилов хезмәтендә игътибар үзәгенә куелмаган һәм шунлыктан, әдип иҗатының асыл мәгънәсен таныту чикләнгән. Атеистик совет чорында формалашкан татар галименә Мөхәммәдьяр гуманизмының нигезендә Ислам гуманизмы ятуы турында, аңлап-белгән хәлдә дә, язарга читен булганлыгы аңлашыла. Әмма 1997 елгы китапка нигез итеп алынган СПб-1 күчермәсендә бүлек башларындагы дини гыйбарәләрнең алтысы теркәлгән була торып та, бары тик берсе генә китапка кертелүе, ә бүтәннәренең төшереп калдырылуы һәм алар турында һичбер искәрмә бирелмәве – хилаф гамәл. Югыйсә, китап дөнья күргән 1997 елга илдәге совет хакимлеге беткән, динне кысрыклаган коммунистлар партиясенең эшчәнлеге тукталган, иң мөһиме – ун еллап дини хөррият дәвам иткән заман иде. Дини гыйбарәләрнең тәнкыйди текст басмасына кертелмәве – Мөхәммәдьяр әсәрен йөзек кашыннан – төп сыйфатыннан мәхрүм итүгә тиң, дисәк, арттыру булмас[167].

Шагыйрь иҗатының асыл хакыйкатен тәкъдир итеп язучылар да булды. Мәсәлән, әдәбият галиме Нәҗип Нәкъкаш

---

[167] Ул китапны басмага әзерләү дәвамында баб-бүлек башларындагы дини гыйбарәләрне олуг галимнәребез төшереп калдырырга хәл иткәнлекләре турында күптәннән үк ишетеп белә идек. Мәшһүр фикер иясе Мөхәммәдьяр әсәренең Коръәнне һәм хәдисләрне олылаган хасиятеннән мәхрүм итү – халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырендәге дога сүзләре теркәлгән өлешен совет чорында киң даирә укучыларга танытмаска омтылу күренешен хәтерләтә.

«Нуры содур»да Коръән һәм хәдисләрдәге фикерләр үзәккә куелганлыгы турында язды[168]. Аның мәкаләсендә мондый юллар бар: «Татар халкының олуг шагыйре Мөхәммәдьярның безнең көннәргәчә килеп җиткән әсәрләре һәммәсе дә Ислам дине, ислам диненең иң зур таянычы, чыганагы – бөек китап Коръән белән, Алланың илчесе, пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдисләре белән сугарылган әсәрләр. Халыкны халык булып, милләт итеп оештыруда, дәүләтнең бөтенлеген, ныклыгын тәэмин итүдә ярдәм идеология булдыруда, үзенең төгәл кануннары, кагыйдәләре, шәригать хөкемнәре һәм хокуклары белән халыкның әхлагын саклауда ислам диненең әһәмияте чиксез зур... Мөхәммәдьяр «Күңелләр нуры» әсәрендә гүзәл әхлак сыйфатларын тасвирлап язганда сүзе үтемле, ышанычлы булсын өчен иң зур авторитетларга – Коръәнгә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләренә, ягъни әйтеп калдырган сүзләренә таяна, шуларны эпиграф рәвешендә йә бүлек башында китерә, йә бүлек эчендә шигъри тәрҗемәләр хәлендә бирә»[169], – дип, аерым мисалларга тукталган. Мәкалә авторы «Сабыр итүнең файдасы хакында сөйләнгән алтынчы бүлектә шагыйрь Коръәннән берничә аять китерә. Аның беренчесе, гарәп телендәгесе, эпиграф итеп куелган» дип язганда әсәрнең кульязма күчермәсен күздә тоткан. Чөнки 1997 елгы басмада алтынчы бүлек башында Коръән аяте теркәлмәгән.

Әсәрдәге дини гыйбарәләр турындагы фикерләребезне белдереп без дә язган идек[170].

---

[168] Нәкъкаш-Исмәгыйль Н. Мөхәммәдьяр иҗатында Коръән һәм хәдисләр // Мирас. – 1997. – №8. – Б. 38–45.

[169] Шунда ук. – Б. 38, 40.

[170] Мәрданов Р. Бу китап хан догасы... – 2005. – №7. – Б. 165; Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы... 2009. – Б. 6–7, 24, 34, 76, 81, 91; Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның... // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 39.

«Нуры содур» әсәренең бүлек башларында теркәлгән дини гыйбарәләр

| *бүлек* | *Коръәннән* | *хәдис* | *теркәлгән күчермәләр* |
|---|---|---|---|
| 1 баб | «Ән-Нәхл» сүрәсенең 90 нчы аятеннән | | СПб-1, СПб-2, Наратлык, Барда, Сарман |
| 5 баб | | «Рәҗәгъна мин...» | Ижевск, СПб-1, СПб-2 |
| 6 баб | «Әлү Гыймран» сүрәсенең 200 нче аяте | | Олы Мәңгәр, Уразай, СПб-1, Барда, Сарман |
| 7 баб | | «Әл-вафа фә-ма...» | СПб-1 |
| 8 баб | «Маидә» сүрәсенең 46 нчы аятеннән | | Олы Мәңгәр, Уразай, Урта Шөн, СПб-1, Ижевск, СПб-2, Сарман |
| 9 баб | | «Мән сәкәтә...» | СПб-1 |
| 10 баб | «Ән-ниса» сүрәсенең 43 нче аятеннән | | Яңа Аккуҗа |

Җиденче, тугызынчы һәм унынчы баб башларындагы дини гыйбарәләрнең берәр күчермәдә генә теркәлгән булуына нигезләнеп, гарәп телендәге текст өлешләренә күчерүчеләр тиешле әһәмият биреп җиткермәгәннәр һәм, шунлыктан, бүтән бүлекләрнеке дә хәзергәчә килеп ирешмәгән дип фаразларга мөмкин.

Монда әйтелгәннәрдән тыш, «Нуры содур» текстының һәр бүлеге эчендә егермедән артык хәдиснең һәм биш Коръән аятенең тәрҗемәләре шигъри тезмәләргә салып аңлатылган. Турыдан-туры тәрҗемәләр булган кебек, ирекле шәрех-аңлатма рәвешендә (шул исәптән, монда күрсәтелмәгән икеюлыкларда) язылганнары да бар. Бүлекләрдә, гомумән, пәйгамбәрнең

берничәшәр хәдисләре китерелгән. Кайбер хәдис мәгънәләре бер үк бүлек эчендә берничәшәр мәртәбә кабатланган, мәсәлән, 8 нче бабтагы телне тыю турындагысы – дүрт тапкыр әйтелгән. Бер үк хәдис мәгънәсе татарчада төрлечәрәк итеп бирелгәнен дә күрергә мөмкин (мәсәлән, 302 һәм 304 нче, 483 һәм 495 нче бәйтләрдә). Тугызынчы бабның исеме астында ук гарәп телендә язылган хәдис текстта (532 нче бәйттә) шулай ук кабатланып, 533 нче бәйттә тәрҗемәсе урын алган.

«Нуры содур» әсәренең бүлекләре эчендә язылган
һәм шәрехләнгән дини гыйбарәләр

| *№* | *бүлек* | *бәйт саны* | *Коръән аятьләренең мәгънәләре* | *хәдис мәгънәләре* |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 1 баб | 101 | | «Бер сәгать гадел кыйлмак...» |
| 2. | 2 баб | 155 | | «Кемгә дәүләт-ү-сәгадәт...» |
| 3. | 3 баб | 182, 183 | | «Сәхавәт берлә булур...» «Кайу ир кем...» |
| 4. | 3 баб | 186–187 | | «Җәһан эчендәге...» |
| 5. | 3 баб | 188 | | «Хак зийадат кыйлур...» |
| 6. | 4 баб | 219 | | «Ир хәйа берлә...» |
| 7. | 4 баб | 222, 226 | | «Һәркем куркса Тәңредин...», «Кайу кем ирсә ойалса...» |
| 8. | 4 баб | 230, 231, 239 | | «Хәйа имандин ирер...», «Кемгә кем кыйлса...», «Булмас иман...» |
| 9. | 5 баб | 302 | | «Кем газа кыйлмак...» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10. | 5 баб | 304 | | «Кем шәҗәгать кыйлса...» |
| 11. | 5 баб | 305 | «Әс-Сафф» сүрәсенең 4 нче аятеннән | |
| 12. | 5 баб | 309–310 | | «Һәркем ул кыйлса...» |
| 13. | 5 баб | 318 | | «Хак Тәгалә кыйлды...» |
| 14. | 6 баб | 363–364 һ.б. | «Әл-Бәкара» сүрәсенең 153, 249 аятьләре | |
| 15. | 6 баб | 372 | | «Сабыр берлә...» |
| 16. | 6 баб | 380 | | «Сабыр кыйлмак...» |
| 17. | 7 баб | 426 | «Әл-Исра» сүрәсенең 34 нче аятеннән | |
| 18. | 7 баб | 429, 446 | | «Вәгъдәгә кыйлган вафа...», «Вәгъдәгә кыйлган вафа...» |
| 19. | 8 баб | 475 | | «Күнилек берлә...» |
| 20. | 8 баб | 480 | | «Күни сүзләгән кешене...» |
| 21. | 8 баб | 483 | | «Нә ки телдин чыкты...» |
| 22. | 8 баб | 495 | | «Ни килсә башка...» |
| 23. | 8 баб | 506, 514, 521, 529 | | «Һәр кем тотты телене...» |
| 24. | 9 баб | 532 533 | | «Мән сәкәтә...» «Һәр ки сакитдыр...» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25. | 9 баб | 540 | | «Һәр ки самит булса...» |
| 26. | 9 баб | 551 | | «Сәкез оҗмах...» (хәдистән) |
| 27. | 10 баб | 572 | «Әл-Кәһф» сүрәсенең 107 нче аятеннән | |
| 28. | Заһид хикәятендә | 677 | «Ән-Нәхл» сүрәсенең 4 нче аятеннән | |

Соңгы – 28 нче санлысы Коръәннең «Йасин» сүрәсе 77 нче аятендә, «Әл-Инсән» сүрәсенең 2 нче аятендә дә бар.

Баб-бүлек башларында, монда күрсәтелгән бәйтләр янәшәсендәге башка икеюллыкларда да Коръән аятьләренең һәм хәдисләрнең мәгънәләрен шәрехләү-аңлату сүзләре язылган.

«Нуры содур»ның бүлек башларында һәм бүлек эчләрендә язылган Коръән аятьләре, хәдисләр һәм аларның мәгънәләре белән тәрҗемәләре барлыгы 35 икәнлеге ачыкланды. Шуларның Коръәннән алынганнары – 9, ә хәдисләр – 26[171].

Поэманың авторы 104–105 нче бәйтләрдә хәзрәти Галинең (Гали ибне Әбү Талиб, 601–661) тирән мәгънәле фикерләрен дә әйткән:

Тыңлаңыз, имди әмирел-мөэминин
Ул Гали сүзләренең хуш мәгънәсен:
«Гадел берлә ил гыймарәт булур уш,
Барча эшләрдә табар аның берлә хуш».

107 нче бәйттә «Бер тәкый хикмәт сүзен әйтәйем» дип,

[171] Тасвирлап үтелгән дини гыйбарәләр үзебез ачыклый алган өлеше генә дип кабул ителергә тиеш. Ислам дине буенча киң мәгълүматка ия белгечләр – Коръәнне, аның тәфсирләрен, хәдисләрне һәм пәйгамбәрләр тарихын тәфсилләп өйрәнгән галимнәр «Нуры содур» текстында тагын да кызыклырак нәтиҗәләргә ирешәчәгендә, без язганнарны тулыландырачагында шик юк. Шулай ук, ялгышларыбызны да төзәтерләр дип ышанабыз.

108–109 нчы бәйтләрдә мондый гыйбарә теркәлгән:

«Көфер берлә мәмләкәт булмас хәраб,
Золым берлә йыкылур олус йөдәб.
Көфре кяфер нәфсенә кыйлур зийан,
Золым берлә булур ил хәле йаман».

Гали ибне Әбү Талибның әйткән хикмәтле сүзләре һәм канатлы гыйбарәләре мөселман дөньясында киң билгеле булган, төрки-татар әдәбиятында да урын алган[172]. Мөэминнәр юлбашчысы Гали ибне Әбү Талиб үзе идарә иткәндә дәүләт эчендә төрле телләрдә сөйләшүче халыкларга, кешеләрнең иҗтимагый хәлләренә бәйсез рәвештә, ислам дине өйрәткән гаделлекне мөмкин булганча тормышка ашырган. Ул җәбер-золым хөкем сөргән һәм гаделлекне белмәгән җәмгыятьтә ислам дине яши алмавын яхшы аңлаган. Гаделлек турында даими кайгыртып, халыкның күңелен яулаган. Гали ибне Әбү Талиб фикеренчә, гаделлек – кешеләрне исламга чакыруның ачык юлы[173].

1997 елгы басмада «Нуры содур» әсәренең хәзрәти Гали сүзе буларак бирелгән гыйбарәсе аерым искәртелмәгән. Ул китапның 178 битендә (105–106 нчы бәйтләр буларак) «Ул гали сүзләрнең...» рәвешендә басылган юлының тәрҗемәсендә (249 биттә) мәгънәсе «олуг сүзләр...» дип ялгыш аңлатылган.

Коръәннең һәр сүрәсе башындагы «Бисмилләһи Рахмәнир-Рахим», шулай ук Аллаһы Тәгаләнең Коръәндә аталган мактаулы исемнәренең дистәләрчә төре бу әсәрдә бик күп мәртәбә телгә алынган булуы да югарыда әйтелгәннәргә өстәп каралганда, «Нуры содур»ның төп асылы тагын да тулырак күзаллана[174].

---

[172] Бу мәсьәләдә элегрәк тә язган идек: [Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер..., 2016. – Б. 14–16.

[173] Ас-Салляби Али Мухаммад. Али ибн Абу Талиб. Четвёртый праведный халиф / пер. с араб., прим., комм. Е.Сорокоуловой. – М.: изд. дом «Умма», 2013. – С. 351.

[174] Шагыйрь Мөхәммәдьярның остазы булган дип фаразланган Мөхәммәтәмингә нисбәт ителгән «Гыйлем Хакка илтер» текстының кайбер урыннарында әсәр мәгънәсенә туры килә торган Коръән сүзләре һәм хәдисләр язылган ([Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер... , 2016. – Б. 66, 72, 88, 89).

Поэма текстын тулы килеш төшенеп укыганда, «Нуры содур»ның, ягъни «Күңелләр нуры»ның төп мәгънәсе – изге ислам динендә, Коръән белән хәдисләрдә икәнлеге ачык аңлашыла. Моңарчы әсәр авторына нисбәт итеп аңлатылган тирән мәгънәле кайбер сүзләрнең һәм фикерләрнең төп чыганагы Коръән һәм хәдисләр, шулай ук Гали хәлифә әйткән гыйбарәләр икәнлеге дә беленә. Бу исә Мөхәммәдьярның иҗади сәләте дини өйрәтмәләрне шигъри әсәрдә, гүяки, затлы намазлыкка алтын җепләр белән нәфис итеп чиккән кебек, никадәрле зәвыклы итеп тасвирлаганын күрсәтә.

«Нуры содур» әсәрендәге хикәятләрнең сюжетлары Коръәнгә һәм аның тәфсирләренә, шулай ук пәйгамбәрләр тарихына багышланган борынгы китапларга нигезләнгән булуын да искәртү зарур. Мәсәлән, икенче бүлек хикәятендә сүз барган Муса пәйгамбәр вакыйгалары Коръәндәге «Әл-Касас» һ.б. сүрәләрдә тасвирланган, Шөгаеб пәйгамбәрнең куйларын көтүе, аның кызына никахлануы, башка хикмәтле хәлләре 1310 (1311) елда Рабгузи тарафыннан язылган «Кыйсасел-әнбия»да бәян ителгән[175].

Җиденче бүлектә (436–440 нчы бәйтләрдә) Коръәндәге «Әл-Кәһф» сүрәсенә бәйле вакыйга искә алынган. Әсәрдә әсхабе кәһф – мәгарә хуҗаларына ияргән көчек күпчелек кулъязмаларда (СПб-1, Олы Мәңгәр, Ижевск, Урта Шөн, СПб-2, Барда, Сарман) «ничә кем кайтардылар – кайтмады»[176] дип теркәлгән. Әлеге шигъри юлдагы «кайтардылар» сүзе бары тик бер күчермәдә – Югары Курсаныкында «кыйнар ирделәр» дип язылган. Мондый гыйбарә шигъри әсәр өчен тупас һәм аның дөресе «кайтардылар» булырга тиеш кебек. Ләкин Рабгузи китабының әсхабе

Коръәннән аятьләр һәм пәйгамбәр хәдисләре әсәр эчендә бирелгән мисалларны «Могҗизнамә» әсәрендә дә күрәбез (Мөхәммәт Әмин. Могҗизнамә..., 2004. – Б. 33, 57, 97, 171, 175, 209, 245 һ.б.).

[175] Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 229–291.

[176] Бу вакыйга «Әл-Кәһф» сүрәсенең аңлатмасында тәфсилле язылган: Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә. – Казан: «Хозур» – Тынычлык нәшрият йорты, 2020. – Б. 397–399.

кәһфкә багышланган кыйссасында болай диелгән: «...куйчыга әйделәр: этеңне оргыл, ирәшмәсүн, безне фаш кыйлур. Чупан этне орды. Кайтмады. Этнең бер аягын сындырдылар». Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән эт телгә килеп, сезгә Хак Тәгалә кирәк булган кебек, миңа да кирәк, дигән. Шуны ишетеп егетләр этне күтәреп алып барганнар[177]. Димәк, этне имгәткәнче кыйнаганнар икән һәм Югары Курса нөсхәсендәге язылышның дөресрәк икәнлеге аңлашыла. Шунысы да бар – «кайтардылар» вариантында шигъри юлда бер иҗек җитми, ә «кыйнар ирделәр» булганда иҗекләр саны дөрес.

Поэманың ахырында (764–768 нче бәйтләрдә) Сөләйман пәйгамбәргә чикерткә ботын кабып кунакка килгән тургай турындагы хикәяткә охшаш һәм аның асылын аңлаткан сюжет Рабгузи китабында да бар. Сөләйман пәйгамбәр белән кырмыскалар чирүенең башлыгы (китапта ул кәрванбашы мәгънәсендәге «җәммали» дип аталган) арасында кайсысының чирүе зуррак икәнлеге турында сүз булып, исәпләгәч Сөләйманныкы азрак икәнлеге ачыкланган. Шуннан соң пәйгамбәрне кунак итү тасвирланган: «Җәммали бойурды – бер чүкүрткә ботыны килтүрделәр. Сөләйман галәйһиссәлам аны күрүб көлүмсәде. Җәммали әйде: «Әй, Сөләйман! Моны аз нирсә тәйү көлүрмесен? Бәрәкәтега бакгыл», – тиде. Ул чүкүрткә ботыны өләштүрде, Мәүла Тәгалә кодрәте берлә анча бәрәкәт бирде – Сөләйман галәйһиссәлам катындагы адәмиләрдин артты. Сөләйман галәйһиссәлам аны күрүб сәҗдәга барды...»[178].

Мөхәммәдьяр тургай хикәятенә бәйләп, үзенең ханга тәкъдим иткән әсәрен чикерткә боты кебек кечкенә генә дип язган. Әмма аның бәрәкәте турында «Кыйсасел-әнбия»да әйтелгән тирән мәгънәне ачык белдермәгән. Гәрчә, Рабгузи әсәреннән аңлашылганча, андый бүләкнең дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан салынган бәрәкәткә ия булуы әйтелгән. Димәк, Мөхәммәдьяр әсәрендәге хикәятләрне борынгы Шәрык әдәбиятында йөргән

---

[177] Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи..., 1881. – Б. 437–438. *Ирәшмәсүн* – иярмәсен; *чупан* – көтүче.

[178] Шунда ук. – Б. 315.

сюжетларны файдаланып язылганнар дип кенә түгел, ә чыганакларын ачыклап өйрәнгәндә, киңрәк мәгънәләренә (шул исәптән, автор турыдан-туры әйтеп бетермәгәннәренә дә) төшенергә мөмкин икән.

«Нуры содур» әсәрендә ханга-хөкемдарга ачык киңәшләр белән бергә киная рәвешендә белдерелгәннәре дә бар дип, галимнәребез бик хаклы язалар. Әле әйтеп үтелгәне дә шундый киңәшләрнең берсе булган. Өстәвенә, кырмыска риваятендә мондый юллар да бар: «Җәммали сорды: Әй, Сөләйман! Син камуг чәрикеңнең хәледин хәбәр белүрмесән? Сөләйман галәйһиссәлам әйде: юк. Җәммали әйде: Мин белүрмен, кичәкөндүз ләшкәремне гизәрмен, һәр кайсы сынук-гаҗиз булса – аны тимар кыйлырмын»[179]. Шул рәвешле, патшалар үз халкының хәлен яхшы белергә, аларны кайгыртырга тиешлеге әйтелгән. Рабгузи китабында бәян ителгәннәрне Мөхәммәдьяр ачык итеп кабатламаса да, аның эчтәлеге ул чорда яшәгән укымышлыларга һәм югары сыйныф даирәсенә яхшы мәгълүм булган дип уйлыйбыз.

## Эчтәлеге

«Нуры содур» текстының теле борынгы булуы сәбәпле, укып мәгънәсен төшенү замандашларыбыз өчен шактый читен. Мөхәммәдьяр әсәрләре, аның ханга нәсихәт-киңәш рәвешендәге «Нуры содур» поэмасы турында моңарчы инде күп язылса да, шулай ук мәктәпләрдә һәм татар әдәбияты тарихы буенча югары уку йортларында өйрәнелсә дә, гомуми күзаллау максатында искә төшерү файдага булыр.

Бу әсәрнең бүлек һәм бүлекчә атамалары кулъязма күчермәләрдә, шулай ук басма китапларда нинди рәвештә булганлыгы, һәрберсенең күләме (кайсы һәм ничә бәйттә икәнлеге) китап ахырындагы искәрмәләр өлешендә тәфсилләп аңлатылды.

Әйтеп үткәнебезчә, «Нуры содур» поэмасының башында Аллаһы Тәгаләгә сәна (мактау), Мөхәммәт пәйгамбәргә,

---

[179] Шунда ук. – Б. 314–315. *Тимар кыйлырмын* – кайгыртам.

сәхабәләргә, ханга догалар һәм мәдхия сүзләре язылган. Аннан соң бу китапның хан исеменә – «ханнар ханы»на, «шаһи галәм»гә (дөнья патшасына) атап язылганлыгы, әсәрнең исеме «Нуры содур» дип аталуы (54 нче бәйттә), иҗат итүчесенең исеме – «Атам – Мәхмүд, догачы – Мөхәммәдьяр» (61 нче бәйттә) аталган. 69 нчы икеюллыкта әсәрнең язылган елы, 70 нче бәйттә «Болгар шәһре Казанда» дип, иҗат ителгән урыны күрсәтелгән.

Әсәрнең ун баб-бүлектән торганлыгы һәм аларның нәрсәләр икәнлеге саналып:

Яхшы укып, мәгънәләрен белеңез,
Шаһи галәмгә догалар кыйлыңыз!

– диелгән.

Поэманың бүлекләре ислам дине өйрәткән күркәм холык хасиятләренә багышланып, һәр бүлек башында аларның Аллаһы Тәгаләдән ирешә торган зур хәзинә икәнлеге аңлатылган, Коръәннең һәм пәйгамбәр хәдисләренең тирән мәгънәле фикерләре нигез итеп алынган. Һәр бүлекнең эчендәге аерым хикәятләрдә күркәм холык сыйфатлары кыска, аңлаешлы, мавыктыргыч һәм гыйбрәтле итеп тасвирланган.

Беренче баб-бүлек гаделлек турында дип исемләнгән һәм бүлек атамасыннан соң ук Коръәндәге гаделлек һәм игелек белән гамәл кылу турындагы аятьнең бер өлеше язылган. Текстта гаделлек белән идарә итү турында нәсихәт сүзләре бәян ителгән. 101 нче бәйттә пәйгамбәрнең «Бер сәгать гаделлек итү алтмыш ел гыйбадәт кылудан яхшырак» дигән хәдисе дә искә алынган. 106 нчы бәйттә Гали хәлифә әйткән «Гадел берлә ил гыймарәт булыр...» (Ил – гаделлек белән төзек булыр) дигән канатлы сүзе язылган, аннан соң «Ил-дәүләткә иң зур зыян золымнан килә» дигән фикере әйтелеп, Гадел Нәүширван шаһ турындагы хикәят сөйләнгән.

Гаделлеге белән шөһрәт казанган Нәүширван 70 вәзиреннән җидесенә мәмләкәтнең имин булуы өчен үзенә киңәшләр бирергә боерган. Вәзирләрнең берсе бөтен дөнья малын җыярга, икенчесе зур гаскәр белән яу чабарга киңәш иткәннәр. Башка вәзирләрнең киңәш сүзләре текстта юк.

Шаһка соңгы һәм иң файдалы киңәшне бирүче «вәзир» дип аталмыйча, «хәким» диелгән. Ул:

Сүзем ул кем – гадел кыйлың илгә сез,
Кем аның хәйрен соңра белгәйсез,

– дип, шулай ук «Гаделлек белән ил төзек булыр» дигән хикмәтле сүзне кабатлаган. Нәүширван аның сүзен тыңлап, илне иминлектә һәм муллыкта тоткан. Бу хикәят Нәүширванның шөһрәте хәзергәчә сөйләнә дип тәгалләнә.

Икенче бүлек рәхим-шәфкатькә багышланган. Мондый күркәм сыйфатлар Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелүе турында әйтелеп, аларга ия булучыларга Тәңре үзе ярдәм итә дигән пәйгамбәр хәдисе дәлил итеп китерелгән. Бу бүлектә Муса пәйгамбәргә багышланган хикәят бәян ителгән. Көтүдәге сарыкларның берсе качкан һәм Муса аны куып, үзе арып-йончып беткән булса да, рәхим-шәфкать күрсәтеп, киеменә төреп һәм кулларына күтәреп көтүгә алып кайтуы өчен Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрлек дәрәҗәсен ирештерүе сөйләнгән.

Өченче бүлектә сәхавәт-юмартлык турында сүз бара. Юмартлык белән гөнаһлар кичерелер, бәрәкәт ирешер һәм ахирәттәге хәлләре хуш булыр диелә. Бүлектәге хикәяттә йөкче (утынчы) турында сүз бара. Көн саен ташлы таудан утын хәстәрләп, аны ике тәңкәгә сатып, берсен садәка итеп бирүе, икенчесен гаиләсенә тотуы язылган. Бер көнне утынын сатканнан соң яшь егетне кыйнап торучыны күреп, сәбәбен сорашкан. Егет ул кешегә ике тәңкә бурычлы икән. Утынчы аңа үзендәге ике тәңкәсен биргән, ә гаиләсе ач калган. Икенче көнне кайтышлый базарда балык сатучыдан барча халык «балыгың исләнгән» дип көлүләренә шаһит була. Балыкчы үтенгәч, үзенең утынын аңа биреп, балыгын өенә алып кайткан. Балаларыма ризык булыр дип, эчен ярып җибәрсә – аннан энҗе-асылташ чыккан. Шулай итеп, аз нәрсә белән юмартлык күрсәтеп, йөз мең алтын кыйммәтендәге байлыкка ирешкән[180].

---

[180] Балык эченнән энҗе табылу турындагы хикәят Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» әсәрендә дә бар (Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 84–88).

Поэманың дүртенче бүлегендә хәйа-оят мәсьәләсе аңлатылган. Оялу – чын мөселманның сыйфаты дип, пәйгамбәрнең «Хәйа – иманнан» дигән хәдисе дәлил итеп ике мәртәбә кабатланган. Икенчесендә ул «Булмас иман кемдә булмаса хәйа» рәвешендә әйтелгән. Әлеге бүлектә дә гыйбрәтле хикәят урын алган. Борынгы заманда бер гарәп яшәгән җирдә бөтен сулар да тозлы гына булган, төче суның ни икәнен дә белмәгәннәр. Бер заман яңгырлар яумыйча, болын-кырларда үләннәр үсмәгән, корылык килгән. Эчәрлек су да беткән. Болар гомер иткән урыннарын калдырып, күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Гаҗәеп бер – җәннәт кебек чәчәкле-үләнле – зур болынлыкта тукталганнар. Шундагы төче күлнең пычрак суын эчеп, гарәп таң калган һәм бу урынны җәннәт дип, суын – Кәүсәр чишмәсе дип аңлаган. Суны савытка тутырып, киезгә төреп, хәлифәгә илтергә ниятләп, дөясенә утырып сәфәр чыккан. Ерак юлны йокламыйча, ашыгып бара торгач, ауга чыккан хәлифәгә юлыга. «Сиңа гаҗәеп бүләк – җәннәт суын китердем» дип, изге теләкләрен әйтеп тапшыра. Эссе көннәрдә ул су инде исләнгән булса да, хәлифә аны алып, иреннәренә тигерә. «Җәннәт суы икән...» дип, аны китергән гарәпкә мең алтын бирдереп озаттыра. Вәзире сорагач, хәлифә «Ул Форат суын (Евфрат елгасын) кичеп килсә һәм аның суын эчкән булса, үзенең ялгышканын аңлап оялыр иде» ди. Хикәят хәлифәнең нинди игелек иясе икәнен бәкләре аңладылар дип төгәлләнә.

Бишенче баб-бүлектә газыйлык, ягъни дин өчен сугышу бәян ителгән. Бүлек исеме астында ук Мөхәммәт пәйгамбәрнең хәдисе гарәп телендә язылган. Хәдиснең татарча мәгънәсе «Дөньяда батырлык кылучы ахирәт бәхетенә ирешер» мәгънәсендә аңлатылган. Автор елан-чаяннар үтергән кешегә дә җәннәткә юл ачылыр дип, янә бер хәдисне язган һәм Коръән сүзләре белән тагын да куәтләп куйган. Шул ук бүлектә пәйгамбәрнең «Ризыгым – сөңгем күләгәсе астында» мәгънәсендәге хәдисен дә искәрткән. Бу бүлектәге хикәяттә диңгездәге давыл вакытында бер газыйның – изге сугышчының көймәсе җимерелеп, үзен җил бер утрауга чыга-

руы һәм анда күргәннәре тасвирланган. Җәннәт кебек искиткеч матур утрауда алтын-көмештән төзелгән, эче энҗе-мәрҗан белән бизәлгән гаҗәеп нурлы сарай балкып тора. Анда күркәм кыяфәтле пәһлеваннарның берсе газыйга барыр юлын өйрәтеп, бер егеткә юлыгырсың һәм аннан да сорарсың дип җибәрә. Ул егет тә тугры юлны белдереп, бер изге дәрвишне очратырсың, ди. Дәрвиш намазын тәгалләп, газыйга юл күрсәтә. Газый мондый гаҗәп хәлләрнең нәрсә икәнлеген сораша. Ул сарайдагы кешеләр – шәһидләр – дин өчен сугышып мең ел әүвәл һәлак булган изгеләр икән. Ә газыйга юл өйрәтүчеләрнең берсе Җәбраил фәрештә, икенчесе – Ильяс пәйгамбәр, ә бу аксакал үзе – Хозыр икән[181]. Хозыр бу газыйга дога өйрәтеп, газый күз ачып йомганчы өенә кайтып җиткән.

Әсәрнең алтынчы бүлеге сабыр итүгә багышланган һәм исеме астында Коръәннән «Сабыр итегез, сабырлыкта ярышыгыз, Аллаһыдан куркыгыз» дигән аять бирелгән. Сабыр итүнең һәм сабырлык белән гамәл кылуның Аллаһы Тәгалә каршында бик зур савап булуы аңлатылган. Мөхәммәт пәйгамбәрнең сабырлык турындагы ике хәдисе әйтелгән. Йосыфның этисе Ягъкуб пәйгамбәр дә сабырлык нәтиҗәсендә күрешүгә ирешкәнлеге искәртелгән. Сабырлыкның башы бик ачы булса да, ахыры балдан татлырак дип аңлатылган. Бүлек эчендәге сабырлык турында хикәят шулай ук гыйбрәтле. Хорасан патшасы Бусәгыйднең бик гыйлемле һәм хикмәт иясе – Бүл-Мозаффар исемле вәзире булган. Бер көнне патша хозурында вакытта вәзирнең аяк киеме эченә кергән чаян чага башлаган. Ничаклы чакса да, вәзир патша белән сүзен өзмәгән һәм бу хәлне һич тә сиздермәгән. Өенә кайткач кына ул хәшәрәттән котылган. Бу хәбәр патшага ишетелгән һәм ул вәзирне чакыртып, вакытында ук белдермәвенең сәбәбен сораган. Вәзир «киңәшкә лаеклы санап чакыргач, сүзегезне тыңламыйча, чаян чага дип чыккан булсам,

[181] Рабгузи әсәрендә Ильяс һәм Хозыр галәйһиссәламнәрнең Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән тере торулары, тауларда, диңгезләрдә һәм сахраларда йөреп адашкан яки бәлагә тарыган кешеләргә юлларын табарга ярдәм итүләре турында язылган (Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи..., 1881. – Б. 39, 372).

эшкә зыян гына килер иде» дип җавап биргән. Патша вәзиренең акылына һәм сабырлыгына хөрмәт йөзеннән мәмләкәтне аңа тапшырган. Сабырлык белән зур нәтиҗәгә иреште дип, автор сүзен тәмамлаган.

Җиденче баб-бүлектә вафа кылу, ягъни ышанычлылык турында сүз бара. Бу бүлектә шулай ук пәйгамбәр хәдисенең татарча мәгънәсе ике мәртәбә кабатлап язылган. Бүлек эчендәге хикәяттә Бәгъдад шәһәренең бай мәхәлләсендәге хәл тасвирланган. Анда яшәүчеләр үзара ярдәмләшеп, беркемне дә мохтаҗлыкка калдырмаска тырышканнар. Хамид Коттан исемле берәү бөлгенлеккә төшкәч, мәхәллә халкы Шәмгун исемле бик бай бер яһүдигә мөрәҗәгать иткән. Аның Хамид Коттанга бурычка биш мең акча биреп торуын сораганнар, «вакытында кайтара алмаса, үзебез түләрбез» дигәннәр. Шәмгун Аллаһ хакы өчен ризалашып вәгъдә биргән. Төнлә йоклаганда төшендә Мөхәммәт пәйгамбәрне күргән. Пәйгамбәр аның изге гамәлен хуплап, тугры динне кабул итәргә өндәгән. Нәтиҗәдә, Шәмгун ислам динен кабул иткән һәм рәхәтлеккә ирешкән.

Сигезенче бүлек сыйдыкка (туры сүзлелеккә) багышланган. Бүлек исеменең астында ук Коръәннән аять бирелгән. Яхшы теллелекне мактап, автор «Бер тылсым бу, әл-гаҗәп ирер бу тел» дип, бик зурлаган һәм «Ул – тылсым ачкычы» дип өстәгән. Пәйгамбәрнең «Башка ни килсә дә телдән килер» дигән хәдисен аңлаткан. Бүлектәге хикәят тә нәкъ шул хакта. Бер солтан (текстта ул «шаһ» дип тә аталган) бәкләрен һәм вәзирләрен җыеп, сөйләшми торган улы турында киңәш итеп,ауга чыгарга карар итәләр – анда теле ачылыр, диләр. Ауда патшаның улы – шаһзадә дә үзенең тәрбиячесе белән катнаша. Бер заман күктә очкан казлар кычкырып аваз сала. Тәрбияче үзенең ау кошын җибәреп, бер казны тота. Шунда шаһзадә кинәт телгә килеп: «Телен тыйган котылды, тыймаганы тотылды» дип, хәдис мәгънәсен әйтеп куя. Моны ишеткән тәрбиячесе «Сөенче!» дип, шаһ янына ашыга. Шаһ бик сөенеп аңа бүләкләр бирә һәм улын китерергә боера. Ләкин улы әтисенә бер сүз дә әйтми. Шаһ бу хәлдән зар-интизар булып, «ялган хәбәр китердең» дип, тәрбиячене үтерергә куша.

Шунда шаһзадә тагын «Телен тыйган котылды, тыймаганы тотылды» сүзләрен әйтеп куя. Аның сүзләрен ишетеп, шаһ шатлыгыннан тәрбияче хезмәтчесен азат итә. Инде этисе улыннан «ник сөйләшмәдең – серен әйтче» дип сорый. Улы үзенең остазы язып биргән бер хәдисне җае килгәндә сынап карармын дип ниятләгәнен әйтә, «шуңа күрә сөйләшми йөргән идем» дип, гафу үтенә. «Сынадым – рас икән, әгәр сахрадагы каз телен тыйган булса, аны ау кошы тотмас иде, ә тәрбияче телен тыйса – аны үтерергә боермас идегез», – ди.

Тугызынчы бүлектә самитлык (аз сүзлелек) турында бәян ителгән, дәлил итеп пәйгамбәр хәдисе гарәп телендә һәм татарча тәрҗемәдә бирелгән. Бүлек эчендәге кыска хикәят тә шул мәсьәләгә багышланган. Каннух дигән җирдә хикмәт иясе, галим бер аксакал булган. Бер көнне мөнбәрдән вәгазь сөйләгәндә «самит (аз сүзле) кеше оҗмахка керер» дигән хәдисне аңлаткан. Мәҗлестә катнашкан аз сүзле бер егеткә бу вәгазь бик тәэсир иткән. Бер бәдбәхет яһүди ул егетне кыерсыткан. Гәрчә егет пәһлевандай һәм ул яһүдине юк итәрлек хәлендә булса да, дәшмичә калган. Егет төшендә Мөхәммәт пәйгамбәрне күргән һәм ул Җәбраил фәрештә аша Аллаһы Тәгаләнең егетне ярлыкадым, урыны оҗмахта дип җиткерүен әйткән. Уянгач, теге яһүд егетнең ишеген кагып, «Динегез хаклыгын күрдем, мөселман булыйм» дип, үзенә иман өйрәтүен үтенгән. Яһүд тә үзе күргән төшне сөйләп бирә – бөтен халык җыелган, җиде тәмуг янәшә тезелгән – «Бу самитны рәнҗеткән» дип, тәмуг утына атарга фәрман ирешкән. Куркып-сискәнеп уяну белән Аллаһы Тәгаләгә иман китергән һәм барча малын Хак юлында сарыф иткән.

«Нуры содур»ның соңгы бүлеге – унынчы бабы гафу итүгә багышланган. Анда «Гафу кыйлмак – Тәңре боерыгы, боерыгын тотканга җәннәт бирер» диелә. Хикәяттә борынгы заманда Мәсгуд һәм Ибне Әшгат исемнәрендәге, бер-берсенә дошман ике шаһ булып, сугышып та бер-берсен җиңә алмаулары сөйләнә. Ниһаять, Мәсгуд бик зур гаскәр җыеп, бик каты бәрелештән соң Ибне Әшгат гаскәре җиңелгән. Әсирләр арасыннан бер егет Мәсгуд шаһка мөрәҗәгать итеп, «Син теләгән эшне (җиңүне)

Аллаһы Тәгалә сиңа бирде, инде син Хак теләгәнне үтә – безне азат ит» дип сорый. «Юмарт Аллаһыдан һәрвакыт юмартлык килер, инде син дә, шаһ, безгә киң күңеллелек кыл», – ди. Шаһ бу егетнең күркәм сүзләрен кабул итеп, Аллаһ ризасы өчен әсирләрнең барчасын азат кылган.

Әлеге – соңгы бүлектәге бу хикәяттән соң Мөхәммәдьяр «Бу китап хан догасы белән тәмам...» дип, әсәрнең бетем өлешен язган. Ул исә үзе бер баб-бүлек зурлыгында диярлек. Анда ханны мактау сүзләре дә күп.

Бетем өлешеннән соң заһид (дәрвиш, суфый) турындагы шактый күләмле хикәят бәян ителгән. Бәни Исраил эчендә (яһүдләр илендә) бер заһид булган. Диңгез эчендәге утрауда татлы сулы чишмә янында зур тирәк – җимеш агачы үскән. Суфи шунда яшәп, намаз укып, чишмәдән су эчеп, ураза тоткан, агачның җимеше белән авыз ачкан. Ул көндезләрен ураза тотып, гыйбадәт кылып биш йөз ел гомер иткән. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә бу суфины ярлыкап, җәннәт насыйп иткәнлеген әйткән. Суфи җөрьәт итеп «күпме еллар кылган ураза-намазларым кая барды – шуны белдерсәң иде», – дип сораган. Хак Тәгалә: «Сине юктан бар иттем, гыйбадәт кылу өчен сихәтлек һәм акыл бирдем, әгъзаларыңны төзек яраттым», – ди. Әңгәмә вакытында дәрвиш бик нык сусаган. Ул арада бер күркәм фәрештә су тулы савыт белән аның каршысына килә. Эчәргә сорагач, фәрештә: «Кылган гыйбадәтләреңне миңа бирсәң, эчәрсең», – ди. Заһид йөз еллык өлешен бирмәкче була, тик фәрештә аңа гына риза түгел. Сусаудан йөдәп, бу суфи барча гыйбадәтен бирергә күнгән. Шулай итеп, бөтен кылган гыйбадәтләрен бер эчәрлек суга алмашкан. Аллаһы Тәгалә аңа «биш йөз еллык гыйбадәтеңне бер эчәрлек суга саткан өчен тәмугка керәчәксең», ди. Суфи «мәрхәмәтең белән мине гафу ит» дип ялына-ялвара. Хак Тәгалә үзенең киң рәхмәте белән аны кичергән һәм җәннәткә керткән. Бу хикәяттән соң авторның Аллаһы Тәгаләгә ялвару сүзләре язылып, бу әсәрнең ханга багышлануы кабатланган һәм күп мәдхияләр укылган.

«Нуры содур» поэмасының ахырында, сүз сөрешенә бәй-

ләп, тагын бер кечкенә хикәят теркәлгән. Анда Сөләйман пәйгамбәрнең үз бикләрен һәм вәзирләрен зур бәйрәм-туй була дип җыйганлыгы турында сүз бара. Бик күп кунаклар үзләре белән төрле тансык бүләкләр алып килгәннәр. Алар арасына бер заманерактан арып-талып, авызына чикерткә ботын кабып тургай да килеп җиткән. Ул Сөләйман пәйгамбәргә мөрәҗәгать итеп, «елкы яки куй кебек зур бүләкләр алып килмәдем, үзем тапкан шушы күчтәнәчне китердем», ди. Кошлар телен аңлау сәләтенә ия булган пәйгамбәр тургайны бүләкли, ярлы тургай сөенеп өенә кайта. Әлеге хикәяткә ялгап автор үзенең, тургай кебек, ханга шушы китапны тәкъдим итүен белдергән һәм аңа мәдхия сүзләре яудырган.

Текстның ахырында автор үз исемен һәм әсәренең кайсы елда язылганлыгын, ничә бәйттән (икеюллыктан) торганлыгын шигъри юллар эчендә белдергән. Бу әсәрне укучылардан үзенә атап дога кылуларын, күчереп язучыларны китапның сүзләрен үзгәртмәскә-бозмаска да өндәгән.

Сәлим Гыйләҗетдинов «Нуры содур» текстын урта гасырларда фарсыча иҗат иткән мәшһүр әдипләрдән Фәрideддин Гаттар, Җәлалетдин Руми, Сәгъди Ширази, Мәхмүд, Баба Фагани әсәрләре белән чагыштыруы нәтиҗәсендә, кызыклы нәтиҗәләрен язган иде. Мөхәммәдьяр аларның берсен дә тулаем тәрҗемә итмәгән, ә аерым сюжетларын һәм төп нигезләрен файдаланып, үзенең оригиналь поэмасын иҗат иткән, диде ул. «Нуры содур» үзенең эчтәлеге һәм бүлекләренең исемнәре буенча Гаттарның һәм Мәхмүднең бер төрле үк исемдәге – «Пәнднамә» дип аталган әсәрләренә якынрак тора дип тәгаенләгән С.Гыйләҗетдинов[182]. «Нуры содур»дагы хәлифәгә изге су илткән гарәп турындагы хикәят Руминың «Мәснәви мәгънәви» әсәрендәге хикәяткә охшашлыгын, хәтта кайбер бәйтләре тәңгәл килүен ачыклаган һәм чагыштыру өчен ике текстан өземтәләр биргән. Мөхәммәдьярда төп сюжет сызыгы

[182] Гилязутдинов С. Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX в). – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ, 2011. – С. 95.

сакланса да, ул аны үзенчә корган дип язды галим[183].

«Нуры содур» поэмасының эчтәлегенә бәйле аңлатмаларга һәм шәрехләргә тукталмадык. Чөнки бу әсәр инде шактый өйрәнелгән, ә тикшерелмичә калган хәтлесен белгечләр ачыклар.

## Исемнәр һәм атамалар

Әсәр текстында күптөрле исемнәр һәм атамалар бар. Аларны күзаллау өчен гомуми рәвештә төркемләп язып үтәбез.

Әйтеп үтелгәнчә, китап авторы үзенең исемен барлыгы өч урында (36, 61, 775 нче бәйтләрдә) һәм «Нуры содур» әсәрен багышлаган Сахибгәрәй хан исемен бер урында (19 нчы бәйттә) күрсәткән.

Поэманың иң башында ук «Бисмилләһи Рахмәнир-Рахим» дип язылган, текстның иң беренче сүзе «Ходавәндә» – Аллаһы Тәгаләнең исеме белән башланган. Бу әсәрдә иң күбе Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре һәм сыйфатлары теркәлгән, алар барлыгы 35 төрдә булып, текстның буеннан-буена кабатланып дәвам иткән. Мөхәммәдьярның бу әсәрендә «Хак» атамасы иң күп – утыз мәртәбә кабатланган, Тәңре дип 22 мәртәбә телгә алынган. Шулай ук борынгы төрки телдәгечә Изи һәм Уган рәвешләрендә, Хак Тәгалә, Аллаһ, Иляһи, Иляһел-галәмин, Хода, Ходавәндә, Рабб, Рахман, Сөбхан, Гафур, Гаффар, Гани, Кәрим, Хәким, Бари, Кадыйр, Җәлил, Зөлҗәлал, Самигъ, Ләтыйф, Мөҗиб, Падишаһ, Пәрвәрдигяр һ.б., шулай ук, «төнне айдын кыйлгучы», «языклар дәфтәрен җуйгучы» кебек эпитетлар белән аталган.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең исеме, мактаулы атамалары һәм сыйфатлары барлыгы 32 төрдә теркәлгән. Алар: Мөхәммәд, Мостафа (иң күбе – 12 мәртәбә), Хәбиб, Хак Хәбибе, Хак рәсүле, рәсүлел-галәмин, фәхре дин, фәхре галәм, фәхре җәһан, фәхре садыйк, фәхрел-мөрсәлин, фәхрел-әнам, сахибе мигъраҗ, шәфигыль-мөзнибин, садрел-кәрам, сәрвәр һ.б. Арада «рисаләт тиңезенең гәүһәре», «нәбүвәт мәгъдәненең җәүһәре» кебек шагыйранә төрләндерелгәннәре дә бар.

---

[183] Шунда ук. – Б. 95–103.

Дини, тарихи һәм мифологик шәхесләрдән Мөхәммәдьяр 32 затның исемнәрен язган. Пәйгамбәрләрдән: Мөхәммәд, Шөгаиб, Муса, Дауд, Сөләйман, Ягъкуб, Йосыф, Ильяс, Хозыр, дүрт хәлифә: Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали, сәхабәләрдән Җабир Әнсари, шулай ук Җәбраил фәрештә, татар ханнарыннан Мөхәммәдәмин хан һәм Сахибгәрәй хан исемнәре аталган.

Хан-хөкемдарны мактаган затлы, купшы һәм күркәм, шулай ук тантаналы сыйфатлаулар бу әсәрдә барыннан да күбрәк. Андыйларны аерып тупламадык. Бары тик, еш кулланылган эпитетлардан «ханнар ханы», «шаһи галәм», «шаһи җәһан», «фәхрел-өмәм»не искә алу белән чикләнәбез һәм «җәһан солтаннарының солтаны», «бу заман газыйларының солтаны» кебек озын сыйфатламалар да аз түгеллеген искәртәбез. «Нуры содур» текстында ханны мактауның төп өлешләре әсәрнең башында (19–68 нче бәйтләрдә), шулай ук ахырына таба 606–639, 707–748 нче бәйтләрдә теркәлгән. Болардан тыш, һәр баб-бүлек башында диярлек иң беренче юллар ханга мөрәҗәгать сүзләрен тәшкил итә, башка урыннарда да мәдхия сүзләре язылган. Гомумән, «Нуры содур»ның 150 икеюллыктан артык өлеше (ягъни, бөтен текст күләменең биштән бере чамасы) Сахибгәрәй ханны мактау, аңа дога багышлау һәм данлап мөрәҗәгать итүләрдән тора. Гомумән, Сахибгәрәй ханга бу әсәрдәге мәдхияләр татар әдәбияты тарихының аерым тикшерүгә лаек, үзенчәлекле өлеше.

Шунысын искәртү зарур, башка бик күп исемнәрнең әсәр күчермәләрендә төрлечә язып йөртелгәне кебек үк, текстның 71 нче бәйтендәге Мөхәммәдәмин хан исеме дә башкачарак теркәлгән. Югары Курса кульязмасында ул Мөхәммәдәбин дип, ә Олы Мәңгәр, СПб-1, СПб-2, Барда һәм Сарман күчермәләрендә Мөхәммәдимин дип язылган.

Текстта төрле шәхесләрдән Нәүширван, Бәһрам, Афрүәсйаб (Әфрасийаб), Хатим Тай, Хәсән Басри һ.б. исемнәре теркәлгән, «әсхабе кәһф» кебек җыелма исем дә бар.

Поэмада бер дистәгә якын географик атамалар да очрый: Болгар, Урда, Казан, Бәгъдад, Иран, Туран, Хорасан, Форат (Евфрат), Каннух.

Күптөрле атама-исемнәрнең әсәрдә мул кулланылуы авторның тирән белемгә, киң мәгълүматка, бай шигъри зиһенгә ия булганлыгын күрсәтә.

Әсәрдәге күпчелек атамаларның аңлатмалары һәм аларга карата искәрмәләр 1997 елгы басма китапта бар, шунлыктан монда аларны кабатлау ихтыяҗы юк.

## Текстның шигъри төзелеше

«Нуры содур» унберәр иҗекле икеюллыклар калыбында иҗат ителгән. Ләкин аның шигъри үлчәменә сыешмаган юллар, ритмик төгәлсезлекләре бар.

Элекке кулъязма әсәрләрне күчерүчеләрнең текстларга үзләреннән сүзләр, кушымчалар, аерым гыйбарәләр һәм хәтта юллар өстәп җибәрү, ә еш кына булганнарын төшереп калдыру, ялгышлык белән сүзләрен алмаштыру яисә юлларын бутау күренешләре археографиядә мәгълүм әйбер. Андый очракларны «Нуры содур» күчермәләрендә дә күрәбез. Поэма турында иң беренче мәкалә язган Нәкый Исәнбәт тә бу мәсьәләне искәрткән. Ул болай дип язган: «Күчерүчеләрнең игътибарсызлыгы һәм күп хата җибәрүләре аркасында сүзләр төшереп калдырылган, ә кайбер юлларга артык сүзләр өстәлгән. Шунлыктан, бөтен юлларда да иҗек саны бер төсле түгел...». Бу мәкаләсе белән бергә «Нуры содур» текстыннан тәкъдим ителгән өлешләрендә «Без үлчәүгә сыймый торган кайбер артык сүзләрне җәя эченә алып күрсәттек, шулай ук сүзнең төшеп калганлыгы күренеп торган урыннарга да шартлы рәвештә сүзләр куеп, аларны җәя эченә алдык»[184] дип аңлаткан.

Татар шигърияте антологиясендә: «Шигырь техникасы ягыннан Мөхәммәдьярда төгәл эшләнгән строфалар, төгәл килгән рифмалар, матур-матур поэтик кабатлаулар бар» диелгән[185].

Шагыйрь әсәрләренең тәнкыйди текстлары басылган 1997 елгы китапта Шакир Абилов «...текстларның ялгыш язылула-

[184] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры..., – 1941. – №4. – Б. 74.
[185] Татар поэзиясе антологиясе..., 1956. – Б. 6.

ры, хәрефләрнең, хәтта сүзләрнең төшеп калулары, юллардагы шигъри үлчәүнең бозылу очраклары – сүзләрнең, иҗекләрнең җитмәве яисә артып китүләре, аерым бәйтләрдәге сүзләрнең бөтенләй буталып язылулары, шигъри юлларның алмашынып килүләре»[186] турында әйткән.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең шигъри-ритмик кимчелекләре турында Мәсгуд Гайнетдин дә язган иде[187]. Мәсәлән, аның татар әдәбияты ядкярләрен бастырганда күзәтелә торган кимчелекләрнең берсе турында язганын искә алыйк: «Ул чор шигъриятендә «вә» сүзенең кыска укылыш вариантлары булган – «ву», «вү» рәвешендә укылган. Биредә дә нәкъ шулай сорала: «берсән-у барсән» – «ү»не «вә»гә әйләндерү белән тагын бер тын өстәлә. Шигырь калыбы бозыла, шигырь юлы нәсер яңгырашына күчә. «Берсән-ү-барсән һәм гафур рәхим» җырлап тора»[188].

Хатыйп Миңнегулов бу мәсьәләдә шулай ук электән язып килә. Ул болай ди: «Кайберәүләрдән «Мөхәммәдьяр әсәрләрендә ритмик төгәлсезлекләр бар» дигән фикерне ишетергә туры килә. Чыннан да бу шулай. Әмма биредә автор, нигездә, гаепле түгел. Аның шигъри таланты, вәзен-кафияне шактый тирәнтен тоеп иҗат итүе бәхәссез. Шагыйрь поэмаларындагы ритмик һәм текстологик җитешсезлекләр, иң беренче чиратта, китапны күчерүчеләр һәм бастыручылар эшчәнлеге белән бәйле. Соңгы басмаларда, мәсәлән, аерым сүзләрне язуда шигъри үлчәм таләбен исәпкә алып җиткермәү, изафәт бәйләнешен хәтердән чыгару очраклары бар. Гамәлдәге графиканың җитешсезлеге дә текстны бирүдә кыенлыклар тудыра...»[189].

Ритмик төгәлсезлек очракларының кайберләренә тукталабыз. Әсәрнең иң беренче юлындагы «Ходавәндә, белүрсән барчаны әсрар» дигәндә үк бер иҗек артык. Текстның башы сакланган кульязмаларның өчесендә дә (Югары Курса, Олы Мәңгәр,

[186] Мөхәммәдьяр. Нуры содур..., 1997. – Б. 31.
[187] Гайнетдин М. Хакыйкать юлыннан..., 2001. – Б. 105–111.
[188] Шунда ук. – Б. 110–111.
[189] Миңнегулов Х. Дөньяда сүземез бар..., 1999. – Б. 104.

СПб-1) ул бер төрле үк. Әмма мәгънәсенә караганда, «барчаны» сүзендәге «-ны» кушымчасы артык. Чөнки «әсрар» – «серләр» мәгънәсендә һәм «барчаны әсрар» дигән сүзтезмә «барчаны серләр» рәвешендә булуы мөмкин түгел, «-ны» кушымчасы ялганса да, «әсрарны» диелгән булыр иде.

Шул ук беренче бәйтнең икенче юлында исә ике иҗек азрак. 1997 елгы басмада ул «Йазуклык колуң мән гөнаһкяр» дип басылган, чөнки төп чыганагы итеп алынган һәм ул вакытта Ш.Абилов кулланган бердәнбер күчермәдә (СПб-1) әлеге шигъри юл нәкъ шулай теркәлгән. Ә Югары Курса һәм Олы Мәңгәр кулъязмаларында «колуңдур» дип теркәлгән. Димәк, бер иҗеккә булса да артык.

Менә боларга охшаш – иҗекләр саны күп булу һәм җитмәү очраклары «Нуры содур» текстында шактый. Югарыда әйтеп үтелгән сәбәпләргә өстәп, кулъязма истәлекләрдә еш очрый торган тагын бер төрлесен искәртик. Төрки-татарча язылган шигъри әсәрләрнең текстларында булган гарәпчә һәм фарсыча гыйбарәләрнең мәгънәләрен яки башкача аңлатма сүзләрен кәгазь читләрендә язу кебек үк, еш кына юллар арасында теркәп кую гадәте булган. Аларны авторлары да, текст күчерүчеләр дә өстәгән[190]. «Нуры содур» кулъязмаларындагы шигъри юлларда артык сүзләрнең кайберләре нәкъ шундый аңлатма-шәрехләрдән килеп чыкканлыгы аңлашыла. Мәсәлән, 256 нчы бәйтнең икенче юлында кулъязмаларның кайберләрендә (мәсәлән, Югары Курса, Ижевск) «йәш ут галәфдин» дигән сүзтезмә бар. Мондагы «ут» (үлән) сүзе әүвәлгерәк протографларда «галәф» (үлән) сүзенең өстенә аңлатма буларак теркәлеп, күчерүчеләрнең берсе аны шигъри текст юлына кертеп җибәргән. Моның тәгаен шулай икәнлеге бүтән күчермәләрдә (мәсәлән, СПб-2 нөсхәсендә) «ут» сүзенең булмавыннан ачык күренә. 22 нче бәйтнең бе-

[190] Татар кулъязмаларының мондый традициясе XX гасыр башына кадәр дәвам иткән. Мәсәлән, Н.Солтанбәковның XIX гасыр ахырыннан 1920 нче елларга кадәр иҗат иткән әсәрләренең автографларында шундый аңлатма-шәрехләр бик күп (Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 50–199).

ренче юлында Галинең каһарманлыгы әйтелеп, икенче юлда «һәйбәтендин» (дәһшәтеннән) дигән гыйбарәдән соң кулъязмаларда теркәлгән «аның» сүзе дә элегрәк аныклагыч (аның – ягъни, Галинең) буларак юллар арасында искәртелгән һәм кайбер күчермәләрдә (Югары Курса, СПб-2) шигъри юлга кертеп язылган. Өстәмә сүзләрне текстка кертү әсәрләрне күчергән кешеләрнең талымсызлыгыннан дип каралырга тиеш түгел. Юллар арасындагы андый сүзләрне үзләренә кадәр күчергән кешеләр башта төшереп калдырып, аннары өстәп язган төп текст өлешләре дип кабул иткәннәр дисәк, шәт, ялгышмабыз.

Әйтеп үтелгән 22 нче икеюллыкның ахырына күчерүчеләр тарафыннан рифмадаш итеп өстәлгән «ирүр» сүзләре дә артык.

Авторның исеме белдерелгән 61 нче бәйттә «Атамыз – Мәхмүд, догачы, исмем Мөхәммәдьяр» юлында 11 урынына 14 иҗек. Моңарчы чыккан китапларда ул шушы озын рәвештә басыла килде. Текст күчермәләренең өчесендә (Олы Мәңгәр, СПб-2, Сарман) ул шулай теркәлгән, ә СПб-1 кулъязмасында авторның исеме Мөхәммәд диелгән. Ләкин төп хикмәте «исмем» (исемем) сүзенең артык булуында. Югары Курса күчермәсендә ул сүз юк: «Атамыз – Мәхмүд, догачы – Мөхәммәдьяр». Әле монда да, безнең фикеребезчә, «атамыз» дигәндәге «-ыз» кушымчасы күчерүчеләр тарафыннан өстәлгән. Гарәп хәрефләре белән язылышта ул бик гади – «м» хәрефенең сүз ахырындагы бераз авышрак язылышы өстенә фәкать бер нокта өстәлүдән килеп чыккан. Әлеге артык кушымчадан башка укылышта бу шигъри юл 11 иҗекле – «Атам – Мәхмүд, догачы – Мөхәммәдьяр» (Мәсгуд Гайнетдин язганча, «җырлап тора»). Басылып чыккан китапларда «догачы» сүзен Мәхмүдкә карый дип аңлатулар да булды. Ләкин бу очракта «догачы» дип автор үзен атаган. Чөнки әсәрендә хан өчен дога сүзләре мул итеп тезелгән һәм 50 нче бәйттә «Догачы мән шаһның изге затына» дип, ап-ачык белдерелгән. «Догачы» дип әйтүе дә нәкъ шушы әсәргә бәйләп язылган. Ә кайбер хезмәтләрдә фаразланганча, Мөхәммәдьярны «догачы» вазифасындагы аерым затлар төркеменә нисбәт итүдән тыелабыз.

Тексттагы 19 нчы бәйтнең «Олуг солтан мөгаззам Сахибгәрәй хан» юлында бер иҗек артык. Ике күчермәдә (Олы Мәңгәр, СПб-2) юлның алдында «бан», ә Барда нөсхәсендә «йан», Исәнбәтнекендә «йа» дип язылып, иҗекләр тагын да күбрәк. Ләкин күчерүчеләр өстәгән «бан» сүзе нәрсәне белдергән булуы аңлашылмый[191]. СПб-1 күчермәсендә әлеге юл «Уг солтан мөгаззим Сахибгәрәйгә» дип, Барда нөсхәсендә юлның ахыры «Сахибкә, әй, җан» дип, икесендә дә хаталы рәвештә язылган.

Югарыда китерелгәннәр шигъри ритмиканың бозылуына сәбәпче берничә мисал гына.

«Нуры содур» текстында бер төрле үк язылсалар да, төрле мәгънәләргә ия булган сүзләр дә бар. Мәсәлән, 476 нчы бәйткә игътибар итик:

Сыйдык, йәгъни күни сүзләмәк булур,
Күни сүзләгән кеше дәүләт булур.

Мондагы рифмадаш сүзләрнең беренчесе хәзерге мәгънәсендәге «булыр», ә икенчесе борынгы төрки-татар телендәге «табар» мәгънәсенә ия. 429 нчы бәйттәге «Вәгъдәгә кыйлган вафа – булур кәрим» дигәндә дә шундый ук мәгънә (табар) очрагын күрәбез.

Янәшә килгән сүзләрне ялгыш аңлау ихтималы да бар. Мәсәлән, 478 нче бәйттәге «Күни сүз берлә булур кечек олуг» юлын алыйк. 1997 елгы тәнкыйди текстта бу юл ахырындагы сүзләр «кечек-олуг» дип, парлы итеп тәкъдим ителгән. Югыйсә, монда «кечек» кешенең «күни сүз берлә» олуг булуы күздә тотылган.

Поэма текстында «кем» сүзе шактый кулланылган һәм ул күпчелек очракта «ки» кисәкчәсен белдергән. Әйтик, 8 нче бүлектәге хикәяттә бер үк хәдиснең мәгънәсе 506 һәм 521 нче бәйтләрдә «Һәр кем тотты телене...» дип, ә 514 һәм 529 нчы

[191] Госманлы империясенең Европа өлешендәге (Болгария, Венгрия, Хорватия һ.б.) кайбер хәрби-административ идарә башлыклары «бан» дип аталган һәм ул «хуҗа» мәгънәсендә дә кулланылган. Ләкин «дөнья шаһы, ханнар ханы» Сахибгәрәй хан нәкъ шул сүз белән сыйфатланган дип булмый.

бәйтләрдә «Һәр ки тотты телене...» рәвешендә теркәлгән булуы – моның ачык мисалы. Шулай ук, 4 нче бүлектәге 231 нче бәйттә «Кемгә кем кыйлса иманны Хак гата» дигәндә Аллаһы Тәгаләнең иман бүләк итүе турында сүз барганда, «кем» дип, башка берәүне күздә тоту ихтималы була алмый. Димәк, бу очракта да аның «ки» кисәкчәсенә тәңгәл кулланылганлыгы аңлашыла. Тексттагы «чөнки», «чөнкем» язылышлары да боларга охшаш.

Әсәр текстындагы «гашыйк» һәм «гыйшык» сүзләре (мәсәлән, 471, 473, 750, 752 нче бәйтләрдә), шулай ук «күңел», «күңел шәйхе», «күңел ләүхе», «дил», «җан-у-дил» кебек һ.б. гади генә тоелган сүзләр дә суфичылык әдәбиятында кулланылган мәгънәләре ягыннан аңланырга тиешле.

Гомумән, «Нуры содур» текстының шактый үзгәрешләргә дучар булуының объектив сәбәбе бар – 1541 елда иҗат ителгән бу әдәби ядкярнең иң элекке тулырак кулъязма күчермәсе XVII гасыр ахырыныкы. Димәк, әсәр иҗат ителгәннән соң бер гасыр ярым вакыт үткән. Ә иң тулы дип исәпләнгән Югары Курса нөсхәсе Мөхәммәдьяр «Нуры содур»ны язганнан соң ике гасыр үткән чорга карый. Автор язган текстның 150–200 ел эчендә үзгәрешләр кичерүе һич тә гаҗәп түгел.

## Бу китаптагы текст үзенчәлекләре

Бу китапта «Нуры содур» поэмасының тексты өчен төп нигез итеп Югары Курса кулъязмасы алынды. Кулъязманың үзендә теркәлмәгән баб-бүлек исемнәре, шулай ук күчерүче тарафыннан төшереп калдырылган биш икеюллык һәм аерым гыйбарәләр, сүзләрнең өлешләре яки кушымчалары бүтән күчермәләр буенча өстәлде һәм дөресләп бирелде. Өстәмә яки ялгыш язылганны алыштырган сүзнең кайсы күчермә буенча бирелгәнлеге билгеләнде. Ә күчермәләрнең күбесенә хас булган, Югары Курса кулъязмасында гына төшеп калган яисә ялгыш язылган сүзләрнең кайсы күчермә нигезендә тулыландырылуы яки киметелүе аерып күрсәтелмәде.

Шунысын искәртү зарур, төрле күчермәләрдәге вариант-

ларны куллану нәтиҗәсендә, күчерүчеләр өстәгән яисә төшереп калдырган шактый урыннарга ачыклык керде һәм текст шактый камилләште. Тик шулай да, аерым гыйбарәләрнең урынсыз кулланылган булуы сизелсә дә, төп асылларын ачыклап булмады.

Әсәрнең текстында шигъри ритмикасы бозылган, күчерүчеләр тарафыннан төшереп калдырылуы сәбәпле, иҗекләр җитмәгән кайбер урыннарда контекстка ярашлы аерым сүзләрне квадрат җәяләр эчендә өстәргә җөрьәт иттек[192].

Төп кулъязма текстына кертелгән бөтен өстәмәләр һәм үзгәрешләр китап ахырындагы искәрмәләр бүлекчәсендә төгәл итеп күрсәтелде. Шунда ук текст өчен кулланылган төп кулъязманың бөтен төрле палеографик үзенчәлекләре (күчерүче төзәтмәләре, хаталы язылышлар һ.б.) бәйтләргә нисбәт итеп искәртелде. Кайбер мәсьәләләр кулъязманың тасвирламасында да аңлатылды.

Югары Курса кулъязмасындагы текстның башка күчермәләр белән чагыштырганда аермалы булган бөтен очракларын да (сүзләрдәге, исемнәрдәге, бәйт юлларындагы һәм аларның урыннары һ.б.) искәрмәләрдә күрсәтү максаты куелмады.

Борынгы текстларны хәзерге графикада бирүдә төп чыганактагы язылыш үзенчәлекләрен тулырак белдерү традициясен сакларга тырыштык. Гәрчә гарәп хәрефләре белән теркәлгән текстлардагы «белеб, булур, килүр, күб, кыйлыб, табты» кебек сүзләрнең язылышлары сөйләмдәге яңгырашны белдерми.

Әсәр кулъязмасында бер үк сүзләрнең: *мин/мән, син/сән, ничә/нәчә, башга/башка, ирер/ирүр* кебек төрлечә язылышлары да үзгәртелмәде.

Текст белән эшләгәндә кулайлык өчен кулъязманың кәгазь номерлары һәм бәйт-икеюллыкларны билгеләгән шартлы саннар күрсәтелде. Шуңа игътибар итү мөһим – бу китаптагы бәйт номерлары 1997 елгы басмадагыларга тәңгәл килми.

Тексттагы архаиклашкан төрки-татар сүзләренең, гарәп һәм фарсы телләрендәге җөмләләрнең, шул ук телләрдән

---

[192] Төгәл итеп әйткәндә, барлыгы 15 урында: икешәр мәртәбә *ки, мән, хуш,* һәм, берәр тапкыр *аны, барча, бер, бу, камуг, кем, ул* сүзләрен өстәдек.

кергән алынма сүзләрнең аңлатмалары һәм тәрҗемәләре китап ахырындагы сүзлектә туплап тәкъдим ителде.

Китапта Югары Курса кульъязмасында «Нуры содур» тексты теркәлгән өлешенең тулы факсимилесе урнаштырылды.

Поэма текстындагы сүзләрнең дөресрәк укылышын тәэмин итү өчен өстәмә «ק» һәм «ғ» хәрефләре кулланылды. «Ләм» (л) хәрефе нечкә укылырга тиешле кайбер урыннарда нечкәлек билгесе куелды. Өрелмәле «вә» (вү) теркәгече әйтелеш таләбенчә «ай-у-йыл», «йаз-у-кыш» рәвешендә язылды.

Китап ахырында Югары Курса кульъязмасының тулырак тасвирламасы бирелде.

Бу хезмәт «Татар археографиясе» сериясендә нәшер ителүенә күрә, археографик һәм палеографик мәсьәләләргә күбрәк игътибар юнәлттек. Ә кайбер хезмәтләрдә язылганча, «Нуры содур» авторын денсезрәк итеп бәяләү, аның утопияче, демократ, оппозиция вәкиле, революционер, диссидент дәрәҗәсендәге идеологик карашларын ачыкларга омтылу безнең бурыч түгел.

***

Китапны басмага хәзерләгәндә күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директоры урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинга, тарихчы Сөләйман Рәхимовка, тарих фәннәре кандидаты Ильяс Мөстәкыймовка, Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге мөдире Энҗе Сабировага, шул бүлек хезмәткәре Айрат Сәмигуллинга ихлас рәхмәтләремне белдерәм.

# НУРЫ СОДУР

*1а кәгазь* ***Бисмилләһи Рахмәнир-Рахим***

1 Ходавәндә, белүрсән барча әсрар,
Йазуқлуқ қолуңдур мән гөнаһикяр.

Белүрмән, күб торур җөрм-ү-гөнаһым,
Мәгәр күз йәшем булғай ғозр-у-хаһым.

Ки йуқдур сәндин үзгә һич химайәт,
Сән ирүрсән кем һәмишәи хәйат.

Бәхаққы абруйи әүляде адәм
Аныңлә фәхер итәр кем ду ғаләм.

**Нәғте рәсүлуллаһи саллаллаһу**
**ғәләйһи вәссәлләм**

5 Сәйидел-кәүнәйн, фәхрел-мөрсәлин,
Хатәм ирүр ул рәсүлел-ғаләмин.

Чөн қыйлды Хақ рәсүлен кем ғинайәт,
Башынға кидеребдер таҗ рисаләт.

Вәликин барча андин нур табты,
Тәқи ризван, биһишт-ү-хур табты.

Җиһан-у-җан ғалимедүр Мөхәммәд,
Нәбийү әүвәл вә хатәмдүр Мөхәммәд.

Сипаһ-салар мәйдани рисаләт,
Имаме әнбийа, садре җәлаләт.

Хак Хәбибе, рәхмәтән лил-ғаләмин,
Үзләре ирүр шәфиғел-мөзнибин.

Үзләренең паке рухына мөдам
Әйтәлем йөз мең доға вә әс-сәлам.

Кем қиамәт көне безгә биғәдәд
Хак рәсүл рухындин булғайму мәдәд?

Әй, Кәрим вә Зөлҗәлал вә, әй, Самиғ!
Мостафаны қыйлур безгә шәфиғ.

*1б кәгазь* Әбүбәкер ул йар ирүр раунақи,
Ғомәр ирде һәмишә дингә қати.

Ғосман тәқи хәлим-ү-хәйа ирде,
Шәҗағәт бабыда Ғәли арслан ирде.

Бере йар вә бере арыслан ирүр,
Бере җамиғ, бере ғилем эчрә ирүр.

Қачан кем рузи мәхшәр булғанында,
Хәлаиқ берлә ғаләм тулғанында

Җөда қыйлма алардин мән гидани.
Иляһи, чиһ Кәрим дигәр тудани.

**Дәр мәдхе падишаһи зәман вәли ма даимән әфзале әс-сәлятыйнез-зәмани ғәдл**

Олуғ солтан мөғаззам Сахибгәрәй хан,
Әсаләт берлә ул хан ибене хан.

Падишаһдур йир йөзендә намидар,
Дәүләт вә иқбаль-сәғадәт бәхтияр.

Тәкәллем эчрә ул сыйддиқы әкбәр,
Төгәл ғақыл эчрә ул хөршиде нур.

Кем шәжағәт бабында Ғәли – арслан,
Вә һәйбәтендин җәмиғ әғда ләрзән.

Қылыч зарбендин булур аждаһа мур,
Уқы пәйкәнедин Бәһрам күзе күр.

Ил-олусны ус берлә тотты үзи,
Мәшриқ-у-мәғрибдә йөрүр уш сүзи.

Уш мөсәххәр булды дөнйа үзенгә,
Падишаһлар бәндә булды сүзенгә.

Хақ қыйлғай дөнйа-ахирәтдә олуғ,
Башы оруб қыйлды уш барча табуғ.

Җәһде берлә бизәде бу барчани
Йите иқлимдә йөретте барыни.

*2а кәгазь* Падишаһи, рәхим игәсе һәм шәфиқ,
Мостафа шафиғ булуб, булғай рәфиқ.

Хөрмәт-ү-ғиззәт эчендә, әй, Ғәни,
Пөр қыйлғыл солтанәт берлә ани!

Хали бары бер доға қыйлалым уш,
Әйтеңез «амин» диб сыйддиқ берлә хуш!

*(Пәйғамбәр ғәләйһиссәламгә доға әйделәр)*

Барчамызны бар қыйлған Бариымыз,
Йалбарыб сәндин теләрмез барымыз.

Ничә кем туғса қойашдин зәррәләр,
Ничә кем йағса болытдин қәтрәләр,

Шаһи ғаләм ғөмрене пайандә қыйл,
Дошманыны табуғында бәндә қыйл.

Солтанәт тәхте үзә даим ани
Мөстәдам қыйлғыл, аңа, Қадир, Ғәни!

Әй, мәҗелес эчрә хазир хасс-у-ғам,
Барча «амин» дәйеб әйтеңез тәмам!

Иляһи, қыйл кем морад мөнтәһасын,
Қабул ит Мөхәммәдйарның доғасын.

Диде һатиф: «Әй, фәқир-ү-бинәва,
Мәйел булса нәзым аймақға сәңа,

Хақ рәсүле рухына син биғәдәд,
«Фатиха», «Ихлас» илә қыйлғыл мәдәд!»

Чөнки алдым илкемә дивүт-қәләм,
Тел тәқи ләшкәр қоруб, текде ғәләм.

Диде күңлем кем шуридәи әхваль:
Чықар башыңдин тәкәббер, қыйлма иһмаль.

Шаһи ғаләм, дөнйада ханлар ханы!
Дөнйада барча сездин тынсун җаны.

*2б кәгазь* Ғәдел берлә чықты, шаһа, атыңыз,
Дөнйада пайәндә булсун затыңыз!

Дадыңыздин қурқуб, әй, шаһи җиһан,
Көчлүк көчсезгә тигермәс һич зийан.

Бүре берлә қуй бергә су эчәр,
Үрдәк берлә қарчыға бергә очар.

Ул доға кем даим қыйлсун тәйү хуш,
Бу китабны битейү башладым уш.

Дәрвишанә хезмәт итеб уш үзем,
Мөфлисанә ғәрыз итеб хуш сүзем,

Бу күңүл гәнҗханәсенең дөррләрен
Уш қәләм бармақы берлә һәрберен

Бәргөзидә қыйлыб аны һәр заман;
Тигмә бер дөрр-данәсен йийғыб рәван,

Төрки теленчә мәғнә сүзләрен йасаб,
Шаһ атыға битедүм ошбу китаб.

Рәхмәт иткәй Хак аның әҗдадына,
Доғачы мән шаһның изгү затына.

Шаһи ғаләм йарлықаб сойурғаса,
Ул сойурғал берлә бәндә ырғаса,

Хәзрәтендин булмағай ирде ғәҗәб,
Кем ирер бу көн җәһанда лөтфы Рабб.

Имди әйтәйем китабым атыни,
Нәзм итәйем – тыңлаңыз әбйатыни.

«Нуры содур» аты, әй, шаһи җәһан!
Һәр кеше кем уқыса аны рәван,

Ханға қыйлғай даимән үкүш доға,
Мөстәҗаб иткәй доғасыны Хода.

Дәүләт эчрә ғөмреңез булсун озун,
Әсрү торыңыз җәһанда иллә озун!

*3а кәгазь* Шаһға аны қыйл мөбарәк, әй, Уған!
Дәүләтене қыйл зийадә, әй, Сөбхан!

Сәғадәт берлә күб йыл йөресүн,
Солтанәт эчрә җәһанда қарисун.

Чөн китабым атыны аңладыңыз,
Шаһ доғасы сүзләрен тыңладыңыз,

Үз атымны һәм [мән] қыйлайым бәйан –
Шаһ ғаләм табуғында булсун ғәйан.

Кем тәйү сорса атым ул шаһсәвар,
Атам – Мәхмүд, доғачы – Мөхәммәдйар.

Сәғадәт гәнҗедин күрсәткел ихсан,
Иллә, әй, падишаһи падишаһан!

Сүзүмне бу олуғ хан хезмәтендә
Кәрим қыйл, йахшы күрсәт хәзрәтендә.

Шаһы кем ғәдле дин Иран-Туран,
Табыбдур зиннәт, табмады ноқсан.

Вә ликин та җиһанда шаһ булғай,
Аның йаричысы Аллаһ булғай.

Рийазәтдин тән эчендә қалмады қан,
Төкәтсә, [ки] терек қалғайму инсан?!

Бәси ашөфтә хәйран булубмән,
Қолың тәк, бисәр-ү-саман булубмән.

Белүрсән барчаның халене шаһ,
Ғинайәт чақыдур, валлаһ, билләһ.

Тарих туқуз йөз қырық сәкезендә,
Мөбарәк мөхәррәм уникесендә,

Болғар шәһре Қазан дәрвазәсендә,
Кеше күбдер хирәд авазәсендә.

Мөхәммәдәмин хан қәбрендә, әй, йар,
Мөҗаувир ирүрмән бәсе булуб зар.

*3б кәгазь* Иляһи, бу китаб булғай мөбарәк,
Бәхаққ «Ғәммә», вә «Ихлас» вә «Тәбарәк».

***

Ничә баб ирер – ишетеңез аны,
Әйтәйен: ун баб ирер озун саны.

Бабе әүвәл – ғәдел сүзләре ирер,
Ғәдел иргә Хак үкүш дәүләт бирер.

Икенче баб – рәхим-ү-шәфкәт ирер,
Рәхиме қыйлғанға Хак дәүләт бирер.

Өчүнче баб ирер – бабе сәха,
Җәннәт ирер, аңла, бел, дарелбәқа.

Ирер түртенче баб, ишет, хәйа,
Кем хәйа әһле ирерләр әүлийа.

Һәм ғәза бабы ирер бишенче баб,
Хасил итәр ғазилар үкүш саваб.

Сабр бабы ирер алтынчы баб, ишет,
Барча эшдә сабыр қыйлғыл, әй, йегет!

Тәқи йитенче баб ирер, аңла, вафа
Кем, вафа қыйлған күрәр даим сафа.

Сыйдық бабы ирүр сәкезенче баб,
Һәркем сыйддиқ булса, табар күб саваб.

Туқузунчы самит бабы ирер уш,
Тел тотуб, самит ултурыр имди хуш.

Баб ғафу ирер унунчы, әй, һөмам,
Ғафу қыйлғыл хасс-у-ғамдин сән мөдам.

Уш китабым аты берлә бабларин
Шәрех қыйлдым, тыңлаңыз берин-берин.

Йахшы уқуб, мәғнәләрен белеңез,
Шаһи ғаләмғә доғалар қыйлыңыз!

## ӘҮВӘЛ БАБ.
## Ғәдел қыйлмақ сүзләрен бәйан қыйлур
## *«Иннә Аллаһә йәэмүрү бил-гәдли вәл-ихсани»*

*4а кәгазь* Ғәдлеңез берлә җәһан зиндә ирер,
Йите иқлим сезгә уш бәндә ирер.

Тулды барча ғәдлеңез берлә җәһан,
Рузи қыйлды ил-олусқа Хақ әман.

Ғәдел бабыны бу дәм бәйан итеб,
Шаһи ғаләм ғәдел сүзен йад итеб,

Әйтәйем ғәдел фазылыны рәван,
Тыңлаңыз аны, әйа, пир-ү-җәван.

Кем җәһанда барча тағәтдин зийад
Ғәдел ирүр – қыйл бу сүзгә иғтиқад.

Иртә-кичә һәркем ул қыйлса ани,
Әсиғ итәр үзенгә ул қыйлғани.

Үзгәләргә тигмәс андин һич өлүш,
Ничә кем қыйлса ғибадәт ул үкүш.

Ғәдел қыйлса падишаһ бер дәм, ишет,
Ил-олус ғәдле берлә табса мишет –

Барчаға тигәр өлүш андин тәмам,
Қыйлур аның белә рахәт хасс-у-ғам.

Ғәдел берлә ил қәмуғ булур әман,
Қалмаз илдә фетнә вә зольме ғөдван.

Ғәдлең белә тағәт итсә хасс-у-ғам,
Ул ғәдел ғәделедин тыныб тәмам.

Хақ Тәғалә ул ғибадәтдин өлүш
Рузи қыйлур ғәдел қыйлғанға үкүш.

Йәғни тағәт итмәгә булды сәбәб,
Ул сәбәбдин қыйлур аңа лөтфы Рабб.

Бәс, бу мәғнә берлә аңлағыл эшен,
Табса булур барча тағәтнең башын.

Ул сәғадәт мәғдәне, кяне сафа
Хақ Хәбибе, фәхре ғаләм Мостафа:

*4б кәгазь* «Бер сағәт ғәдел қыйлмақ йахшырақ,
Кем ғибадәт алтмыш йылдин озақрақ».

Ғәдел берлә дин-ү-дөнйа дәүләти,
Хасил ирүр ахирәтнең мөлкәти.

Ғәдел берлә бу җиһан мәғмүр ирүр,
Ғәдел берлә дөнйа уш пөр нур ирүр.

Тыңлаңыз, имди әмирел-мөэминин
Ул Ғәли сүзләренең хуш мәғнәсен:

«Ғәдел берлә ил ғимарәт булур уш,
Барча эшләр табар аның берлә хуш».

Ғәдел булды барча эш башын белең,
Ғәдел берлә даимән эш сез қыйлың.

Бер тәқи хикмәт сүзене әйтәйем,
Мәғнәсен төрки уш нәзым итәйем:

«Көфер берлә мәмләкәт булмас хәраб,
Золым берлә йықылур олус йөдәб.

Көфре кяфер нәфсенә қыйлур зийан,
Золым берлә булур ил хәле йаман».

## Әл-хикайәте ғәдел Нәүширван

Бер хикайәт қыйлайым уш аңар,
Равилардин бөйлә килмеш бу хәбәр.

Бер мәлик бар ирде, аңла, әй, җәван!
Аты ирде үзенең Нәүширван.

Кем җиһанда ғәдле уш мәшһүр ирер,
Мәдхе аның барча қыйлләрдә йөрер.

Үзенең йитмеш вәзире бар иде,
Һәрберенгә ғилем-әдәб йар иде.

Йитмешендин йитесене ихтыяр
Қыйлдылар үзләре. Ишет, намидар!

*5а кәгазь* «Мәшвәрәт қыйлыб бу көн эш итең,
Әндишә қыйлыб мәңа бер сүз әйтең!

Фикер итеб қыйлыңыз тәдбире рай,
Барча тынсын дөнйада йуқсуз-бай.

Мәңа соңра булсун нагяһ шадиман,
Мәмләкәт үзә булсун [қәмуғ] аман!»

Бу вәзирләр шаһ сүзен ишеттеләр,
Мәшвәрәт берлә қәмуғ эш иттеләр.

Әйделәр кем: «Шаһи ғаләм! Бу заман
Һәрберемез әйтәлем бер сүз рәван».

Шаһ мөнасиб күрде анлар сүзене,
Бу киңәштә мөхкәм итте үзене.

Бу йитенең бере әйде: «Шаһа! Уш,
Әйтәйем сезгә бу дәм бер пәнде хуш:

– Җәмғ итеңез барча дөнйа малыни,
Хуш белерсез бу җиһан әхвалени.

Дөнйа қалмас һич кешегә паидар,
Күб хәзинә йийғыңыз, әй, намидар.

Тотқайсыз мөлекне мал берлә хуш,
Бу ирер мәндин нәсихәт сезгә уш».

Шаһ ишетте бу вәзирнең сүзене,
Фикер берлә мәшғүл итте үзүне.

Ул йитенең бересе, ишет, йәнә,
Қыйлды шаһға күб доға берлә сәна.

Әйде: «Шаһа! Әйтәйем, тыңлаңыз!
Сүзем улдыр, лөтыф итеб аңлаңыз.

Кем көнендә чығарыб аны рәван,
Җәң қыйлғай ил-ү-олус, пир-ү-җәван».

Тигмә бере сүзләде барча сүзен,
Тезде ул сағәт берлә җәһер озын.

*5б кәгазь* Ул дәм эчрә шаһ бойурды аңа кем:
«Сән тәқи һәм бер сүз айғыл, әй, хәким!»

«Имди мәңа тигде нәүбәт, әйтәйем,
Бу вәзирләр сүзене шәрх итәйем.

Сүзем ул кем – ғәдел қыйлың илгә сез,
Кем аның хәййерен соңра белгәйсез.

Бу вәзирләр сезгә айған сүз қәмуғ,
Ғәдел эчендә хасил улмаз, әй, олуғ!

Әйтәйем – барчасыны хуш тыңлаңыз,
Фикер итеб, шаһи ғаләм, аңлаңыз.

Ғәдел берлә ил ғимарәт булур уш,
Ул ғимарәтдин килүр күб мале хуш».

Тотуб аның сүзене шаһи җәһан
Ғәдел қыйлу башлады Нәүширван.

Ғәдел берлә тотды дөнйаны қәмуғ,
Тынды ғәдле берлә кечек һәм олуғ.

Булды мәғмүр илләри барча рәван,
Һич хәраб йир қалмади, аңла җәван.

Килүр ирде ил-олусдин күб чикеш,
Мал-туар, алтун-көмүш һәр йаз-у-қыш.

Кяфер ирде. Ғәдл қыйлды ирсә үзи,
Сүзләнүр бу көн җәһанда уш сүзи.

## ИКЕНЧЕ БАБ.
### Рәхим-шәфкәт сүзләрене бәйан қыйлур

Рәхим-шәфкәт қыйлғучы Ғалимға хуш,
Лөтфыңыздин тотар өмид барча уш.

Йарлы илгә рәхм-ү-шәфкәт қыйлғайсыз,
Тәңредин анларға рәхмәт булғайсыз.

Кем асайыш қыйлғай ил-олус қәмуғ,
Рахәт эчрә тынғай ул кечек-олуғ.

*6а кәгазь* Тыңлаңыз сүземне барча уш тәмам,
Рәхим-ү-шәфкәт қыйлғайсыз [хуш] мөдам.

Рәхим-шәфкәт бәйанын йад итәйем,
Әһле иман күңлене шад итәйем.

Хақ Тәғалә күңүлгә қыйлса нәзар,
Ул күңүлдә белгүрер андин әсәр.

Тәңренең лөтфы берлә йомшак булур,
Ул тәкәббер кыйлмакдин алчак булур.

Чөнкем ул Хак лөтфы берлә йомшанур,
Тулар аның эче-ташы барча нур.

Хак Тәгалә дәмбәдәм кыйлур нәзар,
Ул күңүлгә белгүрер гәнҗе хәбәр.

Хасс-у-гамга рәхим кыйлур һәр заман,
Һич кешегә ул рәва күрмәз зийан.

Йарлылар хәлене күреб йарлыкар,
Рәхмәте берлә аны Хак йарлыкар.

Бер хәдис мәгнәсен әйтәйен сахих,
Җан-у-дил берлә ишеткел, уш сарих!

Рәхмәт иткәй күкдәгеләр сезгә хуш,
Даим артар дәүләтеңез имди уш.

Бу хәдисне ишетеб, фәхрел-өмәм,
Рәхим кыйлгыл барчаларга дәмбәдәм.

«Кемгә дәүләт-ү-сәгадәт йар ирер,
Тәңренең колларыга йари бирер».

Бари аңа йари кыйлур һәр заман,
Дөнйа ичрә күрмәз ул һәргиз йаман.

Баки кыйлур Тәңре аның дәүләтен,
Даим арттурыр Хак Тәгалә нигмәтен.

**Әл-хикайәт**

*6б кәгазь* Ул рәсүлуллаһ Мусаны, аңлаңыз,
Кыйлды ул бер көн мөнаҗат, тыңлаңыз.

Зари берлә қыйлды хәзрәтқә нийаз,
Ул нийазы берлә әйде Хаққа раз:

«Кем йаратқан пак-у-тәк вә, әй, Ғәни,
Ни сәбәбдин ихтийар иттең мәни?

Кем мәңа бирдең рисаләт хилғәтен,
Рузи қыйлдуң уш мөнаҗат дәүләтен.

Лөтыф берлә қыйл аны мәңа бәйан
Кем, моңа булсун мәғнә эчрә ғәйан».

Ул дәм эчрә қыйлды аңа Хақ ғитаб
Кем: «Әйа, Муса, ишеткел уш җаваб!

Кем безем пәйғамбәремез ул Шөғәйб,
Йулымызда садиқ ирде ул биғәйб.

Үзе чөнкем бирде сәңа қызыни,
Сән қабул қыйлдуң үзеңә сүзени.

Кем аның қуйларыны көтәр идең,
Вәғдәсене йиткүреб китәр идең.

Хезмәт итеб сән үзенгә ул заман,
Қуйларыны көтә башладың рәван.

Шәфқәт итеб қуйларын көтәр идең,
Таза утлар истәйү китәр идең.

Вақты берлә сөрәр ирдең һәрберен,
Барчасының арытур ирдең йирен.

Бу йусунлуқ көтәр иркәнсән ани,
Әсри имгәтте ушал бер қуй сәни.

Кем сачылыб чықты  қуйлардин рәван,
Қачты ирсә, қудың аны ул заман.

*7а кәгазь* Күб йөгүрдең, һич арыб ултурмадың,
Арғаныңны кешегә белдермәдең.

Ул қуй арды, ғақибәт, тоттың аны,
Рәхим қыйлыб ул дәм өреттең аны.

Әйдең аңа: – Әй, мөбарәк җануар!
Күб йөгердең сән қачыб, ардың мәгәр.

Үзүң арыб һәм мәне арғуздың уш,
Бер заман қыйлғыл асайыш имди хуш.

Тунуң эчрә чолғаб аны, күтүреб
Килдең ул дәм қуйларыңа тигүреб.

Рәхим қыйлдың ирсә, әй, Муса аңа,
Рәхмәт иттем мән тәқи ул дәм сәңа.

Ихтийар итеб сәне қыйлдым қабул,
Ля җәрәм, булдуң җәһанда хак рәсүл».

## ӨЧҮНЧЕ БАБ.
## Сәхавәт сүзләрене бәйан қыйлур

Әй, сәхавәт мәғдәненең җәүһәре,
Әй, сәғадәт тиңезенең гәүһәре!

Уш сәхавәт бабыны қыйлыб бәйан,
Көч йитәрчә қыйлайым барча ғәйан.

Тыңлаңыз имди сәхавәт сүзләрен,
Таки күргәйсез сәғадәт йөзләрен

Кем, «Сәхавәт берлә булур ир сәғид»,
Ул сәғадәт даимән булур мәзид.

«Қайу ир кем булса дөнйада сәхи,
Хаша булмас ахирәтдә дөзәхи».

Кем сәха ирер иргә олуғ һөнәр,
Ул һөнәр ирер кешегә таҗе сәр.

Әй, мәҗелес эчрә ултурған тәмам,
Ишетеңез ошбу сүзне хасс-у-ғам!

*7б кәгазь* «Җәһан эчендәге ғәйебләр қәмуғ
Бер кешедә булса барча», әй, олуғ,

«Барча ғәйебләрне сәхавәт йабар»,
Һәркем иксә, даим ғивазын табар.

«Хақ зийадат қыйлур аның малыни,
Ахирәтдә хуш қыйлур әхвалени».

**Әл-хикайәт**

Бер хикайәт қыйлайым уш, тыңлаңыз
Кем, сәхи васыфыны хуш аңлаңыз.

Ул борынғы рузегярда, әй, йегет,
Бер хәммаль бар ирде, [аны] хуш ишет.

Вақты ирде үзенең әсрү фәқир,
Һич нәмәрсәсе йуқ ирде, әй, әмир.

Қайаға барыб, килтүрер ирде утун,
Арқасы берлә күтүреб тигмә көн.

Сатар ирде ике дәнкегә ани,
Ул тәсаддық қыйлур ирде берени.

Йәнә бер дәнкесене үзе алыб,
Хәреҗ итәр ирде ивенгә барыб.

Бер көн утун сатыб үзе нагяһан
Барыр ирде йулда – күрде бер җәван.

Бер кеше аны тотуб қәтығ орыр,
Ул йегет мескин ойалыб тик торыр.

Хәммаль әйтүр аңа кем: «Бу ни торыр,
Ни сәбәбдин сәне бу кеше орыр?»

Ул йегет әйде кем: «Әйтәйем сәңа,
Ике дәнке бурычлуғ ирермән аңа».

Ишетеб хәммаль бу йегет сүзени,
Алды бурычлуғ қулундин үзени.

*8а кәгазь* Сатқан утун бәһасен бирде аңа,
Уғлы, қызы қалды ач – барча йәнә.

Иртәсе хәммаль мәгәр тағға барыб,
Утун алыб килтүрер иркән арыб;

Бер кешене күрде кем – балық сатар,
Һич кеше алмаз балықын, ғәйб итәр.

Мәсхәрә тотуб аны тигмә бери:
«Ул изылмыш балықың килтүр бәри», –

Тәйү аңа, көлүшүр ирде қәмуғ
Ул базар эчендәге кечек-олуғ.

Ул балықчы, изыды ирсә, рәван
Килде ул хәммаль қатынгә ул заман,

Әйде: «Әй, утунчы, тыңлағыл сүзүм,
Бу балық берлә қарарды бу күзүм.

Сатсам аны – һич кеше алғусы йуқ,
Имди мәндин алғыл аны уш сән уқ.

Балық алыб, биргел сән мәңа утун,
Эвгә барыб ашағыл аны бөтүн.

Сәндин үзгә һич кеше алмас ани,
Лөтф итеб, андин хәляс иткел мәни».

Қыйлды хәммаль аның сүзене қабул,
Утун биреб, балықыны алды ул.

Ул балықчы сәвүнүб барды рәван,
Имди ишеткел хикайәт, әй, җәван.

Килде хәммаль ивүнгә әсрү арыб,
Әйде кем ошбу балық қарнын йарыб:

«Қыйлайым уғланларым өчүн тәғам...»
(Күргел имди Тәңренең лөтфын тәмам!)

*8б кәгазь* Йарды ирсә ул балықның қарнини,
Бер данә чықты кем – булды ғәни.

Иллә дөрр данә, ләтыйф-у-шаһи дар,
Рәушан вә ширин шәффаф-у абидар.

Йөз мең алтун ирде аның қиммәте,
Йатмыш ирде – қубты хәммаль дәүләте.

Аз нәмәрсә берлә қыйлды ул сәха,
Хақ ғиваз бирде аңа үкүш ғәта.

## ТҮРТЕНЧЕ БАБ.
## Хәйа сүзләрене бәйан қыйлур

Әй, хәйа бағының ул таза гөле!
Хәзрәтең ирер сәғадәт мәнзиле.

Ишетеңез ул хәйа бабы сүзен –
«Ир хәйа берлә күрәр дәүләт йөзен».

Һәркем ул дәүләт теләр булса тәмам,
Ихтийар итсүн хәйаны ул мөдам.

Кем хәйа берлә сәғадәт йар ирер,
Ул сәғадәт хасиле – дидар ирер.

«Һәркем қурқса Тәңредин, ул ойалур»,
Дөнйасыны биреб, ул ғөқба алур.

Булур иман ул кешенең хасиле,
Җәннәт ирер ахирәтдә мәнзиле.

Ул ойалса Тәңредин, қыйлмаз йаман,
Һич кем ирсәгә тигүрмәз ул зийан.

Кем эчендә сақлар ул ойатыни,
Изгүлүк берлә чықарыр атыни.

«Қайу кем ирсә ойалса Тәңредин,
Ни бойурса – чықмас аның әмредин».

Барча йирдә Хақны ул хазир белүр,
Һич йаман эш қыйлмаз, үзе ойалур.

*9а кәгазь* Даимән күрәр үзене шәремсар,
Үзенгә-үзе һәмишә йул кисәр.

Хақ йулында күнилек берлә йөрер,
Күни мөэмин дөнйада үзе ирер.

Бу хәдис мәғнәсе ирер, хуш ишет
Кем, «Хәйа – имандин ирер». Әй, йегет!

«Кемгә кем қыйлса иманны Хақ ғәта,
Дөнйада рузи қыйлур аңа хәйа».

Ул хәйа берлә қыйлур изгү ғәмәл,
Ахирәт эшендин қыйлмас һич хәләл.

Чын мөселман ул булур, аңла йақин
Кем – хәйа берлә бизәнүр күңле чын.

Қайу кеше кем хәйасы булмаса,
Күңле берлә күни тәүбә қыйлмаса,

Ул кешедә ирер иман-ислам зәғиф,
Аңлағыл бу сүзне, әй, йареләтыйф!

Нәқел итәйүм бер хәдис, ишет рәван
Кем, хәдис раст ирер ул, бигөман.

Кем бойурды аны ул фәхрел-әнам,
Тәңре дусты Мостафа садрел-кәрам.

Мәғнәсене төрк теленчә, әй, йегет,
Шәрх итәйем, җан-у-дил берлә ишет.

«Булмас иман кемдә булмаса хәйа» –
Бу хәдис ирер кем, әйде Мостафа.

Бәс, хәйасыз кешенең иманы йуқ.
Бихәйалық – дәрд ирер, дәрманы йуқ.

Кем ойатсыз кешедин килүр йаман,
Һич ойалмас, тигүрер илгә зийан.

Һәркем – ул қурқса, ойалса Тәңредин,
Бер сағәт хали булмас ул әмредин.

*9б кәгазь* Гәр ту күңүл берлә ул тәүбә қыйлур,
Хақ қатында ул гөнаһларын йолур.

Һич кем ирсәне ойалтмас ул кеши,
Даимән лөтф-у-кәрәм булур эши.

## Әл-хикайәт

Бер хикайәт қыйлайым сезгә бәйан,
Кем җәһан эчендә сүзләнүр ғәйан.

Озаққы кичкән заманда, әй, йегет,
Бер ғәрәб бар ирде, әйтәйем, ишет.

Ул ғәрәбнең йирен-йортын аңлаңыз, –
Барчасы шүрестан ирде, тыңлаңыз.

Кем шүр ирде [барча] сулары аның,
Эчәр ирде шүр кечек-олуғларың.

Белмәс ирделәр сөчүк суны туға,
Суы шүр, сақынур ирделәр уға.

Бу йусунлуғ торыр иркән ул ғәрәб,
Нагяһан булды аңа бер эш ғәҗәб.

Йағмады анларға йағмур бер заман,
Утлары бөтмәде, қыйлдылар фиған.

Йазылары эчрә һич ут қалмады,
Үзләре эчкүгә су табулмады.

Күчтеләр ул йортдин анлар қәмуғ,
Тигмә йару барды кечек һәм олуғ.

Ғәрәб таза бер йазыға килде мәгәр,
Әйтәйем ул йазы васфындин хәбәр.

Күрклүк йазы ирде, таза утлары,
Утлар ирде һәр тарафда атлары,

*10а кәгазь* Төрлүк сәчәк берлә имди бизәнеб,
Хөррәм таза, йәш ғәләфдин төзәнеб,

Һәр тарафда бөтмеш ул җай пөр чәмән,
Күрсә кем – җәннәт ирер ул заман.

Таңлар ирде йөрер иркән ул ғәрәб,
Қыйлур ирде ул йазыда су таләб.

Йөрер иркән йазы эчрә, әй, олуғ,
Күрде бер күл: эче балчық су тулуғ.

Сусамыш ирде ғәрәб кем бигөман,
Эчте ул балчықлы судин нагяһан.

Ләззәт алды ул сөчүк судин ғәрәб,
Эчте ирсә нагяһан қыйлды ғәҗәб.

Әйде кем: «Булғай бу йир җәннәт мәгәр,
Кем ишетмеш ирдем андин мән хәбәр.

Хәузы Кәүсәр ошбу булғай, күрдем уш,
Кем ирер суы бу йаңлиғ татлы, хуш».

Татлы су эчкәне йуқ ирде ғәрәб,
Таңлаб аны қыйлды ул әсру ғәҗәб.

Бер сынуқ күзәсе бар ирде һаман,
Аны тултурды ушал судин рәван.

Бер кийезгә мөхкәм аны чолғады,
Йебләр ишеб, аны мөхкәм бағлады.

Әйде кем: «Килде мәңа дәүләт бу көн,
Әрмаған илтәйен аны шаһ өчүн.

Тигүрәйен мән хәлифәгә аны
Кем, эчеб Кәүсәр суын, тынсын җаны».

Тәүәсенгә йөкләде суны рәван,
Тәүәгә [һәм] менде үзе ул заман.

Кичә-көндүз ойумады йул йөреб,
Ашығыб тәүәсени қәтығ сөреб.

*10б кәгазь* Чықты ул бадийәдин мескин ғәрәб,
Җиһәт итеб қыйлды хәлифәни таләб.

Таки ул көн шаһ ауға атланыб,
Сайд қыйлу йөрер ирде имгәнеб.

Йөрер иркән, шаһны күрде нагяһан,
Кем йырақдин туз күренде ул заман.

Тәүәсен қәтығ сөреб йитте ғәрәб,
Тәүәсендин төшмәс иркән ул йөдәб,

Падишаһға қыйлды ул дәмдә сәлам,
Сәвүнүр иркән, сүзен әйде тәмам:

«Кем сәңа килдем, хәлифә, бу заман
Мона килтүрдем ғәҗаиб әрмаған.

Кеше андақ әрмаған күргәне йуқ,
Уш мона килтүрдүм аны сәңа уқ.

Хақ зийадә қыйлсун ғөмреңни, әй, шаһ!
Сәңа җәннәт суыны килтүрдем, аһ.

Эчкел аны, хәлифә, билләһи уш
Кем, йөрәгең таза булсун имди хуш!

Эчеб аның ләззәтене аңлағыл,
Мәңа инғам күб нимә бағышлағыл».

Ул сув хален күзә эчендә, ишет,
Эссе көнләр ирде, аңла, әй, йегет:

Сасы ирде йызығы, исе йаман –
Тулды шаһың нәзүк дәмағы ул заман.

Ойалуб ул суны алды иленә,
Нагяһан тигүрде аны теленә;

Күңле болғанды хәлифәнең рәван,
Серрене қыйлды қәмуғлардин ниһан.

Әйде: «Җәннәт суы ирмеш, аңладым,
Бу ғәрәб айған сүзене тыңладым.

*11а кәгазь* Биреңез мең алтун инғам үзенә,
Ғәйеб қыйлмаңыз аның сез сүзенә.

Вәли үзе мондин уқ қайтсун рәван,
Килмәсүн ул безем илә нагяһан».

Шаһ сүзе берлә қайтты теркенчә ул,
Тәүәсенә мүнүб ул дәм тотты йул.

Сордылар: «Ни сыв ирде, падишаһ,
Кем ғәрәбне қыйлдыңыз мондин бираһ».

Падишаһ вәзиренгә әйде җаваб,
Ул ойалыб булмасун тийеб хәраб:

«Бу Форат суын килүб кичсә иде,
Сусаб аның суыны эчсә иде;

Бәс, ойалғай ирде қыйлғаныдин, –
Йанғай ирде сүзенең йалғаныдин.

Биэр тәйеб килгән кем ирсә ойалыб,
Үзе қыйлған эшедин хәйран қалыб,

Барса ирде, ни рәва булғай иде,
Биргәнемез ни әсиғ қыйлғай иде».

Чөнки бикләр шаһ сүзен тыңладылар,
Ни кәрәм қыйлғаныны аңладылар.

Җан-у-дил берлә қыйлыб үкүш доға,
Падишаһға әйделәр йөз мең сәна.

## БИШЕНЧЕ БАБ.
### Ғәзат қыйлмақ сүзләрене бәйан қыйлур
***Қалә гәләйһиссәлам: «Рәҗәгна мин җиһадил-ахирәти»***

Әй, җәһан ғазиларының сәрвәре,
Сез ирерсез дин-ү-дөнйа миһтәре!

Қыйлайым сезгә ғаза бабын бәйан,
Ғазилық ирер сәғадәт, бигөман.

Ғазиларның васфы хален аңлаңыз,
Уш ғәзавәт сүзләрене тыңлаңыз.

*11б кәгазь* Кем ғәза қыйлмақ ирер олуғ һөнәр,
Ғазилар булур җәһанда мөғтәбәр.

Кем ғәзат берлә ачылур дин йули,
Дөнйада даим ғәза қыйл, әй, вәли.

«Кем ғәза қыйлса җәһан эчрә мөдам,
Мәнзиле булур аның дарес-сәлам».

Дөнйа вә ғөқбаны ул хасил итәр,
Үз морадынға һәмишә ул йитәр.

«Кем шәҗағәт қыйлса бер дәм дөнйада,
Ул күрәр олуғ сәғадәт ғөқбада».

Бу хәдис ирер, ишеткел, мөғтәбәр!
Кем «бәһатур кешене Тәңре сәвәр».

Ничә кем бер йылан үлтүрсә ул,
Табар ул кеше биһишткә күни йул.

Биш намазда күрсәңез йылан-чайан,
Айамадин үлтүрүңез ул заман.

Кем қыйлур хәлаиқға анлар җәфа,
Бу сәбәбдин аны әйде Мостафа:

«Һәркем ул қыйлса хәлаиқға зийан,
Мәғнә эчрә ирер ул ғәкрәб-чайан.

Кем зийанкяр кешене үлтүрсә, бел,
Йылан үлтүргән тик ирер, – аңлағыл».

Дингә дошман даимән кяфер булур,
Ғазилар кяфер берлә туқуш қыйлур.

Әнбийанең сәнғәте ирер ғәза,
Кемгә кем қыйлса аны Тәңре ғәта;

Дөнйада олуғ кәрамәт ирер ул,
Кем аның берлә табар җәннәткә йул.

Рәсүлуллаһ мөбарәк Мостафадин,
Кем фәхре садиқ ирер-ү-фәхре дин,

*12а кәгазь* Нәқел итәйем бер хәдис, мөғтәбәр,
Мәғнәсендин қыйлайым сезгә хәбәр.

Мәғнәсе бу ирер, аңла, әй, йегет,
Төрки теленчә әйтәйен, йахшы ишет.

Җан-у-дил берлә ишетеб, қыйл қабул,
Кем мөбарәк ләфзыдин әйде рәсүл:

«Хақ Тәғалә қыйлды минем ризқым уш,
Бу сөнгүм күләткәсе астында хуш».

Йәғни, кем ризқымны қыйлды ул Уған,
Бу ғәза малындин аңла, әй, җәван.

Кем ғәза малы ирер әсрү хәлаль,
Алса кяфер малыны булмас вәбаль.

Кем ғәза ирер рәсүлнең сәнғәте,
Артар аның берлә ислам дәүләте.

Һәркем эшләсә рәсүл эшен мөдам,
Дин вә дөнйа эшләре булур тәмам.

**Әл-хикайәт**

Бер хикайәт нәкл итәйем мөғтәбәр,
Кем Хәсән Басридин ирер бу хәбәр.

Үзләре әйде ки, күрдем бер йегет,
Ғазилардин ирде үзе, хуш ишет.

Ул хикайәт қыйлды мәңа, тыңлаңыз,
Ғазилар әхвалене хуш аңлаңыз.

«Кем тиңездә йөрер ирдек бер заман
Ғазилық қыйлыб җәһанда, нагяһан

Йилләр исеб, қайнады бер көн тиңез,
Ғәрек булды тиңез эчрә кәмәмез.

Бер ағач өстүндә мәне йил алыб,
Бер җәзирә эчрә чықарды салыб.

*12б кәгазь* Ул җәзирә утлары зәғфран иде,
Күрклүкендә җәннәт-ү-ризван иде.

Ул җәзирә уртасында бер сарай,
Кем йыракдин нуры балқыр қыш вә йай.

Тамлары: бер кирпеч – алтун, бер көмүш,
Дөрр-ү-җәүһәр ул сарай эчрә үкүш.

Кердем ирсә ул сарайға мән рәван,
Күрдем анда кем, йатур бер қач җәван.

Сач, сақаллары таранмыш, таза уш,
Тунлары пакизә һәм үзләре хуш.

Ул сарай анлар белә пөр нур иде,
Үзләре анда йатыб ойур иде.

Күреб анлар халене қуркдым, әй, йар.
Ташқару чықдым – күрәрмән бер сәвар:

Ул ирер хөсне җәмальдә бинәзыйр,
Йызығы ирер аның мөшк-ү-ғәнбир.

Мәне күреб әйде кем: «Сүзлә сүзүң!
Кимәсе сынған кеше ирер үзүң.

Йул сорарсән, бөйлә уқ барғыл рәван,
Бер йегет күргәйсән анда нагяһан.

Сән йулуңны сорғыл ул дәм үзедин,
Ни бойурса, чықма аның сүзедин».

Йөредем, бардым, йулуқтум үзенгә,
Чөн нәзар қылдым мөбарәк йөзенгә,

Қыйлур ирде ул йегет анда намаз,
Ул намазын төкәтеб, қыйлды нийаз.

Мәне күреб ул дәм әйде, хуш ишет:
«Кем ирерсән кимәсе сынған йегет.

Йул сорарсән, йөрегел бөйлә рәван,
Сәңа бер пир отру килгәй бу заман.

*13а кәгазь* Сән сәлам қыйлыб аңа, сорғыл хәбәр,
Кем үзе ирер җәһанда раһибәр».

Йөредем, илгәрү күрдем үзене,
Кем намазын итеб, сөртәр йөзене.

Барыб илгәрү аңа қыйлдым сәлам,
Сурәт-ү-мәғнәдә ирде ул тәмам.

Мәңа әйде: «Кимәсе сынған кеше!
Тотмағыл күңлүндә йулның тәшвише.

Йул сорарсән, әйтәйем, орғыл қәдәм,
Раст йөрүгел бөйлә уқ имди бу дәм».

Бу йегет әйде кем: «Әй, пире ләтыйф!
Барча мәғнә эчрә ирерсән шәриф.

Теләкем улдыр – мәңа қыйлсаң бәйан,
Монча төрлүк күргәнем эшне ғәйан.

Күб ғәҗаиб төрлүк эшләр күрдем уш,
Мәңа андин қыйл хәбәр, әй, пире хуш».

Пир әйде: «Әйтәйем барчасын сәңа,
Бу дәм эчрә хуш қолақ тотғыл мәңа:

Ул сарай кем күрдең аны ул заман,
Ул шәһидләр қәсры ирер, әй, җәван.

Анда йатқан кешеләр ирүр шәһид,
Мең йыл ирер йатқаны анлар, ишет.

Күргәнең атлығ кешедүр – Җәбраил,
Көн дә ике қурла килүр, аңлағыйл.

Ул йегет ки күрдең – ул Илйас ирер,
Кем үзе даим зийарәтқа килүр.

Мәне сорсаң, Хозр ирермән, әй, йегет,
Уш сәңа қыйлдым хикайәт, хуш ишет.

Бер доға үгрәтәйем, йегет, сәңа,
Аны уқуб кер бу сағәт йулыңа.

Йомуб ачқунча күзеңне сән рәван,
Теләгән йиреңә йиткел бу заман».

*13б кәгазь* Ул доғаны мән уқудум ирсә уш,
Күз йомуб ачғунча килдем ивгә хуш».

## АЛТЫНЧЫ БАБ.
## Сабыр қыйлмақ сүзләрен бәйан қыйлур
## *«Йа, әййуһа әл-ләзинә әмәну, әсбиру вә сабиру вә рабиту вә әттәқу Аллаһә ләғалләкүм түфлихүнә»*

Уш күңүл ләүхедин уқуб бу сабақ, –
Сүзләре берлә бизәйем уш вәрәқ.

Җан-у-дил берлә ишетеңез қәмуғ,
Шәрх итәйем аны, әй, кечек-олуғ.

Сабыр бабын қыйлайым сезгә бәйан,
Сабыр итеңез барча эшдә һәр заман.

Сабыр қыйлмақ иргә ирер хуш һөнәр,
Сабыр қыйлған кешене Тәңре үгәр.

Тәңренең рәхмәтләре даим, ишет,
Сабыр қыйлғаннарға булур, әй, йегет.

Барча тағәт башы, аңла, сабыр ирер,
Сабыр қыйлған иргә Хақ дәүләт бирер.

Дустлуқ эчрә сабыр қыйлсаң, әй, ғәзиз,
Қәтрә иркән – булур ул дустлуқ тәңиз.

Дошман үзрә сабыр қыйлсаң йәнә үкүш,
Ғақибәт, аны йиңәрсән, аңла хуш.

Сабыр берлә барча эш хасил булур,
Сабыр қыйлған даимән ғақил булур.

Җабир атлығ бер сәхабә, әй, йегет,
Сабыр иде Хақ йулунда, хуш ишет.

Үзләре қыйлды ривайәт, тыңлаңыз,
Мостафаның хәзрәтендин аңлаңыз:

«Сабыр берлә хасил итәр ир морад,
Сабыр берлә қайғу булур барча шад».

Ул нәбийү Аллаһи Йағқуб, хәзин,
Азрылыб күрмәде чөн Йосыф йөзен,

*14а кәгазь* Дәрде фирқәт эчрә даим руз-у-шәб,
Сабыр қыйлыб қыйлды Йосыфны taләб.

Ғақибәт табты аны ғиззәт белә,
Йөзене күрде аның дәүләт белә.

Сабыр қыйлды ирсә Йағқуб – бер заман
Булды Йосыф восле берлә шадиман.

Бер кем ирсә Мостафаны күрде ул,
Бәс, имандин үзләренә сорды ул

Кем: «Ни булур иман, айғыл, әй, рәсүл?!
Ишетеб, аны қылайым уш қабул».

Мостафа бойурды аңа ул заман
Кем, айайын – тыңла имди, әй, җәван:

«Сабыр қыйлмақ ирер иман», бел йәқин,
Хақ йулында сабыр қыйл, әй, әһле дин.

Қайу кеше сабыр қыйлса ул мөдам,
Ул кешенең булур иманы тәмам.

Сабыр қыйлмақ ирер әүвәле ачиғ,
Һич нимә йуқ дөнйада андин қатиғ.

Соңы балдин сөчүк ирер, әй, җәван,
Сабыр берлә көчай эш булур асан.

Сабыр қыйлған кешеләрне хасс-у-ғам –
Барча ғаләм халқы сәвәрләр тәмам.

Барча эшдә сабыр қыйлғыл, әй, ғәзиз,
Сабыр сүзен аңла, әй,  ғақлы тәмиз.

**Әл-хикайәт**

Нәзым итәйем бер хикайәт имди уш,
Ишетеңез мәҗлес әһле барча хуш.

Кем Хорасан мөлке эчрә бер мәлик
Бар ирде, тыңла, әй, гәнҗ билик.

*14б кәгазь* Аты ирде Бусәғид, аңла аны,
Хикәм берлә тотмыш ирде дөнйаны.

Бер вәзире бар иде аның мәгәр,
Ғилм-ү-хикмәт эчрә ирде мөғтәбәр.

Аты ирде Бүл-Мөзаффәр үзенең,
Кем мотиғы ирде ғалим сүзенең.

Падишаһ бер көн мәгәр үзе белә
Мәшғүл ирде мәшвәрәт сүзе белә.

Итүге эчендә аның бер чайан
Тиггәр ирде ул вәзирне бер заман.

Нәчә тиггәр ирде ғәкрәб үзене,
Кисмәс ирде шаһ берлә сүзене.

Сүзләйү торған сүзен йаңылмады,
Хале аның һич тәғәйир булмады.

Шаһ берлә сүзләде сүзләрени хуш,
Сабыр қыйлыб зәхмене гизләди хуш.

Шаһ қатындин тарқады бикләр қәмуғ,
Ивгә барды барчасы – кечек, олуғ.

Ул вәзир һәм барды ивгә ул заман,
Ашықыб чықарды итүген рәван.

Чөн чықарды итүген ивгә барыб,
Салды ғәқрәбне итүкдин чықарыб.

Падишаһға тигде ул дәм бу хәбәр,
Таңлады үзе вәзир эшен мәгәр.

Өндәб әйде аңа кем: «Сән, әй, вәзир!
Ғақыл эчендә ирдең сән би-нәзыйр.

Сәне ғәқрәб ул заман тиггәндә уқ,
Ни сәбәбдин чықмадың сән анда уқ?

Дәфеғ қыйлмадың сән аның шәррени,
Нуш қыйлдың анда торыб зәһәрени?»

*15а кәгазь* Ул вәзир әйде кем: «Әй, шаһи җәһан!
Хәзрәтеңездә қыйлайым уш бәйан.

Сез мәңа монча үкүш ихсан қыйлыб,
Үзеңүзгә мине сез мәхрәм белеб,

Мәшвәрәткә мине лайық күрдеңүз,
Серреңез сүзен мәңа белдердеңез.

Мәңа сез сүз әйтүр иркән ул заман,
Тигте ирсә мәне ғәқрәб нагяһан,

Әйтә торған сүзеңез тыңламайын,
Ул бойурған эшеңез аңламайын,

Чықсам ирде ташқару, шаһи җәһан,
Булғай ирде әсиғым барча зийан.

Ул  ғәқерәб тиггәнегә түзмәдин,
Сезгә мән сабрым барын күргүзмәдин,

Бер тиггән зәхменгә ул дәм бақыб,
Китсәм ирде хәзрәтеңездин чықыб,

Бәс, сезнең дошманларыңыз хәрбенгә,
Йағиларыңыз қылычы зарбенгә

Мән ничүк түзгәй идем? Шаһи җәһан,
Қол сезнең мән – сез белүрсез әл-әман!»

Ул вәзир сүзене солтан тыңлады,
Ғақиланә сүзләгәнен аңлады.

Шаһға хуш килде аның бу сүзләри,
Қыйлды инғам вәзиренгә үзләри.

Чөн аның ғақиллығыны белди ул,
Мәмләкәтне аңа тәслим қыйлди ул.

Қайу кеше сабырлық булса үзе,
Ғақибәт табар морад бәс ул үзе.

## ЙИТЕНЧЕ БАБ.
### Вафа қыйлмақ сүзләрен бәйан қыйлур
### *Қалә ән-нәби ғәләйһиссәлам: «Әл-вафа фә-ма...»*

*15б кәгазь* Әй, вафа иқлименең шаһы йәқин!
Кем вафаңыз нурыдин руйи зәмин

Кичә-көндүз даимән рәушан ирер,
Йаз-у-қыш ғаләм қәмуғ гөлшан ирер.

Уш вафа бабыны тәхрир итәйем,
Сүзләрене сезгә тәқрир әйтәйем.

Бу вафа ирер, ишет, нуре җәһан!
Кем аның берлә йарыр бу җисм-ү-җан.

Бел – вафа ирер җәһан эчрә һөнәр
Кем, вафа берлә булур ир мөғтәбәр.

Мөғтәбәр булмақ теләсә һәр кеши,
Даимән булсун вафа қыйлмақ эши.

Қайу ир кем сәнғәте булса вафа,
Ул сәбәб берлә күрәр үкүш сафа.

Бу вафа, аңла кем, өч төрлүк ирер,
Кем вафа қыйлса – сәламәт, хуш йөрер.

Әй, борадәр, бере ирер ғәһд эши,
Ғәһед қыйлса Хақ йулында һәр кеши,

«Важиб ирер қыйлмақ ул ғәһде вафа,
Қыйлмаса, күрәр қийамәтдә җәфа».

Бәс, икенчесен айайын, тыңла уш,
Вәғдә қыйлса кешегә бер нимә хуш,

Ул кеше күңлен сафа қыйлмақ кәрәк,
Вәғдәсенгә хуш вафа қыйлмақ кәрәк.

«Вәғдәгә қыйлған вафа – булур кәрим»,
Бу – хәдис мәғнәсе ирер, әй, хәким.

Бәс, өченчесен айайын, тыңлаңыз,
Мәғнәсене шәрх айайым, аңлаңыз.

Падишаһ-у-бик, вәзир берлә қәмуғ,
Бер кем ирсә шарт қыйлса, әй, олуғ:

*16а кәгазь* «Кем мине асрасаңыз сез хуш күреб,
Мин тәқи үлгүнчә табуғда торыб,

Көчүм йитәрчә сезгә хезмәт қыйлғаймән,
Сезгә даим мән һәвадар булғаймән».

Бу йусунлуғ вәғдәгә қыйлса вафа,
Хезмәтендин китмәсә күреб җәфа,

Ул кеше булур вафадар, әй, йегет,
Уш вафа әһле сүзен йахшы ишет.

Әйтәйем әсхабе кәһфнең қиссасын,
Кем китәрер ул күңүлнең ғоссасын.

Бер көчүк қыйлды чөн анларға вафа,
Дөнйа вә ғөқбада табты ул сафа.

Чөнкем анларға ийәрде бер заман,
Айағы ақсады йулда нагяһан.

Ничә кем қыйнар ирделәр – қайтмады,
Күб йөрүде ақсаб, арыб йатмады.

Қыйлды ирсә ул вафаны ихтийар,
Ля җәрәм, булды вәлиләр берлә йар.

Бәс, вафа берлә сафа хасил булур,
Ул сафа берлә сәғадәт табылур.

Ул сафа соффәсенең шаһы тәмам,
Ул вафа қөббәсенең маһы мөдам,

Дин-ү-дөнйа, йир-күкнең мөфәххәри,
Инс-ү-җан вә җеннәрнең пәйғамбәри!

Нәқл итәйем бер хәдис үзендин уш,
Төрк теленчә мәғнәсене аңла хуш.

Кем кәрим ул ирер, аңла, әй, җәван,
Вәғдәсенгә ул вафа қыйлса рәван.

«Вәғдәгә қыйлмақ вафа – ирер кәрәм»,
Бәс, вафа қыйл вәғдәгә һәр дәмбәдәм.

## Әл-хикайәт

*16б кәгазь* Ишетеңез бер хикайәт имди уш,
Бер мәхәллә бар ирде Бәғдадда хуш.

Ул мәхәллә әһле ирде барча бай,
Күрмәз ирде анда кеше һич гидай.

Һәр ки мөфлис булса ирде нагяһан,
Малларындин бирер ирделәр рәван.

Қәйра хуҗа қыйлур ирделәр ани,
Булур ирди ул борунғы тик ғәни.

Ул мәхәллә эчрә бер хуҗа мәгәр
Булды мөфлис нагяһан, ишет хәбәр.

Аты ирде Хамид Қоттан, әй, йегет,
Булды ирсә мөфлис үзе (хуш ишет):

Ул мәхәллә қәүме йийғылыб қәмуғ,
Барды Шәмғун ивүнгә кечек-олуғ.

Шәмғун атлығ бер йәһүди ул заман,
Малы күб ирде. Ишеткел, әй, җәван.

Йийғылыб қәмуғ эвенгә килделәр,
Хамид Қоттан өчүн сүзләр диләр.

Әйделәр кем: «Тәңрелық өчүн, – аңа, –
Бурычқа биргел биш мең ақча. Без сәңа

Аның өчүн барчамыз йөк булалым,
Вәғдәсе йитсә, әда без қыйлалым».

Шәмғун анлардин ойалыб ул заман,
«Бирәйем» – тиб, вәғдә қыйлды нагяһан.

Күңле эчрә Шәмғун әйде кем «бу көн
Вәғдә қыйлдым, бирәйем Тәңре өчүн».

Ул кичә йатты, ойуды. Нагяһан
Йоқлайурда төшүндә фәхре җәһан

*17а кәгазь* Әйде: «Аның хаҗәтен қыйлдың рәва,
Без тәқи уш дәрдеңә қыйлдық дәва».

Сорды Шәмғун кем: «Әйа, нуры җәһан,
Атыңызны әйтеңез мәңа рәван!

Сезгә бер дәм инче бәндә булалым,
Ни бойурсаңыз – мән аны қыйлалым.

Йөзүңез нурын күреб тынды жаным,
Сездин уқ ирер, белүрмән, дәрманым».

Әйде кем: «Сорсаң мәне, Шәмғун, бу дәм
Сыйдық берлә дин йулына қуй қәдәм.

Хақ рәсүле мән, Мөхәммәд – атым уш,
Ғәрз итәйем сәңа иман имди хуш.

«Әшһәде әл лә иләһә» тиб рәван,
Айғыл: «илләл-Лаһ» сүзене, әй, җәван».

Шәмғун әйде: «Хақ рәсүле Мостафа!
Күңлүм эчрә тулды уш сездин сафа.

Тәңрене берсене белдем, хақ рәсүл,
Қыйлдым ислам динене бу дәм қабул».

Җан-у-дил берлә булуб ул мөселман,
Дөнйа-у-ғөқбаны табты хуш аман.

Дөнйа биреб, ахирәтне алды ул –
Даимән дәүләт эчендә қалды ул.

## СӘКЕЗЕНЧЕ БАБ.
### Сыйдық сүзләрене бәйан қыйлур
***Қалә Аллаһу Тәғалә: «Вә мусаддиқән лима бәйнә йәдәйһи»***

Әй, җәһан  ғашиқларының садиқы,
Әй, заман садиқларының ғашиқы!

Ғишық берлә сыйдық сүзен тыңлаңыз,
Тәқрир итәйен аны – хуш аңлаңыз.

Сыйдық бабын қыйлайым сезгә бәйан,
Ул бәйан берлә аны күрең ғәйан.

*17б кәгазь* Төрк теленчә сыйдық мәғнәсен белең –
«Күнилек берлә һәмишә эш қыйлың».

Сыйдық, йәғни күни сүзләмәк булур,
Күни сүзләгән кеше дәүләт булур.

Қайу кеше теләсә дәүләт тәмам,
Күни булсун сүзләре аның мөдам.

Күнүлүк берлә табар дәүләт қәмуғ,
Күнү сүз берлә булур кечек олуғ.

Кем олуғлуғ теләсә даим үзи,
Барча берлә хуш, күни булсун сүзи.

Күниләрни барча ил-олус сәвәр,
«Күни сүзләгән кешене Хақ үгәр».

Адәм уғлының вөҗүде эчрә бел:
Бер тылсым бу, әл-ғәҗәб ирер бу тел.

Кем җәһан эчендә, әй, дин олуғы,
Гәнҗ-ү-дәүләт, рәнҗ-ү-михнәт – қәмуғы

Ул тылсым ачқучы берлә ачылур.
«Нә ки телдин чықты – ул башқа килүр».

Тел күни булса, күнүлүр ил-азақ,
Күни булур барчасы – бу күз-қолақ.

Игри булса тел – қәмуғы игелүр,
Ул сәбәбдин абе руйы түгелүр.

Бер хәдиснең мәғнәсене қәйра уш,
Тәрҗемә қыйлайым имди, тыңла хуш.

Ул – нәбүвәт мәғдәненең җәүһәре,
Ул – рисаләт тиңезенең гәүһәре,

Сахибе миғраҗ-у садрел-әнбийа,
Фәхре ғаләм, Хақ рәсүле Мостафа

Ул мөбарәк ләфзыдин имди үзе,
Ишетеңез бу ирер айған сүзе. –

*18а кәгазь* Нәзым берлә әйтәйем сезгә ани,
Ғәйеб қыйлмаңыз бу сүздә сез мәни.

Адәм уғлы уйғаныб торса рәван,
Һәр сабах йатған йирендин нагяһан,

Телгә әйтүр бу қәмуғ әндамләри,
Халь теле берлә ишеткел һәрбери:

Кем ирерсән безгә, әй, тел, сән олуғ,
Сән төзәтсәң, без төзәнүрмез қәмуғ.

Игри булсаң сән төзәлмәдин, әй, тел,
Барчамыз игри булурмыз, – аны бел.

Бәс, «Ни килсә башға, бел – телдин килүр,
Адәмиға ни ки қыйлса, тел қыйлур».

Кеше йалған сүз белә табмаз нәҗат,
Туғры сүз берлә табар даим хәйат.

**Әл-хикайәт**

Бер хикайәт тыңла имди, әй, олуғ!
Сүзләрене нәзым қыйлайым қәмуғ.

Бер заман эчендә бар ирде мәгәр
Бер солтан, ишетеңез – будыр хәбәр:

Уғлы хален қыйлды анларға бәйан,
Фикер қыйлды бик, вәзирләр ул заман.

Әйделәр кем: «Таңла ауға чықалым,
Шайәд ауда сүзләгәй ул – бақалым».

Таң берлә атланды ауға хасс-у-ғам,
Йөрер ирде аулайу барча тәмам.

Шаһизадә лаласы берлә мәгәр
Йөрер ирде хәлвәт, ишет бу хәбәр:

Очар ирде нагяһан берничә қаз,
Хуш һава йөзендә қыйлдылар аваз.

*18б кәгазь* Лала салды қарчағасын ул заман,
Қазны тотты қарчығасы, әй, җәван.

Шаһизадә әйде ул сағәт, ишет,
Бу хәдис мәғнәсене аңла, йегет:

«Һәр кем тотты телене – қотулды ул,
Телене тотмаған уш тотулды ул».

Чөн ишетте ирсә лаласы рәван:
«Шаһ! Сәвүнче!» – тәйү барды ул заман.

Шаһ сәвүнүб, бирде хилғәтләр аңа,
Әйде кем: «Шаһзадәне килтүр мәңа!»

Килде ирсә шаһизадә үзенгә –
Мөнтәзыйр ирде шаһ анның сүзенгә.

Ничә кем шаһ лөтф итеб сорды үзен,
Шаһизадә сүзләмәде һич сүзен.

Шаһ қыйлды [ки] лаланы ул дәм таләб,
Хишем берлә қыйлды аңа ул ғазаб:

«Кем мәңа йалған хәбәр килтүрдең уш,
Булдың имди мөстәхәқ үлмәгә хуш».

«Үлтүреңез, – тиб бойурды шаһ, – ани!»
Шаһизадә қәйрә әйде сүзени:

«Һәр ки тотты телене – қотулды ул,
Телене тотмаған уш тотулды ул».

Ишетеб уғлы сүзен шаһ булды шад,
Ул мескин лаланы қыйлды азад.

Шаһ әйде лөтыф берлә уғылына
Кем: «Бу көн серреңне айғыл сән мәңа.

Ни сәбәбдин сүзләмәдең, әй, уғул,
Мәне қыйлдың ошбулай зар-у-мәлүл?

Тәңре хақы өчүн, айғыл сән мәңа,
Аймаз ирсәң, хатерем қалур сәңа».

*19а кәгазь* Шаһизадә әйде: «Әй, шаһи җәһан!
Бер хәдис үгрәндем ирде ул заман.

Мәңа остадым битеб бирде ани,
Ошбу ирде – әйтәйем мәгнәсени:

«Һәр кем тотты телене – қотулды ул,
Телене тотмаған уш тотулды ул».

Күңлүм эчрә әйдем, әй, шаһи җәһан,
Бу хәдисне сынайын мән бер ғәйан.

Раст булса, мәгнәсени сынайын,
Мән хәқиқәт белеб ани, тынайын.

Ул сәбәбдин сүзләмәдем бер заман,
Ғафу қыйлғыл мәндин, әйа, шаһ җәһан!

Шәрх итәйем сезгә ғаләм солтаны –
Раст ирер, сынадым ирсә мән аны:

Тотса ирде телене сахрада қаз,
Тотмаз ирде ул дәм эчрә аны баз.

Тотса ирде лала ул дәм телени,
Үлмәгәмү бойурыр ирдеңез ани?!

Күни ирүр бу хәдис, сынадым уш,
Төрки теленчә ирүр мәғнәсе хуш:

Һәр ки тотты телене, қотулды ул,
Телене тотмаған уш тотулды ул».

## ТУҚУЗЫНЧЫ БАБ.
### Самит қыйлмақ сүзләрен бәйан қыйлур
### *«Мән сәкәтә сәлимә вә мән сәмәтә нәжқа»*

Сал қолақ самитлық эчрә нәүҗәван,
Һәр ки самитдыр – ирер ул пәһлеван.

Күб ирер бу самитлық файдасы,
Тыңла имди, күбдер эшнең файдасы.

Әйде, самит булуң тиб ул Мостафа:
«Мән сәкәтә сәлимә вә мән сәмәтә нәжқа».

«Һәр ки сакитдыр – сәламәт булғай ул,
Самит улған һәм нәжатқа табғай йул».

*19б кәгазь* Һәр ки салимдыр – йарыйур даим йөзи,
Мөхкәм-ү-мөстәхкәм булур аның сүзи.

Кем бу самит сүзедин, шаһи җәһан,
Қыйлайым имди сүзгә тел дәрмийан.

### Әл-хикайәт

Бар ирде Каннухда бер пире никхаһ,
Килүрдин вақиф-у кичмешдин агяһ.

Үзе назүк иде вә күңле кәрим,
Ил эчрә ирде [ул] ғалим һәм хәким.

Ултурыб мөнбәр үзә даим үзи,
Тәңре әмре иде сүзләгән сүзи.

Бер көн үзе вәғз эчендә нагяһан
Кем телендә йөреде бу сүз рәван:

«Һәр ки самит булса һәр эшдә үзи,
Кергәй ул дарес-сәлам эчрә үзи».

Тыңла имди бу хикайәтне тәмам,
Аңла имди бу сүземне ник-ү-нам.

Бар ирде бер мәҗлес эчрә бер җәван,
Ошбу вәғзне күңле тотты нагяһан.

Кем ул ил эчрә булур ирде үзи, –
Мәшһүр ирде самитлық эчрә сүзи.

Бер йәһүди қуңшылыкда бар иде,
Үзе бәдбәхт-ү иман инкяр иде.

Ултурыр ирде бер көн самит җәван,
Килде, азар итде ул бәдбәхт, йаман.

Ошбу самит пәһлеван назир иде,
Ул йәһүдә қәтленә қадир иде.

Самит итеб, өнәмәде һич[бер] сүз,
Күңленә ағыр алыб, чатмады йөз.

*20а кәгазь* Йоқлайурда ул кичә самит җәван,
Керде төшенә аның шаһи җәһан.

Әйде аңа: «Ишет сән, әй, нәүҗәван
Кем ирдең самитлық эчрә пәһлеван!

Кем хәбәр қыйлды мәңа ул Җәбраил,
Йарлықадым тәйү сәне ул Җәлил».

Йәнә әйде, ишет, ул фәхре җәһан:
«Сәкез оҗмах кем сәңа булды мәкян!»

Кем бу сүзедин шад булдым үземә,
Кем күренмәс улды шаһ күземә.

Уйғаныб, вөзу итеб вақтға бақар,
Нагяһан берәгү уш ишүк қақар.

Торды, бақты, күрде: ул – җәһүд ирер,
Әйде: «Самит, мәңа иман үгрәт, – тәйер.

– Кем мөселман булғам имди бу заман,
Табғаймән аның илә утдин әман.

Динеңез хақлықыны күрде күзем,
Ошбу диннең хақлықына йуқ сүзем.

Йатыб уш йоқлайурда [мән], нагяһан
Кем күрүнде күзүмә анда җәһан:

Олуғ, кечек – барча килмешләр қәмуғ,
Кем йәнәшә тезелмеш йите тәмуғ.

Тотубән мәне анда килтүрделәр:
– Самитны азар иткән бу, – тиделәр.

Фәрман қыйлды (ишет сән, маһе лиқа):
– Атың аны, – тиделәр, – тәмуғ утыға.

Қурқуғумдин сискәнүбән тордым уш,
Ул сағәт Хаққа иман килтүрдем уш».

Барча малын Хақ йулында қыйлды сарф,
Мондин артуқ тимәде һичбер хәреф.

*20б кәгазь*

## УНУНЧЫ БАБ.
### Ғафу қыйлмақ сүзләрен бәйан қыйлур
***[Қалә Аллаһу] Тәғалә: «Иннә Аллаһә [кянә] ғафуән ғафурән»***

Ғафу бостанының, әй, таза гөли!
Қаршуңызда сайраб уш тел былбыли,

Ғафу бабын имди хуш рушан итәр,
Сүзләре күңүлләрне гөлшан итәр.

Ғафу қыйлмақ ирер ирнең ирдәме,
Ирдәмендә мең дәм ирер бер дәме.

Ғафу қыйлмақ Тәңре бойурықы ирер,
Бойрықын тотғанға ул җәннәт бирер.

Хақ Тәғалә бойрықыны тот рәван,
Хасс-у-ғамдин ғафу қыйлғыл, әй, җәван.

Кем йаманлық қыйлса сезгә дәмбәдәм,
Сез аңа ихсан белә қыйлың кәрәм.

Ғафу қыйлмақ берлә булур ир ғәзиз,
Ғафу қыйл барчадин, әй, ғақлы тәмиз.

Ғафу тимәк ни тимәк булур – ишет,
Мәғнәсене әйтәйем, аңла, йегет.

Кем кичүрмәк ирер ул бер бәндәдин,
Азған-у-йазған бәси шәрмәндәдин.

Хақ әййүр рәхмәт қыйлыб анларға уш:
«Рузи қыйлдық җәннәт-фирдәүсне хуш».

Хури ризван теләгән кеше мөдам
Ғафу қыйлсун барчалардин ул тәмам.

Нагяһан йазыб йаңылса бер кеши,
Кичүреб андин кәрәм булсун эши.

## Әл-хикайәт

Бер хикайәт нәзм итәйем, аңлаңыз,
Җан-у-дил берлә сүзене тыңлаңыз.

*21а кәгазь* Кем озағғы рузегяр эчрә мәгәр,
Бер мәлик бар ирде әсрү мөғтәбәр.

Кем аты Мәсғүд иде үзенең,
Шаһы ирде үзе ул йир йөзенең.

Үзләре ғасры эчендә, әй, йегет,
Һәм йәнә бер шаһ бар ирде, хуш ишет.

Ибне Әшғәт ирде ул шаһ аты, бел!
Уш хикайәт қыйлсун аны сезгә тел.

Бу икәгү дошман ирделәр тәмам,
Алдар ирде бере берене мөдам.

Табмас ирде бере беренгә зафәр,
Тыңла имди, әйтәйем уш мән хәбәр.

Ғақибәт, Мәсғуд йийғды ләшкәрен,
Ил-олусда қуймады орыш ирен.

Қәсдән озун икәгү торуштылар,
Ике ләшкәр күб қәтығ орыштылар.

Тәңере тәқдире берлә нагяһан –
Ибне Әшғәт ләшкәре сынды рәван.

Хақ Тәғалә бирде чөн Мәсғудға йул,
Ибне Әшғәт ләшкәрене қырды ул.

Алдылар әсри күб улҗа, әй, әмир,
Ул чәрикдин қыйлдылар үкүш әсир.

Ғизз-у-носрәт берлә ивгә килде шаһ,
Ул әсирләрнең қәмуғын йиғды шаһ.

Үзе алтун сандәлида ултурыб,
Сорар ирде барча, бер-бер килтүреб.

Бер йегеткә төште нагяһан күзи,
Аны ул дәм килтүреб сорды үзи.

Ул йегет әйде кем: «Әй, шаһи җәһан!
Бер сүзем бар – әйтәйем, биргел аман».

*21б кәгазь* Шаһ әйде кем: «Аман бирдем [хуш] сәңа,
Ни сүзең бар ирсә, айғыл уш мәңа».

Ул йегет әйде кем: «Әй, шаһи кәрәм!
Сүзем әйтәйем, ишеткел ошбу дәм.

Сән теләгән эшне бирде Хак сәңа,
Хак теләгән эшне қыйлғыл сән аңа.

Носрәт ирде теләгең – табтың ани,
Ғафу ирер синдин Изи теләгәни.

Хак Тәғалә сәңа дәүләт бирде уш,
Дошманыңны қәһр қыйлды барча хуш.

Сән тәқи Хақлық өчүн, шаһи җәһан,
Ғафу итеб бездин кичүргел бу заман.

Сән безем йаманымызға бақмағыл,
Қәһер уты берлә безне йақмағыл.

Лөтыф қыйлды уш сәңа Пәрвәрдигяр,
Қәһер қыйлма безгә син, әй, намидар.

Ғафу итеб, қыйл күңлүмезне имди шад,
Лөтыф қыйлыб, барчамызны қыйл азад.

Кем Кәримдин даимән килүр кәрәм,
Бәс, кәрәм қыйл безгә, шаһа, сән бу дәм».

Шаһ ул дәмдә аңлады йегет сүзен,
Күрклү сүз әйтүр тәйү, үгде үзен.

Қыйлды айған сүзләрен ул дәм қабул,
Ул йегетнең қыйлмады күңлүн мәлүл.

Ул йегет сүзене ул дәм ишетеб,
Ул әсирләрне исергәб, рәхим итеб,

Хақ разыйсы өчүн ул шаһи җәһан
Барчасыны азад қыйлды ул заман.

Ул йегетне йарлыға6 сойурғады,
Ғомре барынча тыныб хуш ырғады.

***

Бу китаб хан доғасы берлә тәмам,
Қыйлғаныны бәйан қыйлур кем мөдам.

*22а кәгазь* Әй, җәһан солтанларының солтаны,
Йите иқлимдә қәму ханлар ханы!

Дөнйаны тултурдыңыз әмн-ү-аман,
Булды рахәт эчрә барча җисм-ү-җан.

Булдыңыз бу көн әманға сез сәбәб,
Кем ирерсез дөнйа эчрә зыйлли Рабб.

Сайәңезгә сығыну килгән кеше,
Ғәдлеңез берлә бетәр барча эше.

Сезгә йари қыйлды ирсә Бариыңыз,
Уш сағәдәт булды даим йарыңыз.

Ни уйун кем уйнадылар – оттуңуз,
Ғақибәт, дөнйаны барча тоттуңуз.

Мәшриқ-у-мәғриб сезнең булды тәмам,
Падишаһлар булды уш сезгә ғолям.

Уш мөсәлләм булды сезгә бу җәһан,
Хуш мөсәххәр булды барча өнс-ү-җан.

Хөкмеңез дөнйаны барча тотты уш,
Ғәдлеңез тулды җәһанда имди хуш.

Күрсә ирде ғәдлеңезни Нәүширван,
Булғай ирде бәндәңез, шаһи җәһан.

Хатим Тай вөҗүдеңез йөзен күреб,
Хиҗләт эчрә қалғай ирде ултурыб.

Ул қәтығ йадин уқ атсаңыз йасаб,
Бәндә булғай Рөстәм-ү-Афрүәсйаб.

Уш җәһандағы мөбаризлар қәмуғ
Қолуңыз булуб, қыйлур сезгә тәбуғ.

Тәңренең лөтфы ирер шаһ үзеңез
Кем ирер дөнйагә басруқ сүзеңез.

Хөкмеңез берлә төзәнде ил-олус,
Сүзүңүз берлә туланды ғақл-у-ус.

*22б кәгазь* Дәүләт вә фәтх-ү-зафәр берлә мөдам,
Солтанәт тәхте үзә йөз йыл тәмам

Ғизз-у-дәүләт берлә, шаһа, йәшәңез!
Қайда булса дошманыңыз, – түшәңез.

Сезгә кем қыйлса доғалар дәмбәдәм,
Лөтыф белә қыйлыңыз аңа кәрәм.

Ғәрш Изисе, йа, Иляһел-ғаләмин,
Бу доғаны мөстәҗаб иткел, әмин.

Бер сүзем бар – аны тәхрир итәйем,
Мәқсудымны сезгә тәқрир итәйем.

Шаһи ғаләмнең мөбарәк атына
Күб доға булсун тиб арығ затына,

Төрки нәзм итеб битедүм бу китаб,
«Нуры содур» анын атыны атаб.

Хәтем қыйлдым сүзләрене имди уш,
Хақ мөбарәк қыйлсун аны шаһға хуш.

Нәчә кем булса жәһанда – ай-у-йыл,
Нәчә кем сүзләнсә телдә қаль-у-қыйль,

Һәркем аны уқыса һәр дәмбәдәм,
Йә қайчан кем битесә аны қәләм,

Падишаһға даимән қыйлғай доға,
Жан-у-дил берлә үкүш айғай сәна.

Әй, доғаларны ишеткән пак-ү-тәк!
Хәзрәтеңдә уш қыйлыб йөзем бүхәк,

Зари берлә мин доға қыйлайым уш,
Лөтыф берлә қыйл иҗабәт аны хуш.

Бу заман ғазиларының солтаны,
Дөнйа эчрә барча ханларның ханы –

Шаһи ғаләм ғөмрене қыйлғыл үкүш,
Йите иқлимне аңа биргел өлүш.

*23а кәгазь* Дәүләтене қыйл жәһанда мөстәдам,
Ғиззәтене қыйл зийадә собх-у-шам.

Носрәт-ү-фәтх вә зафәр берлә ани
Қыйл сәғадәт эчрә даим, әй, Ғәни.

Бу китабны қыйл мөбарәк сән аңа,
Йарлықаб қыйлғай ғинайәт уш маңа.

Әй, караңғу төнне айдын қыйлғучы,
Әй, йазықлар дәфтәрени йуйғучы!

Ғафир-у-Ғаффар ирүрсән, әй, Ғафур,
Мәғфирәт җамыны мәңа син эчүр.

Ғафу қыйл йазықларымны, әй, Ғафу,
Йаратғаным, тағәтемне қыйл рафу.

Сәңа лаиқ қыйлмадым һәргиз ғәмәл,
Эшләрем қәмуғ дәға вә һәм дәғәл.

Дөнйада қыйлдым үкүш фисқ-у-фәсад,
Рәхмәтеңгә қыйлдым, әй, Хақ, иғтимад.

Ғәрқ ирүрмән мәгсийәт эчрә мөдам,
Булды ғисйан берлә уш ғөмрем тәмам.

Тәүбә қыйлдым, барча йазықдин кичеб.
Сән иҗабәт қыйлғыл имди, йа, Мөҗиб!

Ғафу қыйлыб, сән йазықларым кичүр,
Лөтыф берлә қәһреӊ утыны үчүр.

Кем ғазабдин рәхмәтеӊ сабиқ ирер,
Йарлықамақ сәңа уқ лаиқ ирер.

Сәне бер тиб белдем имди, әй, Ғәни,
Лөтыф қыйлыб, йарлықа бу көн мәни.

Йарлықар булсаӊ минем тик, сад һәзар
Рәхмәтеӊнеӊ тиӊезендин ни қорар?!

Рәхмәтеӊ дәрйасы ирер бигиран,
Йарлықанур қәтрәсендин өнс-ү-җан.

Күб ғәмәл қыйлмақ берлә һәрбер кеши
Җәһед қыйлса дөнйада йаз-у-қыши,

*23б кәгазь* Булмагынча Тәңренең лөтфы аңа –
Кермәгәй җәннәткә, қолақ тот моңа.

**Әл-хикайәт**

Бер хикайәт қыйлайым, аңла бу дәм,
Садиқанә хуш ишет, фәхрел-өмәм!

Җабир Әнсари әйтүр, әй, җәван:
– Әйде мәңа Хақ рәсүле ул заман

Кем – қатымдин хали чықты Җәбраил,
Ул хикайәт мәңа қыйлды – аңлағыйл.

Кем бәни Исераил эчрә мәгәр,
Бер заһид бар ирде хуш мөғтәбәр.

Хақ йулында күк оруғдин киселеб,
Ғөзләт итте бер җәзирәдә килеб.

Ул җәзирә тиңез эчрә ирде, бел,
Бөтмеш ирде анда бер тағ, аңлағыл.

Чықар ирде ул тағыдин бер болақ,
Ақар ирде суы балдин татлығрақ.

Ул болақ өстендә бөтмеш бер тирәк,
Сайәсе бағы Ирәмдин йахшырақ.

Нар ағачы ирде ул тирәк, ишет,
Көн дә бер нар бирер ирде, әй, йегет.

Заһид ул йирне күреб, қыйлды мәқам,
Тағәт итде анда даим собх-у-шам.

Һәр сабах ул чәшмәгә килүр иде,
Абдәст алыб, ул намаз қыйлур иде.

Ул нар берлә уручыны ачыб,
Һәр кичә ул чәшмә суындин эчеб,

Иртә-кичә қыйлыб ул Хаққа нийаз,
Таңға тигрү қыйлур ирде күб намаз.

*24а кәгазь* Көндүз уруҗ тотуб ул заһид мөдам,
Кичә тағәт берлә биш йөз йыл тәмам,

Ғөмре ахыр булды ирсә, нагяһан,
Лөтыф қыйлды Хақ аңа, ишет, җәван.

Сәҗдә эчрә җаныны тәслим итеб,
Ахирәтға барды дөнйадин китеб.

Чөн қийамәт көне булғанда рәван
Хәшер булса бу хәлаиқ бигөман,

Хақ Тәғалә қыйлғай заһидкә хитаб:
«Рәхмәтем берлә сәне мин йарлықаб,

Бирәйем сәңа биһишти җавидан,
Кем тәмуғдин табқул имди хуш аман».

Заһид айғай: «Әй, Кәрим-ү-бинийаз,
Монча йыллар қыйлғаным рузә-намаз

Кайда барды? Мәңа белдүргел ани,
Йарлықарсән рәхмәтең берлә мини».

Хақ Тәғалә айғай: «Әй, заһид, фөзуль,
Рәхмәтемне қыйлмадыңму сән қабул?!

Мән хисаб итәйем уш сәнең белә,
Йахшы аңла барчасын, фикрәт қыйла.

Йуқдин бән бар әйләдем, заһид, сәни,
Кем сәнең аслың бер қәтрә мордар мәни.

Хур суыдин сәне мән қыйлдым ғәзиз,
Сәңа бирдем сиххәт вә ғақлы тәмиз.

Баш, айақ һәм күз, қолақ бирдем сәңа,
Сән намазың миннәт итәрсән мәңа.

Йите әғзаң төз йараттым мән қәмуғ,
Кем аның берлә мәңа қыйлдың тәбуғ.

*24б кәгазь* Ул ғибадәт қыйлмаға тәүфиқ йәнә
Рузи қыйлдым, әй, фөзуль заһид, сәңа».

Тәңренең бу һәйбәтендин ул заман,
Заһид мескин сусағай ул нагяһан.

Бер фәрештә, сахибе хөсн-ү-җәмаль,
Бер қәдәхне тултурыб абе зөлял,

Заһид алындин рәван кичкәй килеб.
Айғай ул заһид аңа зари қыйлыб:

«Кем сусалықдин йөдәдем әсрү уш,
Мәңа биргел, эчийәм ул суны хуш».

Ул фәрештә айғай: «Әй, заһид! Мәңа
Тағәтең биргел, бирәйем су сәңа».

Заһид айғай: «Йөз йыллық тағәтем
Бирәйем кем, йуқтур үзгә тақәтем».

Ул фәрештә қыйлмағай аны қабул,
Йадағай заһид булуб ул дәм мәлүл.

Ғақибәт, заһид сусалықдин йөдәб,
Барча қыйлған тағәтен аңа атаб,

Киткәй үзе дөнйадин тилмүреб,
Тағәтен бер эчем суға тигшүреб.

Ул қәдәхне алыб эчкәй ул заман,
Тағәтендин бинәва қалғай һаман.

Қыйлғай ул дәм хәзрәте ғиззәт хитаб
Кем: «Әйа, заһид, мәңа айғыл җәваб:

Биш йөз йыл тағәт иткәнең қәмуғ
Бер эчем суға сатыб, қалдың қорығ.

Барыб имди тәмуғға кергел рәван!»
Зари қыйлыб, заһид айғай ул заман:

«Барчаны йуқдин йаратқан пак-ү-тәк!
Белдем үземне, мине қыйлма һәлак.

*25а кәгазь* Китте ғөмрем эчрә қыйлған тағәтем,
Тәмуғ эчрә йанмаға йуқ тақәтем.

Кем йараттың мине син әсрү зәғиф,
Лөтыф қыйлғыл мәңа бу көн, әй, Ләтыйф!

Рәхмәтең берлә мине син йарлыќа,
Рузи қыйл лөтфың белә мәңа лиқа.

Лөтыф берлә қыйлмасаң мәңа нәзар,
Булды эшләрем қәмуғ зир-ү-зөбәр».

Хақ Тәғалә айғай: «Әй, заһид! Бу дәм
Рәхмәтем берлә сәңа қыйлдым кәрәм.

Барғыл уш җәннәткә имди бигөман,
Рузи қыйлдым сәңа хуш хури җинан.

Қыйл тәнәғғем анда күб ниғмәт белә,
Йарлықадым сәне мән рәхмәт белә».

***

Йа, Иляһел-ғаләмин, имди бу дәм
Тәүбә қыйлыб, барчамыз қыйлдық нәдәм.

Хәзрәтеңдин теләнү килдек қәмуғ,
Рәхмәтеңдин безне қайтарма қоруғ.

Кем ирермез тағәтеңдин бинәва,
Лөтыф берлә безгә қыйл рәхмәт ғәта.

Рәхмәтең берлә булур эшләр тәмам,
Рәхмәт иткел барчамызға, вәс-сәлам.

***

Әй, қәмуғ ханлар эчерә намидар,
Кем ирүрсез дөнйа эчрә кямикяр!

Қәһр берлә дошманыңыз сынды уш,
Лөтыф берлә дустларыңыз тынды уш.

Рахәт эчрә ил-олус булды қәмуғ,
Имди тынды дөнйада кечек-олуғ.

*25б кәгазь* Уш сезнең булды җәһан, әй, падишаһ,
Сезгә булды шәрқ-ү-ғәрб – барча сипаһ.

Мәшриқ-у-мәғриб қәмуғы имди уш,
Зәвеқ табты барчалары имди хуш.

Хуш мөшәррәф булды уш руйи зәмин,
Булғай сезгә сәғадәт-ү-һәмнешин.

Күб йәшәңез дәүләт эчендә мөдам,
Ғөмреңез булсун җәһанда мөстәдам.

Күңлүңез теләкләрен бирсүн Иляһ,
Иртә-кичә сезгә Хақ булсун пәнаһ.

Үтенәйем сезгә уш, шаһи җәһан –
Дәүләт эчендә йәшәңез күб заман!

Атыңызға нәзым қыйлғаным китаб
Хәтем қыйлдым, аны мән төрки йасаб.

Тигмә бер бәйте ирер бер пәнде хуш,
Сүзләре вәғаз-нәсыйхәт ирер уш.

Уқыған ғақил кешеләр аңлағай,
Бу зәғиф бичара қолны таңлағай.

Тигмә йирдин җәмиғ қыйлыб сүзләрен,
Мона күргүздүм мәғани йөзләрен.

Тәрҗемә қыйлыб парсы телен, ишет,
Нәзым қыйлдым төрки теленчә, йегет.

Йил тәк исеб кичсә ошбу рузегяр,
Дөнйада қалғай бу сүзләр йадегяр.

Кем уқур булса аны пир-ү-җәван,
Теләгем улдур үзендин ул заман:

Ханға қыйлғай даимән үкүш доға,
Мәғнә аңлаб, табса ул сүздин сафа.

Хан доғасы йөрегәй телләр үзә,
Важиб ирер дөнйада илләр уза.

Кем һәмишә ханға қыйлғайлар доға,
Төн-ү-көн айғай қәмуғлары сәна.

*26а кәгазь* Ничә кем булса җәһанда бу китаб,
Ханға булғай даимән үкүш сәваб.

Нагяһан бер қол доғасын ул Кәрим
Мөстәҗаб иткәй, гөмансыз, ул Хәким.

Ул доға берлә булуб эшләр тәмам,
Дәүләт эчрә күб йәшәгай шаһ мөдам!

Имди уш васфе халем [һәм] әйтәйем,
Бер теләгем бар, аны йад итәйем:

Чөн сынадым ирсә дөнйа эшени,
Белдем аның фетнә-ү-тәшвишени:

Бивафа ирмеш бу дөнйа – аңладым.
Әсри күб ирмеш җәфасы – таңладым.

Аны таңлаб ултурырда нагяһан
Хатеремға төште фикрәт ул заман.

Кем мөбарәк Урдуға барсам үзем,
Ханның қотлуғ йөзене күрсә күзем,

Ул дәм эчрә күб доға қыйлғай идем,
Йарлылықым сүзене айғай идем.

Қыйлғай ирде йарлықаб мәңа нәзар,
Қәйра булғай ирде эшем мөғтәбәр.

Йиткәй ирде теләгем барча рәван,
Кем ғинайәт қыйлса ул шаһи җәһан.

Ни қыйлайым кем, көчүм йуқдур, дәриғ,
Кем ирер мөфлислек иргә бәс қәтиғ.

Ханға лаиқ һич нә ирсәм йуқ бүләк,
Урдуға бармаға һәм қуүәт кәрәк.

Чөн бу фикрәт эчрә қалдым бер заман,
Хақ Тәғалә лөтыф қыйлды нагяһан.

Қыйлды мәңа бу күңүл шәйхе хитаб,
Кем аның сүзе берлә төздем китаб.

*26б кәгазь* Халь теле берлә мәңа айған сүзе
Бу ирер [кем] – мәңа әйде ул үзе:

«Кем, әйа, дәрвише мискин, дәрденак,
Ғосса берлә қыйлма үзеңне һәлак.

Тасниф иткел төрки теленчә китаб,
Падишаһ атыға аны хуш йасаб.

Кем Сөләйман йаңлиғ ирер хәзрәти,
Мөстәдам булсун җәһанда дәүләти.

Һич нимәгә ихтийаҗы йуқ торур,
Хезмәтендә барчасы анук торур.

Дөнйа бер пулча күренмәз күзенә,
Сән қымурсқа йаңлиғ имди үзенә.

Ул китабың үтүнүб изғыл рәван,
Рәхим қыйлғай кем сәңа шаһи җәһан.

Рәхиме берлә эшең булғай тәмам,
Рахәт иткәйсән һәмишә, вәс-сәлам».

Чөн күңүл шәйхе сүзене тыңладым,
Ни ишарәт қыйлды ирсә – аңладым.

Қәзғудин булды хәляс ул дәм күңүл,
Ғашиқанә сүзене қыйлдым қабул.

Алдым илкемгә қәләмни ул заман,
Телгә ни кем килсә күңүлдин рәван

Битейү башладым ул сағәт қәмуғ.
Ғишық берлә тыңла, әй, кечек-олуғ!

Бер хикайәт қыйлайым сезгә бу дәм,
Нәқеш итәр кағәз үзә аны қәләм.

## Әл-хикайәт

Бер хикайәт қыйлайым, ғаләм ханы!
Йалған ирмәз, күни – тыңлаңыз аны.

*27а кәгазь*

Равилар аны ривайәт қыйлур уш,
Сыйдық берлә ишетеңез барча хуш.

Дауд уғлы ул Сөләйман – хақ рәсүл,
Бикләрене йиғды бер көн барча ул.

Өндәде ул көн вәзирләрен мәгәр,
Туй булур диб, қыйлды барчаға хәбәр.

Тигмә бер бикләр-вәзирләр килделәр,
Ул заманда бер олуғ туй қыйлдылар.

Ил-олус килде қәмуғы йийғылыб,
Тигмә бере бер ләтыйф тигеш алыб.

Төрлүк таңсуқ күб тигеш килтүрделәр,
Тигмәсе үз қәдерен белдерделәр.

Бик, вәзирләр ултурырда ул заман –
Ул олуғлар арасында нагяһан

Килде бер турғай йырақ йирдин талыб,
Бер сарнычқа ботын ағзынға алыб.

Әйде кем: «Булсун мөбарәк ошбу туй!
Хасил итү белмәдем һич йылқы, қуй.

Әй, Сөләйман, ошбу ирер табқаным,
Җәһед берлә туйға хасил қыйлғаным.

Дөнйада ирер қәнағәт тәк эшем,
Халемә күрә ирер уш тигешем».

Ул нәбиуллаһ Сөләйман, әй, йегет,
Чөнки турғай сүзен аңлады, ишет.

Ғөзрени лөтыф белә қыйлды қабул,
Булмады турғай сүзендин һич мәлүл.

Ул дәм уқ турғайны ул сойурғады,
Йарлы турғай ивгә барыб ырғады.

***

Мән тәқи имди, әйа, шаһи җәһан,
Булдым ул турғай мәңизлек бу заман.

*27б кәгазь* Хәзрәтеңә йарлылықым белдүрүб,
Уш мона табған тигешем килтүрүб,

(Хәзрәтеңез ул Сөләйман тәк ирер,
Дөнйаның таңсуқлары сездә торыр).

Уш көчүм йитәрчә [бу] төрки китаб
Нәзым қыйлдым падишаһ атын атаб.

Лөтфыңыздин қыйлсаңыз аны қабул,
Хәстә күңлүм булмағай ирде мәлүл.

Қыйлғай ирдем җан барынча мән доға,
Айғай ирдем җан-у-дил берлә сәна.

Әй, Кәрим вә пак-ү-тәк вә Кәрдигяр,
Хәзрәтеңдә йалбарур Мөхәммәдйар.

Тәңре фазлы берлә булды бу тәмам.
Белеңез имди моны сез, хасс-у-ғам:

Туқуз йөз қырқ сәкездә тарих торар,
Китабым хәйр илә булды мөхәррәр.

Ишет, әй, мөғтәбәр ханлар ханы,
Сикез йөз иллек биш бәйт ирер саны.

Иляһи, бу китаб булғай мөбарәк
Бәхаққ «Ғәммә» вә «Ихлас» вә «Тәбарәк».

Тәвәккәлна ғаләл-Лаһи әманән,
Тәвәҗҗәһна иләл-Хаққи зәманән.

Ушал көн кем сәвад иттем бу тәқрир,
Хийалым нәқеш бағлап ошбу тәхрир.

Күңүл гәнҗедә анча бар иде гәнҗ –
Ки йыллар қыйлғай ирдем сарыфы рәнҗ.

Нә мәғнәға моңы, нә сүзгә фикре,
Нә мәғнәдин, нә сүздин үзгә фикре.

Булуб мәғрүр үз гәнҗинәсенә –
Нә мохтаж үзгәләр мөнтәбиһсенә.

*28а кәгазь* Вәли чөн хөкем иде шаһ җәһандин,
Ки қыйлғай тәрҗемә ул тәрҗемандин.

Төрки рәсме берлә битәкәллеф
Зарурәт мончалық қыйлдым тәсаррыф.

Тәвәққығ улдур әрбабы һөнәрдин,
Ки чөн фәйзъ алсалар бу мохтәсардин,

Сағынғайлар мөхиб-ү-бинәвани, –
Доға берлә сәвендергәйләр ани.

Йәнә дәр-хастем бар йахшылардин, –
Мәғқүл сүзене белгән йахшылардин

Кем, әлфазымны тәғйир итмәгәйләр,
Тәсаррыф берлә сәрасәр итмәгәйләр.

Уқығанға, битегәнгә, Иляһи,
Мөбарәк қыйл бу гәнҗе падишаһи.

Рамазан айының унбереси
Ки булды бу китабның интиһаси.

Фәқире кем җәфа берлә битеде,
Доға әһле дилләрдән өмиде.

Тәмам булды «Нуры содур» китабы,
Нәдер фәқир йазғучының гөнаһы.

# ИСКӘРМӘЛӘР

## «Нуры содур» әсәренең бүлек атамалары

«Нуры содур» әсәренең төп өлеше ун баб-бүлектән һәм бүлекләр эчендәге ун хикәяттән тора. Бүлекләрдән тыш, әсәр ахырында тагын ике хикәят урын алган. Бүлек исемнәре моңа хәтле өйрәнелгән кулъязма күчермәләре нигезендә төп ун «баб» һәм алар эчендәге «хикәят» бүлекчәләре итеп күрсәтелә иде. Хикәятләрнең кайберләре аерым күчермәләрдәгечә «фәсыл» дип белдерелде. 1966 елгы басмада барлыгы 16 бүлек һәм бүлекчә булып, шулардан берсе «Фәсыл» дип аталган. Ә 1997 елда чыккан китап 22 бүлек-бүлекчәдән тора, аларның өчесе «Фәсыл» дип теркәлгән.

Әсәрнең хәзерге вакытка билгеле булган төрле күләмдәге күчермәләрен чагыштырып караганда, ун баб-бүлек һәм аларның һәрберсендә берәр хикәят бар. Болардан тыш, әсәрнең керешендә һәм бетем өлешендә дә төрле зурлыктагы, берничәсе аерым исемләнгән, ә кайберләре атамасыз өлеш-бүлекчәләре бар. Андыйларны кушып исәпләгәндә, «Нуры содур» 31 бүлек-өлештән тора.

Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» текстының бу басмасы өчен нигез итеп алынган Югары Курса кулъязма күчермәсенең бер хикмәтле ягы шунда ки, анда баблар һәм бүлекчә исемнәре язылмаган. Ләкин алар өчен текстта буш урыннар калдырылган. Мондый күренешнең сәбәбе ике төрле булырга мөмкин. Беренчесе – бүлек исемнәре төп текстан аерым бер төстәге (кызыл яисә башка) язу карасы белән теркәлгән булып, язу карасының төсе бөтенләй уңып беткән[1]. (Әсәрнең бүтән күчермәләрендә баб-бүлек исемнәре күбесенчә кызыл төс белән язылган һәм андый үзенчәлек авторның төп текстыннан ук килгән дип әйтергә мөмкин). Әмма Югары Курса күчермәсендә бүлек язулары теркәлгән булып, алар уңган һәм

[1] Гарәп хәрефле татар палеографиясенә андый үзенчәлек хас булган (Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 27–28).

бөтенләй җуелган дип әйтерлек дәлил юк. Кулъязманы күчерүче, чынлыкта да, бүлек исемнәрен кызыл яисә башка төстәге язу карасы белән теркәгән булса, һичьюгы берничә хәрефнең тонык күләгә хәлендәге элементлары шәйләнер иде. Яисә, моңа охшаш кулъязма текстлардагыча, күчерүче ялгышып яки ашыгычлыктан бүлек исемнәрен дә төп текст өчен кулланылган көрән төстәге зәгъфран белән яза башлап тукталган очраклары булмыйча калмас иде. Әмма андый урыннары да юк. Димәк, әлеге күчермәдә бүлек атамалары булмавының сәбәбе бүтән.

Гомумән, татар кулъязмаларының сирәк хасиятләреннән берсен – бүлек исемнәре язылмаган очракларның икенче сәбәбен – «Нуры содур»ның Югары Курса нөсхәсендә дә күрәбез. Ягъни, әсәрнең төп текстын гадәти төстәге язу карасы белән күчереп язган вакытта бүлек һәм бүлекчә исемнәрен теркәү өчен буш урыннар калдырылган. Алар кулъязма күчерүнең икенче этабында аерым (кызыл яки бүтән) төстәге язу карасы белән өстәп теркәлергә тиешле булган. Тик менә бу күчермә очрагында бүлек исемнәре язылмаган. Аның исә, үз вакытына күрә, җитди сәбәбе булган дип фаразларга гына кала[2].

Югары Курса күчермәсендә баб һәм бүлек исемнәре язылырга тиешле булып, махсус калдырылган барлыгы 26 буш урын (аларның кайсы кәгазьләрдә икәнлеге кулъязманың тасвирламасына багышланган мәкаләдә төгәл күрсәтелде). Әлеге 26 урыннан тыш, берсе – «Әүвәл баб» атамасы өчен урын калдырылмаган (әлеге баб текстының башы кулъязмада 4а кәгазьгә туры килә). Димәк, Югары Курса күчермәсендә баб-бүлек атамалары барлыгы 27 урында булырга тиешлеге ачыклана.

«Нуры содур» поэмасы эчтәлегенең бүленешен бәйтләр (икеюллыклар) саны буенча күздән кичерик. Текст башындагы 1–18 нче икеюллыклары урта гасыр мөселман әдәби әсәрләре кебек, традицион рәвештә Аллаһы Тәгаләгә, Мөхәммәт пәйгамбәргә, аның сәхабәләренә мактау һәм дога сүзләре багышлаудан гыйбарәт.

---

[2] Мәсәлән, кулъязманы күчерү өчен протографын биреп торган иясе, үзара килешенгән вакыт узгач кире алуыннан, шулай ук күчерүченең кинәттән авырып китүеннән (яисә вафат булуыннан), бәлки, берәр фаҗигале вакыйгага таруыннан һ.б. сәбәпләрдән килеп чыккан булуы ихтимал дип гөман итәргә мөмкин.

Шулардан иң беренче дүрт бәйт Аллаһы Тәгаләне данлау һәм аңа сыгыну сүзләре (сәна, тәүхид), 5–18 нче бәйтләр (барлыгы 14 икеюллык) пәйгамбәрне һәм сәхабәләрен мактау өлеше, ул «Нәгъте рәсүлуллаһи саллаллаһу галәйһи вәссәлләм» дип аталган. Мондый атама Олы Мәңгәр һәм СПб-2 күчермәләрендә язылган.

Әсәрнең 19–68 бәйтләрендә (50 икеюллыкта) ханга мәдхия сүзләре теркәлгән, ул «Дәр мәдхе падишаһи зәман вәли ма даимән әфзале әс-сәлятыйнез-зәмани гадел», ягъни «Замананың даими падишаһына һәм иң гадел солтанына мактаулар» дип исемләнгән. Бүлекнең мондый атамасы Исәнбәт[3], СПб-2 һәм Барда кульязмаларында теркәлгән, ә СПб-1 күчермәсендә ул «Фасыл» дип кенә аталган.

Ханны мактау-олылау сүзләре белән бергә «Нуры содур» әсәренең Сахибгәрәй хан исеменә атап язылганлыгы бәйан ителгән. Мәдхиягә, башка шигъри ядкярләр традициясе буенча, әсәрнең иҗат ителүе турындагы «сәбәбе тәэлиф» өлеше кушылып киткән. Бу бүлектә 61 нче бәйттә автор үзенең исемен күрсәткән.

69–72 нче бәйтләрдә «Нуры содур»ның иҗат ителгән елы һәм урыны белдерелгән.

Бу бүлек эчендә, текстның 30 нчы бәйтеннән соң «Пәйгамбәр галәйһиссәламгә дога әйделәр» дигән гыйбарә – төп текст эчендәге автор искәрмәсе Барда һәм Сарман кульязмаларында теркәлгән. Югары Курса күчермәсендә дә текстның шул урынында буш урын калдырылган. Барданыкында «галәйһиссәлам» дип кенә язылган, ягъни «гә» кушымчасы теркәлмичә калган.

Төп эчтәлегенең «баб»лары нәрсәләр икәнлеге 73–85 нче бәйтләрдә (13 икеюллыкта) аңлатылган. Югары Курса кульязмасында бу бүлекчәнең башында буш урын калдырылган. Димәк, башлангычта ниндидер атамасы булган. Башка күчермәләрдә аның аерым исеме теркәлмәгән. Шәрык-мөселман әдәби әсәрләре үрнәгендә, бу өлеше «Нуры содур»ның башлангычын («ифтитахелкитап»ны) тәшкил иткән дип күзаллана. Әлеге бүлекчәне тексттагы 73 нче бәйт алдыннан йолдызчыклар белән билгеләдек.

Әсәрнең төп өлеше беренче баб белән башланган һәм ул 86–140 нчы бәйтләрне (55 икеюллыкны) үз эченә алган. Аның исеме Олы

[3] Исәнбәт Н. Казан ханлыгы чоры әдәбиятыннан Мөхәммәдъяр Мәхмүд углы әсәрләре // Совет әдәбияты. – 1941. – №4. – Б. 69.

Мәңгәр, Барда һәм Сарман күчермәләрендә тулырак итеп «Әүвәл баб. Гадел кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур. Иннә Аллаһә Тәгалә йәэмүрү бил-гадли вәл-ихсани» дип теркәлгән. (Сарманныкында «Тәгалә» сүзе язылмаган, Олы Мәңгәрнекендә язуы бик начар таныла). СПб-1 кулъязмасында да атама тулы килеш, бары тик башы «Бабе әүвәл» рәвешендә. СПб-2 нөсхәсендә «Баб» сүзе төшеп калган һәм «сүзләрен» урынына «сүзен» дип кенә теркәлгән, башка өлеше тулы. Югары Курса күчермәсендә бу бүлек башында урын калдырылмаган. Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1966 елгы басмасында «Гадел кыйлмак сүзләрен бәян кыйлур» һәм 1997 елгы басмасында «Баб әүвәл; гадел кылмак сүзләрен бәйан кылур. Иннә аллаһә йөзмере бил-гадли вәл-ихсани» дип теркәлгән.

Беренче бабның 110–140 нчы бәйтләрендә (31 икеюллыкта) «Әл-хикәяте Гадел Нәүширван» кыйссасы урын алган. Мондый атама бары тик СПб-2 күчермәсендә генә бар, Сарман кулъязмасында ул «Әл-хикәят» дип, Барданыкында «Хикәят» дип кенә күрсәтелгән. Басмалардан 1966 елгы китапта «Әлхикайәти гадил Нуширван» һәм 1997 елгысында «Әл-хикайәт гадел Нәүшируан» диелгән.

Әсәрнең икенче бүлеге «Икенче баб. Рәхим-шәфкать сүзләрене бәйан кыйлур» дип аталган, ул 141–178 нче бәйтләрне (барлыгы 38 икеюллыкны) үз эченә алган. Бүлекнең мондый рәвештәге исеме Наратлык, СПб-2, Барда һәм Сарман күчермәләрендә бар. СПб-1 кулъязмасында ул «Фасыл рәхим-ү-шәфкать» дип кенә аталган. Басмаларның 1966 елгысында «Рәхим-шәфкать сүзләрен бәян кыйлур» дип, 1997 елгыда «баб» урынына «фасыл» дип язылган, калган сүзләре исә шулай ук бирелгән.

Бу бүлекнең эчендә 158–178 нче бәйтләре (21 икеюллыгы) Муса пәйгамбәргә багышланган һәм «Әл-хикәят» рәвешендә бирелгән. Ул Ижевск күчермәсендә шул рәвешле, СПб-3, Наратлык, Барда һәм Сарман кулъязмаларында «Хикәят» дип, СПб-1 нөсхәсендә «Фасыл» дип аталган. СПб-2 күчермәсендә берничек тә белдерелмәгән. 1966 елгы басма китапта шартлы рәвештә (җәяләр эчендә һәм курсив белән) генә «Муса хикәяте» дип, 1997 елгыда «Фәсыл» рәвешендә тәкъдим ителгән.

Нәүбәттәге бүлек 179–217 нче бәйтләрне (39 икеюллыкны) үз эченә ала һәм ул «Өчүнче баб. Сәхавәт сүзләрене бәйан кыйлур» дип аталган. Мондый рәвештә ул Ижевск, СПб-2, Барда, Сарман күчермәләрендә һәм 1997 елгы басмада теркәлгән. СПб-2

нөсхәсендә «сүзләрен» диелгән (мондый язылыш элек хәрәкәләр кулланылган булуга бәйле дип алда искәрттек). Ә СПб-3 кулъязмасында «Хикәят» дип, СПб-1 күчермәсендә «Фасыл» дип язылган, Исәнбәт нөсхәсендә «Өченче баб. Сәха сүзләрен бәян кылыр», 1966 елгы китапта «Сәхавәт сүзләрен бәян кыйлыр» дип бирелгән.

Бу бүлекнең эчендәге 189–217 нче бәйтләре (29 икеюллыгы) йөкче-утынчыга багышланган хикәятне тәшкил итә. Ижевск кулъязмасында ул «Әл-хикәят», ә СПб-3, Исәнбәт, Барда һәм Сарман күчермәләрендә, шулай ук 1997 елгы басмада «Хикәят» дип аталган, СПб-1 һәм СПб-2 текстларында бөтенләй теркәлмәгән. 1966 елгы басмада шартлы рәвештә «Хәммал хикәяте» дип язылган.

«Түртенче баб. Хәйа сүзләрене бәйан кыйлур» дигән бүлек исеме текстның 218–296 нчы бәйтләрен (79 икеюллыгын) үз эченә ала. Бүлекнең мондый исеме Ижевск, СПб-1, СПб-2 һәм Сарман күчермәләрендә бер төрле үк теркәлгән. Бары тик СПб-2 нөсхәсендә «...сүзләрен» диелгән, ягъни ахырдагы «е» хәрефе язылмаган. 1966 елгы китапта «Хәйа сүзләрен бәйан кыйлыр», 1997 елгы китапта «Түртүнче баб. Хәйа сүзләрен бәйан кылур» рәвешендә тәкъдим ителгән.

Әлеге бүлек эчендәге 245–296 нчы бәйтләрдә (52 икеюллыкта) «Кәүсәр суы»на (җәннәт чишмәсенә) багышланган хикәят бәян ителгән. Ул Ижевск һәм Сарман кулъязмаларында «Әл-хикәят» дип теркәлгән, СПб-1 күчермәсендә «Фасыл» дип язылган. Олы Мәңгәр белән СПб-2 нөсхәләрендә берничек тә аерып белдерелмәгән. Басма китапларның икесендә дә «Фәсыл» дип аталган.

Текстның 297–360 нчы бәйтләре (64 икеюллык) «Бишенче баб. Газат кыйлмак сүзләрене бәйан кыйлур. Калә галәйһиссәлам: Рәҗәгъна мин җиһадил-ахирәти» дип аталган. Бүлек исеме тулы рәвешендә (пәйгамбәр хәдисе белән бергә) Ижевск һәм СПб-1 күчермәләрендә теркәлгән. Ә Уразай, СПб-2 һәм Сарман кулъязмаларында, шулай ук 1997 елгы басмада хәдис язылмаган. Олы Мәңгәр нөсхәсендә бишенче бүлекнең исеме дә, хәдисе дә бөтенләй теркәлмәгәннәр. 1966 елгы басмада бу бүлек «Газәват сүзләрен бәян кыйлыр» дип бирелгән.

Бишенче бүлекнең 323–360 нчы бәйтләрендә (38 икеюллыкта) газыйлар турындагы хикәят тасвирланган. Анысы Ижевск һәм Сарман күчермәләрендә «Әл-хикәят» дип, ә СПб-1, СПб-2 һәм Барда кулъязмаларында «Хикәят» рәвешендә белдерелгән.

СПб-2 күчермәсендә хикәят текстының беренче икеюллыгындагы «хикәят» сүзе калынрак итеп язылып дулкынсыман сызык белән әйләндереп алынган. Олы Мәңгәр кулъязмасында хикәятнең атамасы ничек бирелгән булуы билгесез, – язуы уңган[4]. Әсәрнең Уразай нөсхәсендә бишенче бүлек эчендәге хикәят аерып аталмаган. Ике басма китапта да ул «Хикәят» дип теркәлгән.

«Алтынчы баб. Сабыр кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур. Йа, әййуһа әл-ләзинә әмәну, әсбиру вә сабиру вә рабиту вә әттәку Аллаһә ләгалләкүм түфлихүнә» дип исемләнгән бүлек текстның 361–416 нчы бәйтләрен (56 икеюллыкны) алып тора. Мондый – тулы язылышы Уразай, Ижевск, СПб-1, СПБ-2, Барда һәм Сарман кулъязмаларында теркәлгән. Барда күчермәсендә Коръән аяте бүлекнең исеме өстендә, төп шигъри текст юллары кебек, көрән төстәге кара белән язылган. Олы Мәңгәр күчермәсендә бары тик аять өлеше генә танылa. Ә СПб-3 нөсхәсендә бүлек исеме һәм Коръән аяте урынына «Хикәят» дип язылган. 1997 елгы басмада Коръән аятеннән башка өлеше бирелгән, 1966 елгы китапта «Сабыр кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлыр» дип аталган.

Бу баб-бүлекнең 386–416 нчы бәйтләре (31 икеюллыгы) чаян турындагы хикәяттән гыйбарәт. Уразай, СПб-1, Барда һәм Сарман күчермәләрендә ул «Хикәят» дип исемләнгән. СПб-2 кулъязмасында хикәятнең башы текстны сызык белән бүлеп кенә билгеләнгән. Ә Ижевск нөсхәсендә бернинди дә язуы юк. Олы Мәңгәрнекендә булып, уңгандыр. Ике басмада да «Хикәят» дип бирелгән.

Поэманың 417–471 нче бәйтләрендәге (55 икеюллыктагы) җиденче бүлек Уразай, Урта Шөн, СПб-1, СПб-2, Барда һәм Сарман кулъязмаларында «Йитенче баб. Вафа кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур» рәвешендә теркәлгән. СПб-1 нөсхәсендә бүлек исеменең астында «Каләән-нәби галәйһиссәлам: Әл-вафа фә-ма...» дип, хәдиснең башы язылган. (Мөхәммәд пәйгамбәрнең вафа – сүздә тору турында кырыктан артык хәдисе бар, шулардан кайсысы бу очракта күздә тотылганлыгы ачыкланмады). Олы Мәңгәр кулъязмасында да язулары булгандыр, хәзер күренми. 1997 елгы басмада «Йәтенче баб. Вафа сүзләрен бәйан кылур...» дип, 1966 елгы китапта «Вафа сүзләрен бәян кыйлыр» рәвешендә бирелгән.

---

[4] Һәрхәлдә, бу кулъязманың без эш иткән басмадагы (Мәскәү, 2007) бу урында һәм алга таба да бүлек-бүлекчә исемнәре танырлык түгел.

Әлеге бүлекнең 447–471 нче бәйтләрендә (25 икеюллыкта) Шәмгун турындагы хикәят сөйләнгән. СПб-1 күчермәсендә ул «Әл-хикәят» дип, ә Уразай, СПб-3, Урта Шөн, Барда һәм Сарман кульязмаларында «Хикәят» дип теркәлгән. СПб-2 нөсхәсендә шигъри юлдагы «хикәят» сүзе генә зуррак итеп язылган. Олы Мәңгәр күчермәсендә язуы уңган. Ижевск күчермәсендә мондый бүлекчә исеме теркәлмәгән. 1997 елгы басмада «Әл-хикәят» дип язылган, ә 1966 елгы китапка бу хикәят кертелмәгән.

Әсәрнең сигезенче бүлеге 472–529 нчы бәйтләрендә (58 икеюллыгында) урын алган. Ул «Сәкезенче баб. Сыйдык сүзләрене бәйан кыйлур. Калә Аллаһу Тәгалә: Вә мусаддикан лима бәйнә йәдәйһи» рәвешендә аталган. Мондый тулы исеме Уразай, Ижевск, СПб-1, Урта Шөн, СПб-2 һәм Сарман күчермәләрендә теркәлгән, ә Музей һәм СПб-3 нөсхәләрендә ул язылмаган. Олы Мәңгәрнекендә баб-бүлек исеме уңган булса да, Коръән аяте таныла. Барда кульязмасында «Сәкезенче баб. Сыйдык сүзләрене бәйан кыйлур» рәвешендә теркәлгән. Басмаларның 1997 елгысында бүлек исеме Коръән гыйбарәсеннән башка һәм «...сүзләрен» дип, 1966 елгыда «Сыйдык сүзләрен бәйан кыйлур» дип бирелгән.

Шушы сигезенче бүлекнең 497–529 нчы бәйтләре (33 икеюллык) телне тыю турындагы хикәяттән гыйбарәт. Ул Ижевск күчермәсендә «Әл-хикәят» дип, Барданыкында «Хикәят» дип теркәлгән. Олы Мәңгәр нөсхәсендә танылмый. Уразай һәм СПб-1 нөсхәләрендә, шулай ук ике басмада әлеге хикәят атамасы язылмаган.

Тугызынчы бүлек – «Тукузынчы баб. Самит кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур. Мән сәкәтә сәлимә вә мән сәмәтә нәҗа» дип аталган һәм текстның 530–562 нче бәйтләрен (33 икеюллыкны) алып тора. Мондый рәвештәге (пәйгамбәр хәдисе язылган) исеме, хаталы булса да, бары тик бер – СПб-1 нөсхәсендә генә теркәлгән. Уразай, Урта Шөн, СПб-2, Сарман күчермәләрендә һәм 1997 елгы басмада хәдистән башка өлеше язылган. 1966 елгы басмада әсәрнең бу бүлеге юк. Ижевск кульязмасында «Тукузынчы баб» дигән сүзләре генә бар. СПб-2дә хәдис урынында фәкать «бисмилләһи» диелгән, Уфа күчермәсендә бу бүлекнең исеме язылмаган. Олы Мәңгәр кульязмасында элек язылган булып, уңган.

Бу бүлекнең 536–562 нче бәйтләрендә (27 икеюллыгында) самит (аз сүзле кеше) турындагы хикәят бирелгән. Ул Ижевск кульязмасында «Әл-хикәят» дип аталган, ә Уразай, Урта Шөн һәм Сар-

ман күчермәләрендә, шулай ук 1997 елгы басма китапта «Хикәят» рәвешендә язылган. СПб-1, СПб-2 һәм Уфа нөсхәләрендә бөтенләй теркәлмәгән. 1966 елгы басмага бу хикәят кермәгән.

Тексттагы 563–605 нче бәйтләр (43 икеюллык) «Баб унунчы. Гафу кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур. Калә Аллаһу Тәгалә: Иннә Аллаһә кянә гафуан гафурән» дип исемләнгән. Бүлекнең мондый тулы атамасы бары тик Яңа Аккуҗа нөсхәсендә генә бар. Коръән гыйбарәсеннән башка өлеше Урта Шөн, СПб-2, Сарман кульязмаларында һәм 1997 елгы басмада бирелгән. СПб-1 нөсхәсендә Барда күчермәсендә «Унынчы баб. Гафу сүзләрен бәйан кыйлур» рәвешендә язылган. Олы Мәңгәр нөсхәсендә дә бүлекнең исеме булган, язуы уңган. 1966 елгы басма китапта «Гафу кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлыр» диелгән.

Бу бүлекнең эчендә 575–605 нче бәйтләрдә (31 икеюллыкта) Мәсгуд турындагы хикәят урын алган. Аның атамасы Ижевск, СПб-1[5], Яңа Аккуҗа күчермәләрендә «Әл-хикәят» дип, Сарман нөсхәсендә «Хикәят» рәвешендә теркәлгән. Олы Мәңгәр, Уразай, Уфа кульязмаларында хикәят башы берничек тәаталмаган. Ике басмада да «Хикәят» дип күрсәтелгән.

Әсәрнең 606–653 нче бәйтләре (48 икеюллык) китапның хатимәсе – бетем өлеше һәм ул ханга мәдхия белән кушылган. Кульязма күчермәләренең берсендә дә, шулай ук басмаларда ул аерым бирелмәгән. Без исә бу китапта аның башын (606 нчы бәйт алдында) өч йолдызчык белән билгеләдек. Яңа Аккуҗа күчермәсендә (3б кәгазьдә) 606 нчы бәйтнең кызыл төстәге язу карасы белән, хаталы булса да, язылганлыгы – элек ул урында бүлек (бүлекчә) исеме күрсәтелгәнлегенә ишарә итә дип аңларга мөмкин.

654–702 нче бәйтләрдә (49 икеюллыкта) заһид-суфи турындагы хикәят язылган. Яңа Аккуҗа күчермәсендә ул «Әл-хикәят» дип, Ижевск, СПб-1 һәм Барда кульязмаларында «Хикәят» дип теркәлгән, 1997 елгы басмада да шулай бирелгән. Олы Мәңгәр, Уразай һәм Урта Шөн кульязмаларында аерым билгеләнмәгән. 1966 елгы басма китапта бу хикәят юк.

Әсәрнең 703–706 нчы бәйтләрендә (4 икеюллыкта) авторның Аллаһы Тәгаләгә ялвару сүзләре теркәлгән. Кульязмаларда һәм басмаларда ул аерып күрсәтелмәгән. Бу китапта исә аның башланган

[5] Бу кульязмада хаталы итеп «Ә хикәйәт йәт» дип язылган.

урынын (703 нче бәйт алдында) өч йолдызчык белән билгеләдек.

Китапны ханга багышлау һәм аңа мәдхия өлеше 707–753 нче бәйтләрдә (47 икеюллыкта) аерым язылган. Кулъязмаларның бары тик берсендә генә – Югары Курса күчермәсенең 25а кәгазендә 707 нче бәйт алдында буш урын калдырылган. Димәк, башлангычта бу бүлекчәнең дә исем-атамасы булган дигән сүз. Басмаларда бүленмәгән. Бу китапта аның башына (707 нче бәйт алдында) өч йолдызчык куйдык.

Әсәрнең 754–768 нче бәйтләрендә (15 икеюллыкта) тургай турындагы хикәят язылган. Аның башы «Хикәят» дигән сүз белән бары тик СПб-1 кулъязмасында бар. Ә Уразай, Ижевск, Урта Шөн һәм Сарман күчермәләрендә андый атама юк. Югары Курса нөсхәсендә буш урын калдырылган. Басмаларда ул «Хикәят» дип бирелгән.

Мөхәммәдьярның тургай хикәятенә бәйләп ханга мөрәҗәгате һәм аны данлавы, китапның тәмамлануы турындагы сүзләре «Нуры содур» ахырындагы 769–794 нче бәйтләрдә (26 икеюллыкта) язылган. Бу басмада әлеге өлешнең башына – 769 нчы икеюллык алдына шулай ук өч йолдызчык куйдык. Әсәрнең бетем (хатимә) өлеше, шул рәвешчә, ике урында язылган. Алдарак 606–653 нче бәйтләрдә дә урта гасыр мөселман китапларына хас хатимә бүлеге бар. Бетемнәр ни сәбәптән ике урында икәнлеге билгесез.

Күргәнебезчә, кулъязма чыганакларда поэманың бүлек һәм бүлекчә атамаларында, аларның басма китапларда бирелешләрендә аермалар шактый.

Әсәрдәге бүлек текстларының күләме буенча иң зурысы 4 нче баб – ул барлыгы 79 икеюллыкны тәшкил итә, ә иң азы – 9 нчы баб – нибары 33 бәйтле. Баб-бүлек эчләрендәге хикәятләрнең иң күләмлесе – 4 нче бабта, ул 52 икеюллыктан тора, ә иң кечкенәсе – 2 нче бабныкы, анысы 21 бәйттән гыйбарәт.

Бүлек һәм бүлекчәләрнең «Фасыл» дип аталуы бары тик бер күчермәдә генә (СПб-1) биш урында теркәлгән. «Хикәят» һәм «Әл-хикәят» рәвешендәге язылышлар кулъязма күчермәләрдә төрлечә бирелгәннәр. Бөтенләй язылмыйча-күрсәтелмичә калган очраклары да бар. Чагыштырып өйрәнгәч, аларның күпчелеге – унике хикәятнең унысы «Әл-хикәят» дип теркәлгән булып, бары тик икесе генә «хикәят» дип язылганлыгы ачыкланды. Шунлыктан, аларны да бу китапта «әл-хикәят» дип бирергә карар иттек.

## Бу басма өчен нигез итеп алынган Югары Курса кулъязмасының палеографик хасиятләре һәм текст бирелешенең үзенчәлекләре

*1 нче бәйт.* «Барча» сүзе кулъязмада «барчаны» дип теркәлгән.

*2 нче бәйт.* «Йәшем» сүзе кулъязмада «йәш» дип теркәлгән.

*3 нче бәйт.* Кулъязманың кәгазе таушалган булуы сәбәпле, бу юлның ахыргы ике сүзе күренми. Алар әсәрнең башка күчермәләре буенча бирелде.

«Нәғте рәсүлуллаһи...» дигән бүлек исеме СПб-2 күчермәсе буенча бирелде.

*8 нче бәйт.* «Хатәмдүр» сүзе алдында кулъязмада «һәм» теркәгече бар.

*9 нчы бәйт.* Кулъязмада «рисаләт» һәм «әнбийа» сүзләре алдында «вә» теркәгече язылган.

*12 нче бәйт.* Кулъязманың кәгазе таушалганлыгы сәбәпле, ахыргы ике сүзе күренми. Алар әсәрнең башка күчермәләре (СПб-2 һ.б.) буенча бирелде.

*13 нче бәйт.* Кулъязманың кәгазе таушалганлыгы сәбәпле, бу икеюллыкның сүзләре өлешчә генә сакланган. Икеюллык әсәрнең башка күчермәләре буенча бирелде.

*16 нчы бәйт.* Кулъязмада «арыслан» сүзе урынында «ислам» дип теркәлгән.

*18 нче бәйт.* «Қыйлма» сүзе урынында кулъязмада «қыйлмасын» дип теркәлгән.

«Дәр мәдхе падишаһи...» дигән бүлек исеме СПб-2 һәм Барда күчермәләре буенча бирелде.

*20 нче бәйт.* Кулъязмада «иқбаль» сүзеннән соң «вә» теркәлгән.

*22 нче бәйт.* Ике юлның да ахырларында кулъязмада «ирүр» сүзләре теркәлгән, «җәмиғ» сүзе «җиғ» дип хаталы язылган. Ул сүзнең алдында «аның» дип язылган. «Әғда» сүзе «әғдаләр» дип теркәлгән.

*24 нче бәйт.* Кулъязмада «ус» сүзе теркәлмәгән. Монда СПб-2 күчермәсе буенча өстәлде.

*26 нчы бәйт.* Кулъязманың кәгазе таушалганлыгы сәбәпле, бу бәйттәге беренче юлның башындагы ике сүзе СПб-2 күчермәсе буенча бирелде.

*27 нче бәйт.* Кулъязманың кәгазе таушалганлыктан, бу икеюллыкның беренче юлы тулаем, икенче юлдагы беренче һәм ахыргы сүзләре СПб-2 күчермәсе буенча бирелде.

*28 нче бәйт.* Кулъязманың кәгазе таушалганлыгы сәбәпле, икенче юлдагы соңгы сүз СПб-2 күчермәсе буенча бирелде.

«Пәйғамбәр ғәләйһиссәламгә доға әйделәр» дигән гыйбарә Сарман күчермәсе буенча бирелде.

*31 нче бәйт.* Бу икеюллыкның «теләрмез» сүзе кулъязмада «теләримез» дип хаталы язылган.

*41 нче бәйт.* Кулъязманың кәгазе таушалганлыгы сәбәпле, бу икеюллыкның беренчесендәге соңгы ике сүзе һәм икенче юлдагы беренче сүзе генә сакланган. Текст СПб-2 күчермәсе буенча тулыландырылды.

*43 нче бәйт.* Кулъязмада «тигермәс» сүзе «тигмәс» дип ялгыш теркәлгән.

*45 нче бәйт.* «Кем» сүзе кулъязмада юк. Монда СПб-2 күчермәсе буенча өстәлде[6].

*47 нче бәйт.* Кулъязмада «күңлүл» дип хаталы язылган.

*56 нчы бәйт.* «Әсрү» сүзе кулъязмада хаталы теркәлгән.

*61 нче бәйт.* «Атам» сүзе кулъязмада «атамыз» дип теркәлгән.

*64 нче бәйт.* Кулъязмада «табыбдур» сүзе хаталы язылган.

*67 нче бәйт.* «Бисәр-ү-саман» гыйбарәсе кулъязмада хаталы теркәлгән.

*69 нчы бәйт.* Кулъязмада «тарихның» дип теркәлгән.

*70 нче бәйт.* «Авазәсендә» сүзе кулъязмада ялгыш «рәвазәсендә» дип теркәлгән.

*71 нче бәйт.* «Мөхәммәдәмин» исеме кулъязмада: «Мөхәммәдәбин» («Мөхәммәд ибн») дип ялгыш теркәлгән. «Йар» сүзе урынында «шәһрейар» дип язылган.

*74 нче бәйт.* Кулъязманың икенче юлында иң алда ялгыш «Рәхим» сүзе язылган.

*80 нче бәйт.* Кулъязмада «йитенче» сүзе теркәлмичә калган.

*81 нче бәйт.* Кулъязмада «бабы» сүзе теркәлмичә калган, «һәркем» сүзе ялгыш «һәм» дип язылган.

---

[6] Текст өчен кулланылган Югары Курса кулъязмасындагы ялгышларга төзәтмәләр һәм өстәмәләр алынган башка күчермәләр алга таба җәяләр эчендә кыскача – (Уразай), (СПб-2) һ.б. рәвешендә күрсәтелә.

*82 нче бәйт.* Бу бәйттәге ике юлда да «самит» сүзе ахырында «д» хәрефе белән «самид» дип теркәлгән.

«Әүвәл баб...» дигән бүлек исеме «Барда» күчермәсе буенча бирелде.

Кулъязмада 89 һәм 90 нчы бәйтләрнең юллары ялгыш бутап теркәлгән.

*89 нчы бәйт.* «Җәван» сүзе кулъязмада «чәван» дип теркәлгән.

*90 нчы бәйт.* Кулъязмада «қыйл» сүзе «қыйлғыл» дип теркәлгән.

*92 нче бәйт.* Кулъязмада «ул» сүзе теркәлмәгән. (СПб-2).

*95 нче бәйт.* Кулъязмада «ил» сүзе ялгыш «илде» дип, «зольме ғөдван» гыйбарәсе «залим ғөван» дип теркәлгән.

95 һәм 96 нчы бәйтләр СПб-1 күчермәсендә дә шушы тәртиптә, ә Олы Мәңгәр, СПб-2 Сарман нөсхәләрендә урыннары алышынган.

*97 нче бәйт.* «Ғибадәтдин» сүзе кулъязмада «ғибаддин» дип хаталы язылган.

*100 нче бәйт.* «Мәғдәне» сүзе кулъязмада ялгыш «мәғнәсе» дип теркәлгән. (СПб-2).

*101 нче бәйт.* «Алтмыш» сүзе кулъязмада ялгыш языла башлап, яңадан теркәлгән. «Йылдин» сүзе кулъязмада «йыл» дип кенә теркәлгән. (СПб-2). «Озақрак» сүзе кулъязмада «озақ» дип кенә теркәлгәнгә охшаган. Ул урында кәгазенең чите ертылганлыктан төгәл әйтеп булмый, әмма күпчелек кулъязмаларда бу сүз «озақ» дип язылган.

*104 нче бәйт.* «Ул» сүзе кулъязмада «у» дип кенә теркәлгән.

*105 нче бәйт.* «Эшләр» сүзе кулъязмада «эшләрдә» дип теркәлгән. (СПб-2).

*107 нче бәйт.* «Сүзене» гыйбарәсе кулъязмада «сүзен» дип теркәлгән.

*109 нчы бәйт.* «Золым» сүзе кулъязмада «зольме» дип теркәлгән. «Йаман» сүзе алдында ялгыш «бу» дип теркәгән сүзен күчерүче сызып төзәткән.

«Әл-хикайәте ғәдел Нәүширван» дигән бүлек исеме СПб-2 күчермәсе буенча бирелде.

*112 нче бәйт.* Кулъязмада «ғәдле» сүзе ялгыш языла башлап сызылган һәм дөрес итеп теркәлгән.

*114 нче бәйт.* «Қыйлдылар» сүзе кулъязмада «қыйлды» дип теркәлгән. (СПб-2).

*116 нчы бәйт.* «Тынсын» сүзен «тийенсен» (ягъни, шатлансын) дип тә укырга мөмкин.

*121 нче бәйт.* «Пәнде» сүзе кулъязмада «бәнде» дип теркәлгән.

*124 нче бәйт.* «Мөлекне» сүзеннән соң кулъязмада «йәнә» дип артык гыйбарә теркәлгән.

*128 нче бәйт.* «Җәң» сүзе кулъязмада «чәң» дип теркәлгән.

*132 нче бәйт.* «Хәййерен» сүзе кулъязмада «хәбәрен» дип ялгыш теркәлгән.

*133 нче бәйт.* «Улмаз» сүзе урынында кулъязмада «ирүр» дип ялгыш теркәлгән. (Наратлык).

*135 нче бәйт.* Кулъязмада «килүр» сүзенең «р» хәрефе теркәлмәгән.

*136 нчы бәйт.* Нәүширван исеме кулъязмада «Нүшин рәван» дип хаталы язылган.

*138 нче бәйт.* Кулъязмада «мәғмүр» сүзен ялгыш яза башлап, сызылмыйча калдырылган «мәм» иҗеге бар.

*139 нчы бәйт.* Кулъязмада «туар» сүзенең артык (өченче) «уау» хәрефе язылганнан соң, кырып чистартылган.

«Икенче баб...» дигән бүлек исеме Наратлык күчермәсе буенча бирелде.

*141 нче бәйт.* Кулъязмада «рәхим-ү-шәфкәт» дип һәм икенче юл ахырындагы сүз «хуш» дип теркәлгән.

*142 нче бәйт.* «Йарлы» сүзе кулъязмада «йари» дип теркәлгән. (Наратлык).

*146 нчы бәйт.* Кулъязмада «күңүлгә» сүзе алдында «бу» дип теркәлгән.

*155 нче бәйт.* «Кемгә» сүзеннән соң кулъязмада «кем» дип теркәлгән.

*156 нчы бәйт.* Беренче юлның беренче сүзе кулъязмада ялгыш «йари» дип язылган. «Күрмәз» сүзенең «-ләр» кушымчасы артык язылып, күчерүче тарафыннан сызылган.

«Әл-хикәят» дигән атама Ижевск күчермәсе буенча бирелде.

*159 нче бәйт.* Икенче юлдагы «нийазы» сүзе кулъязмада «нийаз» дип теркәлгән.

*162 нче бәйт.* Икенче юлдагы «мәңа» сүзе кулъязмада юк. (Ижевск). «Булсун» сүзеннән соң кулъязмада «бу» дип теркәлгән.

*163 нче бәйт.* Кулъязмада «аңа» сүзе теркәлмәгән. (Наратлык).

*166 нчы бәйт.* Кулъязмада «қуйларыны» сүзенең ахыргы хәрефе теркәлмәгән.

«Өчүнче баб...» дигән бүлек исеме Ижевск күчермәсе буенча бирелде.

*179 нчы бәйт.* «Мәғдәненең» сүзе кулъязмада «мәғдийенең» дип хаталы теркәлгән.

*180 нче бәйт.* Кулъязмада «йитәрчә» сүзенең «т» хәрефе астында ялгыш нокта куелган.

*184 нче бәйт.* «Таҗе сәр» сүзтезмәсе кулъязмада «таҗ вә сәр» дип ялгыш теркәлгән. Күрәсең, протографындагы «җ» хәрефе өстендәге даммә хәрәкәсе «вә» теркәгече итеп күчерелгән.

*185 нче бәйт.* Кулъязмада «ошбу сүзне» урынына «ошбуны» диелгән. (Ижевск).

«Әл-хикәят» дигән атама Ижевск күчермәсе буенча бирелде.

*191 нче бәйт.* «Фәқир» сүзе урынында кулъязмада «тәр» дип ялгыш теркәлгән. (СПб-2).

*194 нче бәйт.* «Дәнкесене» сүзенең соңгы хәрефе кулъязмада юк.

*195 нче бәйт.* Кулъязмада «үзе» дигән сүз теркәлмәгән. (СПб-2).

*199 нчы бәйт.* Кулъязмада «алды» сүзеннән соң «уд» дип теркәлгән.

*200 нче бәйт.* Кулъязмада «уғлы» сүзенең «у» хәрефе генә теркәлгән. Шунда ук «қызы» дигәннән соң хаталы «қа» иҗеге язылып, сызылган.

*201 нче бәйт.* Кулъязмада «ир» иҗеге ялгыш ике мәртәбә язылып, берсе сызылган.

*204 нче бәйт.* Кулъязмада «базар» сүзе ялгыш «баз» дип кенә теркәлгән, бәйт ахырында «кечек һәм олуғ» дип язылган.

*205 нче бәйт.* «Изыды» сүзе кулъязмада «йадады» дип теркәлгән.

*206 нчы бәйт.* «Тыңлағыл» сүзе кулъязмада «тыңла» дип теркәлгән. (Ижевск).

*208 нче бәйт.* Кулъязмада «мәңа» дигән сүз теркәлмәгән. (СПб-2).

*210 нчы бәйт.* «Сүзене» сүзе кулъязмада «сүзен» дип теркәлгән. (Ижевск).

*215 нче бәйт.* Икенче юлдагы «вә» кисәкчәсе кулъязмада теркәлмәгән. (СПб-3).

*217 нче бәйт.* «Нәмәрсә» сүзе кулъязмада «нәрсә» дип теркәлгән.

«Түртенче баб...» дигән исем Ижевск күчермәсе буенча бирелде.

*220 нче бәйт.* «Дәүләт» сүзендәге «ләт» иҗеге кулъязмада ялгыш теркәлгән һәм сызып, дөресләп язылган. Беренче юлның ахыргы сүзе кулъязмада «мөдам» дип теркәлгән.

*221 нче бәйт.* «Дидар» сүзе кулъязмада «дивар» дип ялгыш теркәлгән.

*225 нче бәйт.* «Сақлар» сүзе кулъязмада «сағлар» рәвешендәрәк теркәлгән. Чынлыкта, «қаф» хәрефенең ике ноктасы куелмаган.

*229 нче бәйт.* «Берлә» сүзе кулъязмада «перлә» дип теркәлгәнгә охшаш булса да, чынлыкта «би»нең бер һәм «йа»ның ике нокталары берләштереп, өч нокта рәвешендә язылган.

*235 нче бәйт.* Беренче юлы кулъязмада «Ул кеше ирер ислам зәғиф» дип, икенче юлдагы «йаре» сүзе «бар» дип теркәлгән. (СПб-3).

*238 нче бәйт.* «Төрк» сүзе кулъязмада «төрки» дип теркәлгән. (СПб-3).

*239 нчы бәйт.* «Кемдә» сүзеннән соң кулъязмада «кем» сүзе теркәлгән.

*240 нчы бәйт.* «Дәрд» сүзе кулъязмада «дур» дип хаталы теркәлгән.

*242 нче бәйт.* Икенче юлдагы «ул» сүзе Ижевск күчермәсе буенча өстәлде.

*243 нче бәйт.* «Күңүл» сүзе кулъязмада «күңлүл» дип, «йолур» сүзе «пелүр» дип хаталы теркәлгән. Соңгысы СПб-2 күчермәсе буенча бирелде.

*244 нче бәйт.* Бу икеюллык кулъязмада хаталы язылып, яңадан кабатлап теркәлгән. «Һич» сүзе кулъязмада «һәр» дип теркәлгән. (СПб-3). Бу бәйттән соң «Әл-хикайәт» бүлекчәсе исеме язылырга тиешле буш урында 245 нче бәйтнең башындагы «Бер хикайәт қыйла» өлеше ялгыш теркәлгән.

«Әл-хикәят» дигән атама Ижевск күчермәсе буенча бирелде.

*248 нче бәйт.* «Олуғларның» сүзе кулъязмада «олуғ суларның» дип ялгыш теркәлгән. (СПб-2).

*249 нчы бәйт.* «Суы» сүзе кулъязмада «суны» дип теркәлгән.

*252 нче бәйт.* «Йазылары» сүзе кулъязмада «йазылар» дип теркәлгән.

*253 нче бәйт.* «Күчтеләр» сүзендәге «т» хәрефенең ике ноктасы урынына кулъязмада ялгыш өч нокта куелган.

*255 нче бәйт.* «Утлар» сүзе кулъязмада «утлары» дип ялгыш, «тарафда» сүзе «тарафыда» дип теркәлгән.

*256 нчы бәйт.* Кулъязмада «йәш» дигәннән соң теркәлгән «ут» сүзе артык. Чөнки аннан соң килгән «ғәләф» сүзе дә «үлән» мәгънәсендә. Кайбер күчермәләрдә бу бәйт юлларының урыннары алмашкан (мәсәлән, Ижевск һәм СПб-1). Ә Олы Мәңгәр һәм СПб-2 кулъязмаларында үзгәрешсез.

*257 нче бәйт.* «Җай пөр» сүзләре кулъязмада «җайыр» рәвешендә хаталы теркәлгән. «Чәмән» сүзендәге «ч» хәрефе астында өч нокта урынына ялгыш ике нокта гына куелган.

*259 нчы бәйт.* Кулъязмада «эче» сүзендәге беренче хәрефтән соң ялгыш сәкен хәрәкәсе куелып, күчерүче тарафыннан сызылган.

*260 нчы бәйт.* «Кем» сүзе кулъязмада теркәлмәгән. (СПб-2).

*261 нче бәйт.* «Ул» сүзе кулъязмада теркәлмәгән. (СПб-2).

*263 нче бәйт.* «Суы» сүзе кулъязмада «су» дип теркәлгән. (СПб-2).

*266 нчы бәйт.* Кулъязмада «аны» сүзеннән соң «хуш» дип теркәлгән.

*268 нче бәйт.* «Җаны» сүзе кулъязмада «хан» дип ялгыш теркәлгән.

*273 нче бәйт.* «Шаһны» сүзе кулъязмада «шаһ» дип теркәлгән.

*274 нче бәйт.* «Тәүәсендин» сүзе кулъязмада «тәүәдин» дип теркәлгән. «Йөдәб» сүзе урынында бу кулъязмада, шулай ук башка күчермәләрнең күбесендә «би-әдәб» (әдәпсез) дип язылган. (СПб-2). Бу сүзгә бәйле мәсьәлә кереш мәкаләдә тәфсилләп аңлатылды.

*278 нче бәйт.* «Суыны» сүзе кулъязмада «суын» дип теркәлгән. (Ижевск).

*281 нче бәйт.* «Сув» сүзе кулъязмада «сувың» дип теркәлгән. (Уразай).

*282 нче бәйт.* Кулъязмада «ирде» сүзе алдында «су» дип ялгыш язылып, күчерүче тарафыннан сызылган.

*286 нчы бәйт.* Кулъязмада «бирең» сүзе хаталы теркәлеп, сызылган һәм дөресләп яңадан язылган. «Биреңез» варианты Уразай күчермәсеннән өстәлде.

*288 нче бәйт.* Кулъязмада «теркенчә» сүзендәге «н» хәрефенең ноктасы куелмаган. «Мүнүб» сүзендәге «м» хәрефе астына кулъязмада бер нокта куелган. Күрәсең, бу сүз башта «бүнүб» дип язылган булгандыр.

*289 нчы бәйт.* «Сыв» сүзе урынында кулъязмада «сер» дип теркәлгән. (Уразай).

«Бишенче баб...» исеме Ижевск күчермәсе буенча бирелде.

*293 нче бәйт.* «Биэр» сүзе кулъязмада «безне» дип ялгыш теркәлгән.

*295 нче бәйт.* Кулъязмада «қыйлғаныны» сүзенең ахыргы хәрефе теркәлмәгән.

*298 нче бәйт.* «Бабын» сүзе кулъязмада «бын» дип ялгыш теркәлгән.

*301 нче бәйт.* «Ғәзат» сүзе урынына кулъязмада «ғәзавәт» дип теркәлгән. (Уразай).

*303 нче бәйт.* Кулъязмада «ғөқбаны» сүзе хаталы язылып, кәгазь читендә дөрес итеп теркәлгән.

*314 нче бәйт.* Бәйтнең беренче сүзе итеп кулъязмада «ул» дип язылган. Кулъязманы күчерүче «Мөбарәк мостафадин» гыйбарәсен «Мостафа мөбарәкдин» дип ялгыш язган һәм үзе үк сүзләрнең өсләренә урыннарын алмаштырып дөресләүне белдерә торган тамгалар куйган. Кулъязмада «кем» сүзеннән соң «рәсү» дип яза башланып, тәмамланмаган һәм сызылмыйча калдырылган.

*316 нчы бәйт.* Кулъязмада «төрки» сүзенең «р» хәрефе башта язылмыйча калып, «кәф» өстенә кечерәк итеп өстәлгән.

*317 нче бәйт.* «Ишетеб» сүзе урынына кулъязмада «ишет» дип теркәлгән. (Сарман).

*318 нче бәйт.* «Астында» сүзе кулъязмада «аләтендә» дип теркәлгән. (Ижевск).

*319 нчы бәйт.* Кулъязмада «малындин» сүзенең «ма» иҗеге теркәлмичә калган.

*321 нче бәйт.* Кулъязмада «ислам» сүзенең ахырындагы «м» хәрефе теркәлмәгән.

*322 нче бәйт.* Кулъязмада «дин вә» сүзләре теркәлмәгән. (Уразай).

«Әл-хикәят» дигән атама Ижевск күчермәсе буенча бирелде.

کوب ایدور بو صامت لیق فایده سی / تیکلا ایمدی کوب دور بو اشنینک فایده سی

ایدی صلمت بولونک تیب اول مصطفی / من شکت سلم ومن صمت نجی

هرکه ساکن دور سلامت بولغای اول / صامت الغای انم نجات قه یتوغای دول

19а кәгазь

هر كه سالم سالمه اير ايرسه يكم يورى     محكم و مستحكم يولور انينك سوزى

كيم بو صامت سوزيكين شاه جهان     قيلايم ايمدى سوزنكا تيل اريان

بار ايردى تنوحى پير سنك خواه     كيلور ايردى واقف كيچمشيدن اگاه

اورزنار دك ايردى كونكلى كيريم     ايل ايچرا ايردى عالم هم حكيم

اولتوروب منبر اوزرا ايم اوزن     تنكرى امرى ايردى سوزلاكان سوزى

بر كونا اوروب وعظ ايچنده كهان     كيم تيلندن يورب بو سوز اودان

هر كه صامت بولسا هم ايشه ارزى     كيم كلمة الله دور و سلام ايچرا اوزن

تينكلا ايمدى بو حكايتنى تمام     انكلا ايمدى بو سوزنى نيك نام

بار ايردى مجلس ايچرا بر جوان     اوشبو وعظنى كونكلينه توشتى ناگهان

كيم اول ايل ايچرا بولور ايردى اوزن     مشهور ايردى صامت ليق ايچرا اوزى

بيهوده قوتنكشم ليق بار ايردى     اوزنى بر بخت ايمانى افكار ايردى

اولتوروب ايردى كونى صامت جوان     كيلدى اندار ايتدى اول بدبخت يمان

اوشبو صامت پهلوان نا خير ايردى     اول بيهوده قلغا بس قادر ايردى

صامت ايتى اوزنه مادت تابع سوزن     كونكلى نا آنمير اليب چاتماديدى سوزن

يو قلايو

*19 б кәгазь*



*20а кәгазь*



عفو بستانی نینک ارتاره گلی | قیرشونکیزده ایسراب اورش ئیل بلبلی
عفو بابرین ایمز خوش لاشن ایتار | سوزلاری کونکولی کاشتی ایتار
عفو قیلماق ایرور ایر نینک ایرصی | ایرصی مینزا مینک دام ایرور بر صی
عفو قیلماق تنکری بویوردی ابرار | بویوردی قیلین توتقانغا الر جنت
حق تعالی بویوردی قیلین توت روان | خاص عام دین عفو قیلغیلار جوان
کیم بیهانلیق قیلسا سیزکا دام برم | سیز انکا احسان بیلا قیلنکز کرم
عفو قیلماق بر لا بولور ایر عزیز | عفو قیل بارچادین ای عقل تمیز
عفو قیلماق بولور ایشت | معنی سینی ایتایم انکلا یکیت
کیم کیچی رماک ایرور بر بنده دین | ارغمان دیان غا ابی شرمنده دین
حق ایرور رحمت قیلیب انلارغه اوش | روزی قیلادوق جنت فردوس نغی خوش
حور رضوان تیلاکان کیشی مدام | عفو قیلسون بارچه لاردین اول تمام
ناگهان یاردین بینکلسا بر کیشی | کیچورلاب اندین کیم بولسون اشی

بر حکایت نظم ایتایم انکلانکیز | جان و دل بر لا سوزینی تنکلانکیز
کیم ایدی ادنا

*20б кәгазь*

کیم اوزانی رون کار ایچه امکس    بر ملک بار ایردی اسمی معتبر
کیم آتی مسعود ایدی اوزی نینگ    شاهی ایردی اوزی اول ایر یوزی نینگ
اوزلاری عصری ایچنده ایر یکیت    هم ینه بر شاه بار ایردی خوش اشیش
ابن اشعث ایردی اول شاه اتی بیل    اوش حکایت قیلسونم آتی ایز کا تیل
بو ایککو اوشتما ایردیلار تمام م    اولار ایردی بر بیرینه مردم
تابماس ایردی بر بیریکا ظفر    تنکلا ایمدی ایتایم اوش من خبر
عاقبت مسعود ایغدی لشکرین    ایل الوس لا قوبماداری اوروشقا ایرین
قصد اوزدی ایککو توروشتیلار    ایکی لشکر کوروب قیتیغ اوروشتیلار
تنکری تقدیری بر لا ناکهان    ابن اشعث لشکری سنیدی روان
دوتقا عتف قابر ایردی مسعود اول    ابن اشعث لشکرینی قیردی اول
الیلار اسیر کوب ادیجالار امیر    اول چریک اینی قیلیلار اوکوشرا اسیر
عز نصرت بر لا ایغو کا کیلدی شاه    اول اسیرلار نینگ تمو غمین یفدی شاه
اوزی التونی هندای لا الدتوروب    سودار ایردی بارچه بیر کیلتوروب
بیر یکیت کاتو وشتی ناکهان کوزی ب    آی اولدم کیلتوروب سوردی اوزی
اول یکیت ایدی کیم ار شاه جهات    بر سوزوم بار ایتایم بر کیل امان

*21а кәгазь*

شاه ایدیکیم امان برکیم سنکا — دی سوزنینک بار ایسه ایغیل ادشمنکا

اول یکیت ایدیکیم ای شاه کرم — سوزنی ایتایم ایشتکیل اول بو دم

سن تیلاکان ایشنی بیردی حق سنکا — حق سنکا تیلاکانی ایشنی قلیغیل بزنکا

نصرت ایردی تیلاکینک تابتینک آنی — عفو ایردر سیزینک ایندی تیلاکانی

حق تعالی سنکا دولت بیردی اوش — دشمنانیکنی قهر قیلدینک بارچا خوش

سن تیکی حق لیق اوچون شاه جهان — عفو ایتب بیزنی کیچورکیل ای شهان

سنی بیزنیم هم انمیز غنا بقما غیل — قهر اوتی برلا بیزنی یاقما غیل

لطف قیلدی اوشبو سنکا پروردکار — قهر قیلمایین کاسین ال شامدار

عفو ایتب قیل کونکلومیزنی ایمدی شاه — لطف قیلیب بارچامیزنی قیل آزاد

کیمکیریم دین دایما کیلور کرم — بس کرم قیلیب بیزکا شاها سن بو دم

شاه اول دم انکلادی یکیت سوزینی — کونکلی سوزنی ایتور تیبو اوکلدی اوز دینی

قیلدی ایغانی سوزلاریسنا اول شاه قبول — اول یکیت نینک قیلمادی کونکلنی ملول

اول یکیت سوزنی اول دم ایشتب — اول اسیرلارنی ایسه کتاب رحیم ایتب

حق رضاسی اوچون اول شاه جهان — بارچاسین آزاد قیلدی اول زمان

اول یکیت کا دیبی لیقاب سیورغادی — عمری بارنچه تینب خوش ایدی غادی

ال

21б кәгазь



*22а кәгазь*

دولت وفتح وظفر بر لا مدام سلطنت تختیده اورن ایدوریل تمام

عمر و دولت بر لا شادمان ایشانکیز قیلدی بولسا دشمنانکیز توشانکیز

بیز کا کیم قیلسا دعا لار دایم بدم لطف بیلا قیلانکیز انکا کرم

همرشادیز لیسیز یا الله العالمین بو دعای مستجاب ایتکیل امین

بر سبب دین بار ای تحریر ایتادیم مقصود دور ای بیز کا تقدیر ایتادیم

شاه عالم نینک مبارک آتینا کوب دعا بولسون تیب ایریغ دیتین

ترکی نظم ایتیب بتردیم بو کتاب نور صول لار انینک آتینی آفتاب

ختم قیلدیم سوزلاریغ ایمدی ادیش حق مبارک قیلسون ای شاه خوش

نیچاکیم بولسا جهان ده آدی ویسل نیچاکیم سوزلانسا تیلدا اقبال قیل

هر کیم ای ادقوسا دور دم بدم یا قیچا کیم بتیسا آیغای ای قلم

پادشاه عمرادیما قیلغان دعا جان و دل بیلا ادکوش ایغان ثنا

ادعیا لاری انشکان پاک تاک حضرتینکا اوش قیلیب یوزدیم بخاک

زار بیلا امین دعا قیلیم اوش لطف بیلا قیل اجابت ای نوش

بو زمانه عمارلارنینک سلطانی دنیا ایچرا بارچا خانلار نینک خانی

شاه عالم همیشه قیلغیل ادکوش یتی اقلیمی انکا بیرکیل ادلوش

دولت

*22б кәгазь*



*23а кәгазь*



بو ملا نمیجی تنکری نینک لطفی انکا
کیم یما کلبر جنت ساقولاق توت منکا

بر حکایت قیلایم انکلا بو دم
صاحاقانه خوش ایشیت فخر الامم

جابر انصاری ایتور ابر حوان
ایدی منکا حق رسولی اول زمان

کیم قیتمی بن حالی جیقیتی جبرائیل
اول حکایت منکا قیلدی انکلا نمیل

کیم بنی اسرائیل ایچرا مکر
بر زاهد بار ایدی خوش معتبر

حق بولنده کوک اورونمیدین کیسلی
ازلت ایتی بر جزیره کیلیب

اول جزیره تنکز ایچره ایدی بیل
بتمیش ایدی انده بر باغ انکلا نمیل

چیقار ایدی اول تاغمیدین بر بولاق
اقار ایدی سغو بال ایرنی تاتلیغ راق

اول بولاق اوستونده بتمیش بر تراک
سایه سی بار غه دایم ایدی یمشی راق

نار اغاچی ایدی اول تراک ایشیت
کونده بر نار بره ایدی ایشیت

زاهد اول یرده کوروب قیلدی مقام
طاعت ایتر انده دایم صبح و شام

هر صباح اول چشمه کا کیلور ایدی
ابدست الیب اول نماز قیلور ایدی

اول نار بر لا ادروزی ایجیب
بر کیچه اول چشمه سوغو ایچیب

ایدی تاکیچه قیلیب اول حق غه نیاز
تانکه تیکلو قیلور ایدی کوب نماز

کونداوز

*23б кәгазь*



*24а кәгазь*

اول عبادت قیلماغا توفیق ینا    روزه‌لر قیلدیم ایران غنیمت ای زاهد سنگا
تنگری نینگ بو بیتدین اول زمان    زاهد مسکین‌نی سوسانماغان تاکیماها
بر فرشته صاحب حسن جمال    بر قدحنی تولتوروب آب زلال
زاهد الیندین اوزان کیچمک کیلیب    ایغلاب اول زاهد افغان اوروب قیلیب
کلکچ اول الیغنی ینا بیر ایچیم اسرا اولش    منکا بیر کیل ایچایم اول سوونی خوش
اول فرشته ایغلاب زاهد منکا    طاعتنک بیر کیل بیرایم سوونی سنکا
زاهد ایغلاب بولدی بیل لیق طاعتیم    بیرایم کیم بو قنتور اوزنکا طاعتیم
اول فرشته قیلماغان آنی قبول    یا داغماغان زاهد بولدی اول دم ملول
عاقبت زاهد سوسالیقدین بی تاب    بارچا قیلغان طاعتینی انکا آتاب
کیتکان اوزی دنیادین تیلموروب    طاعتی بیر ایچیم سوغه تیکشوروب
اول قدحنی آلیب ایچکان اول زمان    طاعتیدین بی نوا قالغان همان
قیلغان اول دم حضرت عزت خطاب    کیم ایا زاهد سنکا ایتیل جواب
بیش یوز ییل طاعت ایتکانینگ قویغان    بیر ایچیم سوغه ساتیب طالعینگ قورغان
بار ایدی ایمدی تموغقا کیل روان    زار قیلیب زاهد ایغلار اول زمان
بارچه‌نی زهد قیدین ایرتقان پاک تاکی    پطلدیم اول دم مینی قیلماق هلاک
کیتی



کیتمه گمرم ایچره قیلغانم طاعتم	تموغ ایچره ایتماغای یوق طاقتیم
کیم بیر ایتینک مینی سین اسر ضعیف	لطف قیلغیل منکا بولغان لطیف
رحمتنک برلا مینی سین یارلیقا	روزی قیل لطفونک بیلا منکا لقا
لطف برلا قیلماسانک منکا نظر	بولدی ارشلاریم تموغ از یرزبر
حق تعالی ایغلارای زار ابر بولدم	رحمتم برلا سنکا قیلدیم کرم
بار غیل اوش جنتکا ایمدی کمانه	روزی قیلدیم سنکا خوش حور جنان
قیل تنغلم اننکا کوب نعمت بیلا	یارلیقادیم سنی من رحمت بیلا
یا الله العالمین ایمدی بولدم	تق بیر قیلب بارچامیز قلدروق ندم
حضرتنکدین تیلانو کیلدوک تموغ	رحمتنک دین بزنی قایتاردا قوتوروغ
کیم ایردوک عصمتنکدین بی نوا	لطف برلا بزکا قیل رحمت عطا
رحمتنک برلا بولدوق ایشلاریم تمام	رحمت اینتکیل بارچامیزغا والسلام

ار تموغ خانلار ایچرا انامدار	کیم ایروراسیز دنیا ایچرا کامکار
قهر برلا اوشمانکیز بیندر اوش	لطف برلا دوستلارینکیز تنزل اوش
راحت ایچرا ایلدا اولکسا بولدی قموغ	ایمدی تینگز دنیادا ایکجک اولوغ

*25а кәгазь*



اوشبو سیزنینک بولدی جهان ای پادشاه سیزگا بولدی مشرق و مغرب بارچا سپاه
مشرق و مغرب تمومی ایمدی اوش خلق تابع بارچه لاری ایمدی خوش
خوش مشرف بولدی اوشبو روی زمین بولغالی سیزگا سعادت همنشین
کوب یشانکیز دولت ایچنده مدام عمر ینکیز بولسون جهانده مستدام
کوکلونکیز تیلادین برسون الله ایرتا کیچه سیزگا حق بولسون پناه
اوتوتاریم سیزگا اوش شاه جهان دولت ایچنده یشانکیز کوب زمان
اتنکیزغه نظم قیلغانیم کتاب ختم قیلدیم آی من توزکی بیساب
تیکما بر بیتی اوپیدور بر سوزی خوش سوزلاری وعظ نصیحت ایرور اوش
اوقیغان همه قیلیب کشیلار انکلاغای بو ضعیف بیچاره قولنی تا انکلاغای
تیکما ایردین جمیع قیلیب سوزلارین مونا کورکوزدوم معانی دیوانلارین
ترجمه قیلیب پارسی تیلیدین اوشتق نظم قیلدیم توزکی تیلنچه ایریکیت
تیل تاک ایسب کیچا اوشبو روزگار انبیادین قالغان بو سوزلار یادگار
خان نما قیلغان دعا ایمدی اوکوش دعا معنی انکلاب تا بسا اول سوزدین صفا
خان دعاسی بودور کان تیبل لار اوزی واجب ایرور دنیاده ایللار ازون ا
کیم همیشه خان نما قیلغایلار دعا توبون کون ایفان تموغلاری شفا
نچه اکم

25б кәгазь

نیچا کیم بولسا جهاندا بو کتاب      خانغه بولغای دایما الفیل ثواب

تا کیهان بر قول دعا سین اول کریم      مستجاب ایتکای کمانسیز اول حکیم

اول دعا بیلا بولوب اش لار تمام      دولت ایچرا کوب یشاغای شاه مرام

ایمدی اوش وصف حالیم ایتادیم      بیر تیلاکیم بار آنی یاد ایتادیم

چون سینادیم ایدی سا دنیا ایشی      بیلدیم اینگ فتنه تشویشی

بی وفا ایمیش بو دنیا انگلادیم      الم کوب ایمیش جفاسی تانگلادیم

ای تانگلاب اولتورور دانا کیهان      خاطریم غمانتوشی فکرت اول زمان

کیم مبارک اوردوغه بارسام اوزوم      خان نینگ قوتلوغ یوزین کورسا کوزوم

اولدم ایچرا کوب دعا قیلغاسا ایدیم      یاد ایلیقیم سوزین ایتقای ایدیم

قیلغای ایدی یادی قاب منکا نظر      قایدا بولغای ایدی ایشیم معتبر

بنکا ایدی تیلاکیم بار جان دان      کیم عنایت قیلسا اول شاه جهان

ی دم قیلادیم کیم کوچوم یوق تورور دریغ      کیم ایدور مفلس لیک ایرکابس قتیغ

خانغه لایق تاج نا ایلسام یوق بولاک      اوردوغه بارمغیم قوت کراک

جون بو فکرت ایچرا قالدیم بیر زمان      حق تعالی لطف قیلدی تا کیهان

قیلدی منکا بو کونکلوم شحیح غمناک      کیم اینینگ کیم بیلا تورور دایم کتاب

*26а кәгазь*

حال تیلیب الامنکا ایقان سوزنی | بو ایردور منکا ایدی اول اوزنی

کیم ایاد دورویش مسکین دردناک | غصه بیرلا قیلما اوزونکنی هلاک

تصنیف ایتکیل توزی تیلینچه بر کتاب | پادشاه ایتیو آنی خوش بیساب

کیم سلیمانینکلیغ ایردور حضرتی | مستدام بولسون جهانده دولتی

هیچ نیما کا احتیاجی یوق تورور | خدمتنا بارچاسی انوق تورور

دنیا بیرو لیکا کورلانماد کوزینا | سن قمو رسقا یکلیغ ایمدی اوزینا

اول کتابنک اد تو خوب ایز نمیل روا | رحیم قیلغا کیم شاهنشاه جهان

رحمی بیرلا اشینک بولغای تمام | رحمت ایتکای سن همیشه والسلام

جون کونکول شیخی سوزنی تیکلادیم | ی ابشارته قیلدی ایسا انکلادیم

قن نمو دین بولدی خلاص اول کونکول | عاشقانه سوزنی قیلدیم قبول

آلدیم ایلکیم کا قلمنی اول زمان | تیلکلای کیم کیلی کونکول دینار روا

بیتیو باشلادیم اول ساعت قونغ | عشق بیرلا تنکلار کیچک ادلونغ

بر حکایت قیلادیم سیز کا بوروم | نقش ایتار کا غمزه اوزرا آی قلم

بر حکایت قیلادیم عالم جانی | یقان ایرماز کوین تینکلانکیز آنی

راوی

*26б кәгазь*

راوی لار آی روایت قیلور اوش صدق بیله اشتینک بیر جادو ایش

داود اوغلی اول سلیمان حق رسول بیک لارنی یغدی بیر کون بارچا اول

اوزی نینک اول کون وزیر لاری بیله طوی تویلار دیب قیلیب بارچا انکا خبر

تیکما بیک لار و وزیر لار کیلدیلار اول زمانه اول اولوغ طوی قیلدیلار

ایل اول کیلدیلار قوتی غیلیب تیکما بیر لطیف تیکیش آلیب صح

تورلوک تانکسوق کوب تیکیش کیلتور تیلماس اوز قدرینی بیلدوردیلار

بیک وزیر لار اولتوردیلار زمانه اول اولوغ ملالار اسمنا انکا کیم

کیلدی بیر تورغای ساق بیر ینکنا الیب بیر سارنیچق بوتین آغزینه آلیب

ایدی بیکم بولسون مبارک اوشبو طوی حاصل ایتو بیلمادیم هیچ بیلیگی قوی

ای سلیمان اوشبو ایرور تابقانیم جهد بیر لا طوغان حاصل قیلغانیم

دنیادا ایرور قناعت تاک ایشیم حالیم کورا ایرور اوش تیکیشیم

اول نبی الله سلیمان ایر کیت چون که تورغای سوزین انکلادی ایش

عذرینی لطف بیله قیلدی قبول بو ملالار تورغای سوزنی هیچ ملول

اول دم اوق تورغای اول سیوندی یاری تورغای ایدی کا باریب ایرغادی

من تعی ایمدی پادشاه جهان بولدوم اول تورغای منینک لیک بولسانک

*27а кәгазь*



حضرتینکا یاری لقیم بیلدوروب — اوش مونا یا بفان تیکشی کیلتوروب
حضرتینکیز اول سلیمان تاک ایرور — دنیانینک تمانکوق لاری لایتورور
اوش کوچوم یتار چاپتورکیم کتاب — نظم قیلدیم پادشاه اتین آفتاب
لطفینکیز دین قیلسانکیز ای قبول — خستہ کونکلوم بولماغای ایردی ملول
قیلغان ابراهیم جان بار نیجاهن رحما — ایغای ابراهیم جان اول برلا آشنا
ارکریم پاک ذاتاک کسرت کا ر — حضرتینکا ایالبار و رفیق محمد یار
تنکری فضلی برلا بولدی بو تمام — بیلکنک ایمدی مونی سیز خاص عام
نه قوزی یوز قرق سیکزدا تاریخ تزدا — کتابیم آخر ایله بولدی محی ر
اشیت ای معتبر خانالار عزخای — سیکیز یوز ایلیک بش بیت ایدی سانا
الهی بو کتاب بولغای مبارک — بحق نحما و اخلاص و تتبارک
توکلنا على الله امّا نا — توجهنا الى الحق ز ما نا
اوشال کون کیم سوزلا ایتیم بو تقریر — خیالیم نقش بغلاب اوشبو تحریر
کونکول کنجی آنجا بار ایدی کنج — نه جا کیملار قیلغان ابراهیم فرنج
نه معنی نمانکیز نه سوز کا فکر — نه معنی دین نه سوز دین اوزکا فکری
بولوب مغرور اوی کنجینه سینه — نه محتاج اوزکالارنینک منتبه سینه

ذیل

27б кәгазь

ولی چون حکم ایدی شاه جهاندین — که قیلغاسن ترجمه اول ربّ جهاندین

توری رسم شه بیلا بی تکلّف — ضرورت مونچه لیق قیلدیم تصرّف

توقع اولدور ارباب هنردین — کم چون فیض السالار بو مختصردین

سفینه ایلار محبّ بی نوای — دعا بیلا سوزوریکا ایلار آی

ینه حرفیم استیم باری بخشی لاردین — مغول سوزی بیلالای بخشی لاردین

کیم الفاظیم نی تغییر ایتماکایلار — تصرّف بیرلا اسرا ایتماکایلار

تاریخ منک یتمش توقوزدا ایردی بحق — کی نقش ایتیم بو منشور صحیح

اوقونغا بنکا الا الهی — مبارک قیل بو تنبیح پادشاهی

رمضانی نینک ادف برسی — که بولدی بو کتب نینک انتهاسی

فقیر کیم جفا بیلا ابتر — دعای اهل حال لاردین امیدی

تمام بولدی نور صدور کتابی — نه دور فقیر یازغوچی نینک گناهی

بایعی از مشتری بها خواهد — کاتبی از نظر دعا خواهد

تمام

28а кәгазь

# ЮГАРЫ КУРСА КУЛЪЯЗМАСЫНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

«Нуры содур» поэмасы теркәлгән бу күчермәнең кыскача һәм гомуми тасвирламасы кереш мәкаләдә язылды. Монда исә тәфсиллерәк һәм керештә әйтелмәгән мәгълүматлар урын алды.

Кулъязма җыентыкның текстлары саргылт, 16,5х20,5 см зурлыгындагы Россия кәгазенә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәстәгълик-шикәстә төрендә теркәлгән. Һәр битендәге текст уртача 15 парлы шигъри юл күләмендә, 12х16 (16,5) см зурлыгындагы мәйданда ике багана итеп язылган.

Үзендә төгәл датасы, шулай ук кайда һәм кем тарафыннан күчерелгәнлеге күрсәтелмәгән. 6–10, 13–16, 19, 23 һәм 26 нчы кәгазьләрендәге филигрань өлешләрендә вак боҗралар белән каймаланган түгәрәк эчендә «ЕМФ» хәрефләренең катлаулы вензеле төшерелгән. Филиграньнәр турындагы махсус белешмәдә аның 1739 елда Россиядә эшләнгән кәгазь булуы күрсәтелгән[1].

Җыентыкның гомуми күләме 29 кәгазьне тәшкил итә. Шуларның 1а–28а кәгазьләрендә шагыйрь Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы язылган. Әсәрнең башка күчермәләре белән чагыштырганда, текстында хаталары азрак.

28б кәгазендә билгесез шигъри әсәрнең ике бәйте, Корбан чалганда укыла торган, гарәп телендәге дога теркәлгән. 29а–29б кәгазьләрендә Коръән аятьләреннән өземтәләр һәм гарәп телендәге догалар язылган.

Кулъязманың төбе ак җеп белән тегелгән.

Гомуми сакланышы уртача диярлек. 24 нче кәгазе төбеннән тулаем аерылган. 6а, 7а, 8а, 9а, 10а, 11а, 12б, 13б, 14б, 15б, 16б, 18а, 19а–20б, 21б, 22б, 24б, 25б, 26а, 27а, 28б кәгазьләре төбендә ачык

[1] Клепиков С.А. Филиграни и штемпели на бумаге русского и иностранного производства XVII–XX века. – М: изд-во Всесоюзной книжной палаты, 1959. – С. 48 (№245).

яшел төстәге (XVIII гасыр ахырына нисбәтле) кәгазьне тасмасыман кисеп ябыштырып реставрацияләнгән. Шулардан 10а, 13б, 19б кәгазьләрдә язу фрагментлары шәйләнә, 15б кәгазьдә карандаш белән «Бисмилләһи Рахмәнир-Рахим» дип теркәлгән. Беренче кәгазенең читләре шактый таушалган: 1а кәгазендәге тексттан барлык сүзләрен дә (түбәндәге юлын тулаем диярлек) танып булмый, 1б кәгазендәге тексты укыла, бары тик соңгы юлында берничә генә сүзе таныла. 2 нче һәм 3 нче кәгазьләрнең читләре таушалган булуы сәбәпле, берничә сүз өлешчә танылмый.

Кустодлар 6б кәгазеннән башкаларында һәммәсендә дә бар. Кустодлар кагыйдә буенча кәгазьнең «б» ягына язылырга тиеш булса да, 11а кәгазендә ялгыш теркәлгән.

Әсәр текстын күчерүче тарафыннан бүлек һәм бүлекчә исемнәрен язу өчен дип тәгаенләнеп, текст эчендә барлыгы 26 урын буш калдырылган. Алар: 1а, 1б, 2а, 3б, 4б, 5б, 6а, 7а, 7б, 8б, 9б, 11а, 12а, 13б, 14а, 15а, 16б, 17а, 18а, 19а, 19б, 20б (өске юлда һәм уртада, ягъни – 2 урында), 23б, 25а, 26б кәгазьләрдә. Китапның искәрмәләрендә әйтелгәнчә, кулъязманы күчергән кеше әлеге буш калдырылган урыннарга башка төстәге (кызыл) бүлек исемнәрен язып чыгарга тиеш булган[2]. Ләкин, ни сәбәптәндер, ул эш башкарылмыйча калган.

6б кәгазенең түбәнге өлешендә «Бисмилләһи Рахмәнир-Рахим» һәм поэманың беренче юлы – «Ходавәндә, белүрсән барчаны әсрар» язылып, шигъри юл сүзләре кырып чистартылган, аерым хәрефләре өлешчә танылa. Ягъни, бу кәгазенә әсәрнең башын язарга керешеп, ни сәбәптәндер, күчерүчене канәгатьләндермәгән.

Кулъязмадагы ялгыш язылган башка юллар һәм сүзләр, палеографик үзенчәлекләр поэма текстына карата бирелгән искәрмәләрдә күрсәтелде.

Күчермәдәге 5б, 11б, 14б, 23а кәгазьләрдә төп текст читенә чыгарып өстәмә сүзләр һәм кушымчалар язылган.

---

[2] Татар археографиясендә мондый очраклар бар. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 1790 елгы кәгазьгә теркәлгән бер күчермәсендә шундый ук хәлне – бүлек-фасыл исемнәренең язылмыйча, алар өчен буш урыннар калдырылганын күрәбез (Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «2644т» шифры белән саклана торган кулъязма).

11б кәгазнең сул як читендә кызыл кара белән «сезгә бирдүм» дигән гыйбарә теркәлгән. 13б кәгазенең сул як читендә текстның буеннан-буена кызыл төстәге кара белән сызылган.

Әсәрнең исеме 1а кәгазенең иң өстендә «Һәза китаб Нуры содур» дип язылган. Аннан югары өлешенә бераз соңрак (башка кул белән булса кирәк) «[Ошбу] китаб бән Мөхәммәдхәнәфиянең торур» дип теркәлгән. 15б кәгазьнең уң як читендә төп текстка каршы якка (асты өскә) таба башка кеше тарафыннан ачык төстәге көрән язу карасы белән «Кәтәбтү Габделхаликъ» дип теркәлгән.

«Нуры содур»ның 790 нчы бәйтеннән соң кулъязмада бу әсәрне элегрәк күчергән кеше тарафыннан үзгәртелгән икеюллык бар. Анда беренче юлында «Тарих мең йитмеш тукузда ирде һиж[рә]т» диелгән.

Һижри 1079 нчы ел һәм 792 нче бәйттә язылган 11 нче рамазан көне миладига күчергәндә 1669 елның 12 февраленә туры килә.

Поэма текстының иң ахырында колофоннарда языла торган, күчерүченең дога өмет итүе турындагы фарсы телендәге шигъри икеюллык та теркәлгән.

Кулъязмада кайбер юллар һәм аерым сүзләр хәрәкәләр белән язылган. Мәсәлән, 309 нчы бәйтнең беренче юлы тулаем хәрәкәләр белән теркәлгән. Хәрәкәләрнең булуы кайбер сүзләрнең дөрес укылышын ачыклау өчен аеруча әһәмиятле. Мәсәлән, хәрәкәсез язылган очракта «җиһан» дип укылуы күбрәк ихтимал булган сүз кулъязманың 2б кәгазендә (54 нче бәйттә) хәрәкәләр белән аерымачык «җәһан» дип теркәлгән. Кайбер сүзләрдә сузык авазны белдерә торган хәреф орфографик кагыйдә нигезендә үзе языларга тиеш булса да, хәрәкә белән генә белдерелгән. Мәсәлән, кулъязманың 1б кәгазендә «дәүләт» сүзенең «уау» хәрефе «дәл» өстендәге хәрәкә итеп кенә теркәлгән. Әсәрнең 93 нче икеюллыгында (4а кәгазьдә) «гадле» сүзенең соңгы хәрефе язылмыйча, ул «ләм» астындагы кәсрә хәрәкәсе итеп кенә күрсәтелгән. 467 нче бәйттәге «сүзене» дигәннең ахырындагы «е» хәрефе «нун» астындагы кәсрә хәрәкәсе белән белдерелгән. «Тәңре» сүзенең соңгы хәрефе дә «ра» астындагы кәсрә белән язылган (мәсәлән, 518 бәйт). Шулай ук 121 нче бәйттәге (5а кәгазьдә) «шаһа» сүзендәге ахыргы «а» хәрефе «һ» өстендәге фәтхә белән билгеләнгән. 692 нче бәйттәге «хәзрәте» сүзенең ахыргы хәрефе язылмыйча, «т» хәрефе өстендә «даммә» хәрәкәсе белән белдерелгән. Гомумән, кулъязманың һәр битендә

берничә сүзгә хәрәкәләр куелган. Ә аерым сүзләрдә хәрәкә куелмаган булса да, элеккерәк протографларда аның тәгаен булганлыгы аңлашыла. Мәсәлән, бу кулъязмадагы «әһеле» сүзенең ахыргы хәрефе язылмыйча, «әһел» дип кенә теркәлгән очраклар бар: 386, 435, 448 нче икеюллыклардагы «мәҗлес әһле», «вафа әһле», «мәхәллә әһле» сүзләрендә. Шуңа охшаш тагын бер үзенчәлек – сүздә язылырга тиешле «уау» хәрефе күп очракта хәрәкә кебек кенә теркәлгән. Мәсәлән, «ирер» сүзенең кулъязмада «уау» белән язылган урыннарын бу китапта «ирүр» дип, ә «уау» язылмыйча, хәрәкә рәвешендә теркәлгәннәрен «ирер» дип бирдек.

Гомумән, «Нуры содур»ның башлангыч протографлары хәрәкәләр белән язылганнан калган үзенчәлекләр шактый. Сүзләрнең ахырларындагы «э» һәм «ы» авазлары элегрәк кәсрә хәрәкәсе белән белдерелгән. Ә күчермәләрнең кайберләрендә кәсрә куелмаган һәм «йа» хәрефе дә язылмаган. Югары Курса кулъязмасы – нәкъ шундыйларның берсе. Моңа дәлил итеп дистәдән артык мисал китерергә мөмкин. Мәсәлән, кайберләре: 107, 210, 749 нчы бәйтләрдәге «сүзене», 166 нчы бәйттәге «куйларыны», 278 нче бәйттәге «суыны», 395 нче бәйттәге «сүзләрене», 389 нчы бәйттәге «вәзире», 733 нче бәйттәге «йөзене» дип укылырга тиешле сүзләрнең ахыргы хәрефләре кулъязмада теркәлмәгән.

Әсәрнең элекке протографларында «нун» (н) хәрефенең шикәстә төрендәгечә авыш сызыксыман булып, сул як очы бераз түбәнгә төшебрәк язылышын кулъязма күчерүчеләр «нун» хәрефенә «йа» ялганган – ягъни, «-ны», «-не» кушымчалары дип кабул итүдән килеп чыккан ялгыш язылышлар да бар. Югары Курса нөсхәсендә, мәсәлән, 152 нче бәйттә «мәгънәсене», 405 нче бәйттәге «сүзене», 414 нче бәйттәге «солтаны», 473 нче бәйттәге «сүзене», 642 нче бәйттәге «төнене» дип язылган гыйбарәләрнең ахырларындагы «ы» һәм «е» хәрефләре артык.

Татар палеографиясенә хас күренешләрнең тагын берсе – бер сүздә янәшә килгән хәрефләрнең бер яки ике нокталарын бергә җыеп, өч нокта итеп бирү бу кулъязмада да бар. Мәсәлән, «белүр», «белә» һәм «берлә» сүзләрендәге беренче һәм икенче хәрефләрнең нокталары күбесенчә өч нокта рәвешендә берләштереп язылган. (Мәсәлән, 310, 334, 375, 387, 421, 464, 568 нче бәйтләрдәге сүзләрнең язылышында шундыйларны күрергә мөмкин). Шул сәбәпле, «берлә» сүзенең «перлә» дип язылганга охшаган очра-

клары бар. «Нуры содур»ның башка кульъязма күчермәләренә дә нокталарны шулай туплап язу хасиятенә күрә, андый язылыш, күрәсең, авторның үз кульъязмасыннан ук килгәндер дияргә мөмкин. Иҗат ителгән вакытлары элеккерәк чорларга караган әсәрләрнең күчермәләрендә андый язылыш еш очрый.

Кульъязманы күчергән кеше «ра» һәм «за» хәрефләрен, сүз башындагы «гайн» хәрефенең язылышларын үзенчәлекле итеп теркәгән. Сүз ахырында кушылып язылган «мим» хәрефенең «койрыгы» бик кыска. «Дәл», «нун» һәм «йа» хәрефләре шикәстә төрендәгечә. Өч нокталы «уау» хәрефе ике ягыннан да тоташтырып язылган, мәсәлән, «су» сүзе ике «уау» белән язылып, уртадагысы шундый рәвешле. Сүз башындагы «э» авазын белдерү өчен борынгы чор текстларына хас булганча, «әлиф» һәм нокталарсыз «йа» хәрефенең төп өлеше теркәлгән (мәсәлән, «эчеб», «эчендә» кебек сүзләрдә).

Гадәттә даммә хәрәкәсе рәвешендә языла торган кыска «вү» кульъязманың кайбер урыннарында «вә» буларак теркәлгән.

Мондый палеографик хасиятләрдән тыш, әлбәттә, бу күчермәдә дә орфографик хаталар, сүзләрнең ахыргы хәрефләренең язылмыйча калуы кебек, һәрбер кульъязма истәлектәгечә, текст кимчелекләре бар.

Күчерүче тарафыннан ялгыш язылып, кыска гына итеп сызылган, яңадан дөрес вариантны кабатлаган урыннары шактый. Кайбер очракларда хаталы язылышлар сызылмыйча да калган. Татар кульъязмаларына хас булган имля тотрыксызлыгы бу нөсхәдә дә чагыла. Мәсәлән, «б/п», «җ/ч» хәрефләренең үзара бутап язылышлары: «парсы» сүзе «барсы» һәм «пәнд» сүзе «бәнд» дип, 198 һәм 199 нчы бәйтләрдәге бер үк сүз ике төрле итеп: «бурычлуг» һәм «бурыҗлуг» дип теркәлгән. Шулай ук «чайан» сүзе «җайан», «җәң» сүзе «чәң», «җәван» сүзе «чәван», «хаҗәт» сүзе «хачәт» дип язылган һ.б.

Төшеп калган хәрефләрне күчерүче үзе үк өстәгән очракларда, андый хәрефләр сүзнең өстенә кечкенә генә итеп куелган.

«Нәүширван» исеменең бу кульъязмада «Нушин рәван» дип хаталы теркәлгән урыннары бар. Бу исә нәкъ шушы Югары Курса кульъязмасында гына түгел, ә «Нуры содур»ның бүтән күчермәләрендә дә шулай. Гомумән, андый ялгыш язылган сүзләрнең бер өлеше аерым бер нөсхәгә генә хас булмыйча, бүтәннәрендә дә бар.

Әсәр текстындагы «сәнгате» дигән сүз, шулай ук бу кульязмада (321, 423 бәйтләрдә) һәм бүтән күчермәләрдә дә (мәсәлән, СПб-2, Олы Мәңгәр, Урта Шөн, Сарман) – «сәнгате» дип язылган, ә кайберләрендә исә (СПб-1, Ижевск кульязмаларында) «сыйфаты» диелгән. Бу ике сүзнең дә гарәп хәрефләре белән язылышлары бик охшаш, шунлыктан күчерүчеләр үзләре таныганча теркәгәннәр. Контексттагы мәгънә өчен әлеге сүзләр икесе дә яраклы.

Татар кульязмаларында кайбер сүзләрнең яки шигъри юлларның урыннары ялгыш язылган очракларда күчерүче үзе үк дөресли торган махсус ишарә-тамгалар куйган[3]. Югары Курса кульязмасында да 314, 371, 509 нчы бәйтләрдә шундый төзәтмәләр бар. Аларны «Нуры содур»ның бүтән күчермәләрендә дә күрдек, мәсәлән, андыйлар СПб-2 нөсхәсенең берничә урынында теркәлгән.

7б кәгазьнең ахыргы юлы белән 8а кәгазьдәге беренче юллары ялгыш язылып, күчерүче яңадан дөресләп кабатлаган.

Тулы текстлы булуы ягыннан татар әдәбияты тарихы өчен аеруча кыйммәтле бу истәлекне Татарстан Республикасы Милли китапханәсе хезмәткәрләренә Арча районында үткәргән археографик экспедиция вакытында Югары Курса авылында Лилия Вахитова 2024 елның 17 июль көнендә тапшырган.

Кульязма ядкяр хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «8667т» шифры белән саклана.

Татар палеографиясенә багышланган хезмәттә бу кульязманың кайбер үзенчәлекләре күрсәтелде һәм бер битенең (16а кәгазенең) фотокүчермәсе бирелде[4].

Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 55.

2. Загидуллин А. Сенсация или очередная уникальная находка // Китапханә. – 2024. – №2. – С. 32–33.

[3] Мондый төзәтмәләр турында язылды: Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кульязмаларының палеографик үзенчәлекләре. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2024. – Б. 56–57.

[4] Шунда ук. – Б. 172, 173, 175.

# СҮЗЛЕК

*абдәст* – тәһарәт, юыну
*абе зөлял* – саф чишмә суы
*абе руй* – абруй, йөз суы
*авазә* – җыр, көй, дан, хәбәр
*агыр* – авыр
*агяһ* – белеп торучы, хәбәрдар
*азар* – шелтә, кыерсыту
*азган-у-йазган* – азган һәм язган
*азрылыб* – аерылып
*айайым, айайын* – әйтим
*айамадин* – аямыйча, аямастан
*айган; айгыл* – әйткән; әйт
*айдын* – якты
*аймаз ирсәң* – әйтмәсәң
*ай-у-йыл* – ай һәм ел
*алгусы* – аласы, алачагы
*алчак* – мәрхәмәтле
*алындин* – алдыннан
*аман* – иминлек, тынычлык
*андак* – шундый
*андин* – аннан
*анча* – күпме, ничаклы
*аныңлә* – аның белән
*аңлагай* – аңлар
*аргуздың* – ардырдың
*артар* – артыр, ишәер
*арыг* – саф, чиста
*арытур* – чистартыр
*асайыш* – тынычлык, иминлек, рәхәтлек
*асан* – җиңел, җайлы
*ат* – исем
*атлыг* – атлы, җайдак
*аулайу* – аулап
*ачиг* – ачы
*ачкунча, ачгунча* – ачканчы

*ашөфтә* – борчылган, борчулы

*әбйат* – бәйтләр, шигъри юллар
*әгда ләрзән* – дошманнар тетрәр
*әда* – үтәү, башкару, түләү
*әҗдад* – тырышлык
*әйде; әйтәйен; әйтәлем* – әйтте; әйтим; әйтик
*әл-әман, әман* – иминлек
*әл-гәҗәб* – гаҗәп, гаҗәеп
*әлфаз* – сүзләр
*әмирел-мөэминин* – мөэминнәрнең юлбашчысы, патшасы
*әмн-ү-аман* – куркынычсызлык, тынычлык
*әнбийа* – пәйгамбәрләр
*әндам* – тән әгъзалары
*әндишә* – уй, фикер
*әрбабы һөнәр* – һөнәр ияләре
*әрмаған* – бүләк, ерактан китерелгән бүләк
*әсаләт* – асыл затлылык, аксөяклек
*әсиғ* – файда, табыш
*әсрар* – серләр
*әсри, әсрү* – бик, бик нык, бик күп
*әсхабе кәһф* – мәгарә хуҗалары
*әхваль* – хәлләр
*әһле дил* – акыл иясе, суфи
*әһле иман* – иман әһелләре, мөселманнар
*әшһәде әл лә иләһә илләл-Лаһи* – бер Аллаһтан башка илаһи көч юклыгына шаһитлек итәм

*баб* – бүлек
*бағ; бағы Ирәм* – бакча; оҗмах бакчасы
*бадийә* – сахра, чүл
*баз* – лачын
*бақар; бақалым* – күрер; күз салыйм әле
*бақи* – мәңгелек
*Бари* – һәр нәрсәне юктан бар итүче (Аллаһы Тәгалә)
*басруқ* – өрлек
*башынға кидеребдер таҗе рисаләт* – башына пәйгамбәрлек таҗын кигергән
*бәндә* – кол
*бәни Исраил* – исраиллеләр, яһүд халкы
*бәргөзидә* – сайланган, сайлап алынган
*бәри* – бире

*бәсе, бәси* – бик, күп, күпләр

*бәхаққ, бәхаққы* – хакына, өчен

*бәхаққы абруйи әүляде адәм* – адәм балаларының абруйлары хакына

*бәхтияр* – бәхетле

*бәһатур* – баһадир

*белүрсән* – беләсең

*берәгү* – бирәү

*берин-берин* – берәм-берәм

*бивафа* – ышанычсыз, сүзендә тормаучы

*биғәдәд* – хисапсыз, күп

*биғәйб* – гөнаһсыз

*бигиран* – кыйммәт, бәясез

*бигөман* – шиксез, шөбһәсез

*бинәва* – бәхетсез, ярдәмсез, ярлы, фәкыйрь

*бинәзыйр* – тиңсез, охшашсыз

*бинийаз* – ирекле, мохтаҗ түгел

*бираһ* – адашкан, юлдан язган

*бисәр-ү-саман* – мескен, ярдәмчесез

*Бисмилләһи Рахмәнир-Рахим* – мәрхәмәтле, рәхимле Аллаһының исеме белән

*битәкәллеф* – тәкәллефсез, оялмыйча

*битейү, битедүм, битеб* – язарга, яздым, язып

*бихәйалық* – оятсызлык

*биһишт; биһишти җавидан; биһишт-ү-хур* – җәннәт; мәңгелек оҗмах; оҗмах һәм хурлар

*болақ* – чишмә

*борадәр* – кардәш, туган

*бостан* – бакча

*бөйлә* – шулай, шулай итеп

*бөтмәде; бөтмеш* – үсмәде; үскән

*булғай; булғам; булмағай; булмағынча* – булыр; булыйм; булмас; булмыйча

*булур* – табар

*бүхәк* – баш ию, башны җиргә тигерү

*важиб* – үтәлергә тиешле дини эш

*вақиф* – аңлаучы

*васфы халь* – хәлнең сыйфаты, эшнең торышы

*васыф* – сыйфат, билге

*вафа* – сүздә тору, вәгъдәне үтәү, эчкерсезлек

*вафадар* – сүзендә торучы

*вәбаль* – гөнаһ

*вәли* – изге, әүлия

*вәли, вәликин* – ләкин, вә ләкин

*«Вә мусаддиқән лима бәйнә йәдәйһи» (Коръән, «Әл-Маидә» сүрәсе, 46 нчы аять)* – хаклыгын раслау өчен

*вәрәқ* – язу кәгазьләре

*вәс-сәлам* – һәм сәлам, тәмам

*восле* – күрешүе

*вөҗүд* – яшәеш, барлык

*вөзу* – тәһарәт алу

*ғази* – дин өчен сугышучы, җиңүче

*ғақибәт* – ниһаять, нәтиҗәдә

*ғақил; ғақиланә* – акыллы; акыл белән

*ғақл-у-ус; ғақлы тәмиз* – акыл һәм аң; саф акыллы

*Ғалим* – бар нәрсәне яхшы белүче (Аллаһы Тәгалә)

*Ғафир-у-Ғаффар* – гөнаһ-хаталарны ярлыкаучы, гафу итүче (Аллаһы Тәгалә)

*Ғафу, Ғафур* – гөнаһларны кичерүче, ярлыкаучы, үтә мәрхәмәтле (Аллаһы Тәгалә)

*ғәза, ғәзавәт, ғәзат* – изге сугыш, һөҗүм итү

*ғәйан* – ачык

*ғәқрәб* – чаян

*ғәләйһиссәлам* – аңа Аллаһының сәламнәре булсын

*ғәләфдин төзәнеб* – үлән белән бизәлеп, яшеллеккә күмелеп

*«Ғәммә»* – Коръәннең «Ән-Нәбә» сүрәсе

*гәнҗ билик* – яшь егет

*гәнҗ; гәнҗханә* – хәзинә; хәзинә йорты

*гәнҗе хәбәр* – кыйммәтле хәбәр

*гәнҗинә; гәнҗ-ү-дәүләт* – хәзинә, китапханә; хәзинә һәм байлык

*Ғәни* – бай, бирү белән байлыгы кимеми торган зат (Аллаһы Тәгалә)

*ғәни* – бай

*гәр* – әгәр

*ғәреқ* – бату

*ғәрз; ғәрыз итеб* – белдереп; аңлатып

*Ғәрш Изисе* – күк иясе, Аллаһ

*ғәта* – бүләк

*ғәһд* – вәгъдә, ант, йөкләмә

*ғиваз* – бүләк

*гида, гидай* – фәкыйрь, бичара

*ғиззәт* – кадер, хөрмәт

*гизз-у-дәүләт* – шөһрәт һәм байлык
*гизләде* – яшерде, сиздермәде
*гимарәт* – төзек, бөтен
*гинайәт* – ярдәм, кайгыртучанлык
*гисйан* – баш тарту, каршылык күрсәтү, гөнаһ кылу
*гитаб* – шелтәләп, биткә бәреп әйтү
*гозр-у-хаһым* – ялваруым һәм теләгем
*голям* – хезмәтче, кол
*госса* – кайгы
*гөзләт* – ялгызлыкка бирелү
*гөқба* – ахирәт, мәңгелек дөнья
*гөлшан* – гөлбакча
*гөнаһикяр (гөнаһкяр)* – гөнаһлы

*дад* – гаделлек, турылык, гадел хөкем
*даимән* – даими, туктаусыз
*данә* – энҗе
*дарелбәқа* – мәңгелек дөнья
*дарес-сәлам* – оҗмах
*дәга, дәгәл* – ялган, алдау
*дәм* – вакыт, мизгел
*дәмаг* – борын
*дәмбәдәм* – һәрвакыт, бертуктаусыз
*дәнке* – тәңкә
*дәрвазә* – капка
*дәрвишанә* – дәрвишләрчә
*дәрд; дәрде фирқәт* – авыру; аерылу сагышы
*дәрднак* – авыру, газапланучы
*дәриг* – аяныч, кызганыч, үкенеч
*дәрман* – дәва
*дәр мәдхе падишаһи зәман вәли ма даимән әфзале әс-сәлятыйнез-зәмани гәдл* – замананың даими патшасына һәм иң гадел солтанына мактаулар
*дәрмийан* – уртада, арадашчы
*дәр-хастем* – сорау, таләп итү
*дәфег* – бетерү, кире кайтару
*дивүт (дәват)* – кара савыты
*дидар* – күрешү, очрашу
*дин-ү-дөнйа* – дин һәм дөнья
*дөзәхи* – тәмуг иясе
*дөрр, дөрр-данә; дөрр-ү-җәүһәр* – энҗе, мәрҗән; энҗе һәм җәүһәр
*ду галәм* – ике дөнья

*җай* – урын
*җам* – касә, чынаяк
*җамиг* – җыючы
*җан-у-дил* – җан һәм күңел
*җәван* – егет
*җәзирә* – утрау
*җәмг итү* – җыю, туплау
*җәң* – сугыш, яу
*җәһан* – җиһан, дөнья
*җәһед* – тырышлык
*җәһер* – кычкырып, тавыш белән
*җисм-ү-җан* – җисем һәм җан
*җиһан-у-җан* – дөнья һәм җан
*җиһәт* – сәбәп, максат, юнәлеш
*җөда* – аерылу
*җөрм-ү-гөнаһ* – язык һәм гөнаһ

*зарб; зарбенгә* – сугу; оруына
*зар-у-мәлүл* – зарлы һәм сагышлы
*зафәр* – җиңү
*заһид* – суфи, дәрвиш
*зәррә* – бөртек
*зәхмене* – ярасын, җәрәхәтен
*зийад, зийадә, зийадат* – артык, бик күп
*зийанкяр* – зыянлы, зарарлы
*зиндә* – җанлы
*зир-ү-зөбәр* – асты өскә килү, буталыш
*зольме гөдван* – дошманлык золымы
*Зөлҗәлал* – бөеклек иясе (Аллаһы Тәгалә)
*зыйлли Рабб* – Аллаһ күләгәсе

*ибне* – улы
*ив (эв)* – өй
*игәсе* – иясе
*игелүр* – ялгышыр
*игри* – кыеш, бөгелгән, икейөзле, ялган
*игтиқад* – ышану, инану
*игтимад* – ышаныч, таяныч
*иҗабәт* – кабул итү
*изгыл; изыды* – юнәлт; чакырды
*изылмыш* – сасыган
*иқбаль* – бәхет

*иклим* – климат, борынгыча бүленештә экватордан котыпка кадәр җиде икълим күзалланган

*ил-азак; илкем* – кул-аяк; кулым

*илгәрү* – элгәре, алдан

*иллә* – бик тә, бигрәк тә

*иллек* – илле

*илтәйен* – илтим

*ил-ү-олус* – ил һәм олыс

*Иляһел-галәмин* – ике дөнья хуҗасы (Аллаһы Тәгалә)

*Иляһи, чиһ Кәрим дигәр тудани* – Илаһым, синнән башка юмарт кем бар тагын

*имаме әнбийа* – пәйгамбәрләр юлбашчысы

*имгәнеп; имгәтте* – мәшәкатьләнеп; бимазалады

*имди* – инде

*ингам* – бүләк, хөрмәт

*«Иннә Аллаһә йәэмүрү бил-гәдли вәл-ихсани» (Коръән, «Ән-Нәхл» сүрәсе, 90 нчы аятьтән)* – һичшиксез, Аллаһ гадел булырга, изгелек кылырга әмер итә

*«Иннә Аллаһә кянә гафуән гафурән» (Коръән, «Ән-Ниса» сүрәсе, 43 нче аятьтән)* – һичшиксез, Аллаһ – кичерүче, гафу итүче

*инсан; инс-ү-җан* – кеше; кешеләр һәм җаннар

*интиһа* – ахыр, бетү

*инче* – хезмәтче

*ирде; иркән* – иде; икән

*ирдәм* – һөнәр

*ирер (ирүр); ирмәз* – булыр; булмас

*иркәнсән* – икәнсең

*ирүрсән һәмишәи хәйат* – син мәңге тере

*исергәб* – кызганып

*ислам* – буйсыну

*истәйү* – теләп, эзләп

*иткел* – ит, үтә, башкар

*«Ихлас»* – Коръәннең «Әл-Ихлас» сүрәсе

*ихсан* – ярдәм итү, игелек кылу

*иһмаль* – гамьсезлек, санлашмау, ваемсызлык

*ичрә* – эчендә

*ишеткел* – ишет

*йа* – җәя

*«Йа, әййуһа әл-ләзинә әмәну әсбиру вә сабиру вә рабиту вә әттәку Аллаһә ләгалләкүм түфлихүнә» (Коръән, «Әлү Гыймран» сүрәсе, 200 нче аятьтән)* – И, иман китерүчеләр! Сабыр итегез, сабырлыкта ярышыгыз

шыгыз, атларыгызны бәйдә тотып, чикләрне саклагыз һәм Аллаһтан куркыгыз, бәлки, уңышка ирешерсез

*йаги* – дошман

*йагмады; йагса* – яумады; яуса

*йадагай* – аптырады

*йагмур* – яңгыр

*йад; йадегяр (йадкяр)* – искә алу; ядкяр, истәлек

*йазгучы* – язучы, күчерүче

*йазуқлуқ* – гөнаһлы

*йаз-у-қыш* – яз һәм кыш

*йазы* – кыр, болын, дала

*йазық* – гөнаһ

*йай* – җәй

*йақин* – анык белү, ышану

*йангай; йанмага* – янар; янарга

*йаңлиг* – кебек, шикелле, чаклы, хәтле

*йаңылса* – ялгышса

*йар* – иптәш

*йаратганым* – яратканым, юктан бар итүчем (Илаһым)

*йаре ләтыйф* – мөлаем дус

*йари; йаричы* – ярдәм; ярдәмче

*йарлыгаб* – шәфкать күрсәтеп

*йару* – як, тараф

*йарыр; йарыйур* – яктырыр; нурланыр

*йәшәгай* – яшәр

*йеб* – җеп, бау

*йийгды; йийгыб; йийгылыб; йийгыңыз* – җыйды; җыеп; җыелып; җыегыз

*йите* – җиде

*йиткел* – җит, ireш

*йоқлайурда* – йоклаганда

*йөк булалым* – җаваплы булабыз

*йөрегәй; йөрегел* – йөрер; бар

*йуйгучы* – җуючы, юкка чыгаручы

*йуқсуз* – фәкыйрь, ярлы

*йусунлуг (йусунлуқ)* – рәвешле, тәртипле, юньле

*йызыгы* – исе

*қадир* – көчле, кодрәтле

*Қадир* – һәр нәрсәгә көче җиткән зат (Аллаһы Тәгалә)

*қайа* – кыя, ташлы тау

*қайгу* – кайгылы

*қайу* – кайсы
*қақар* – кагар
*қалә Аллаһу Тәгалә* – Аллаһы Тәгалә әйтте
*қалә гәләйһиссәлам* – пәйгамбәр әйтте
*қалгайму* – калырмы
*қаль-у-қыйль* – имеш-мимеш, шау-шу
*қарарды* – каралды
*қарисун* – картайсын
*қатынгә* – катына, янына
*қач; бер қач* – күпме; берничә
*қәдәх* – савыт, бокал
*қәзгу* – кайгы
*қәйра* – тагын, янә, яңадан
*кәмә* – көймә
*қәмуг, қәму* – бөтен, барлык, тулаем
*кәрамәт* – затлылык, изгелек, юмартлык
*кәрәк* – кирәк
*кәрәм* – юмартлык, киң күңеллелек
*Кәрдигяр* – бар итүче, Аллаһ
*Кәрим* – Юмарт (Аллаһы Тәгаләнең мактаулы исеме)
*қәср* – сарай, пулат
*қәтле* – үтерергә
*қәтрә* – тамчы
*қәтыг, қәтиг* – каты, көчле
*қәһр, қәһер* – җиңү, ачулану
*кем ирсә* – кеше, берәү
*кермәгәй* – кермәс
*килтүр* – китер
*кичүргел* – кичер, гафу ит
*қолақ тотгыл* – колак тот, тыңла
*қорар* – корыр
*қоруг, қорыг* – коры
*қөббә* – гөмбәз
*көфре кяфер* – кяфернең көферлеге
*көчай* – авыр
*қуй қәдәм* – аяк бас, атла, кер
*қуңшылық* – күршедә
*құрқугумдин* – куркуымнан
*қурла* – тапкыр, мәртәбә
*күзә* – чүлмәк (кызыл балчыктан эшләнгән савыт)
*күк оругдин* – көн яктысыннан
*күләткә* – күләгә

*күни; күнүлүр* – дөрес, яхшы; дөрес булыр
*күңүл ләүхе* – күңел тәкъдире, күңел кушуы
*күр* – сукыр
*күрәр; күргәйсән; күргүздүм* – күрер; күрерсең; күрсәттем
*күрүклүк* – күркәм, ямьле
*кутүреб* – күтәреп
*қыйлалым* – кылыйк
*қыйлғай, қыйлғаймән* – кылсын, кылырмын
*қыйль* – сүз
*қымурсқа* – кырмыска
*кямикяр (кямкяр)* – теләкләрне кабул итүче
*кяне сафа* – рәхәтлек чыганагы

*лала* – тәрбияче, хезмәтче
*ләтыйф* – йомшак, гүзәл, мөлаем
*Ләтыйф* – бәндәләргә бик күп йомшаклык һәм шәфкать кылучы (Аллаһы Тәгалә)
*ләфзы* – сүзе
*ләшкәр қоруб текде ғәләм* – гаскәр төзеп, байрак текте
*лиқа* – кавышу, очрашу
*лөтф, лөтыф* – мәрхәмәт, гүзәллек, киң күңеллелек
*лөтф-у-кәрәм* – мәрхәмәт һәм юмартлык
*лөтфы Рабб* – Аллаһ мәрхәмәте
*ля җәрәм* – шиксез, әлбәттә

*мале хуш* – яхшы мал-мөлкәт
*маһ* – ай
*маһе лиқа* – ай кебек йөзле, чибәр
*мәғани* – мәгънәләр
*мәғмүр ирүр* – төзек булыр
*мәғсийәт* – гөнаһлы эш, гөнаһ
*мәғфирәт* – гафу итү, кичерү
*мәдәд* – ярдәм, булышлык
*мәдхе* – макталуы, мактаулы исеме
*мәзид* – артык
*мәйел* – теләк, кызыксыну
*мәқам* – урын, яшәү урыны
*мәқсуд* – максат, ният
*мәкян* – урын
*мәлик* – патша, хөкемдар
*мәлүл* – ялыккан, сагышлы
*мәнзил* – урын, йорт

*«Мән сәкәтә сәлимә вә мән сәмәтә нәҗа» (хәдис)* – дәшмәүче имин булыр, телен тыючы котылыр

*мәңа* – миңа

*мәңизлек* – кебек, охшаш

*мәхрәм* – якын дус, сердәш

*мәшвәрәт* – киңәш

*мәшриқ-у-мәгъриб* – көнчыгыш һәм көнбатыш

*миннәт* – яхшылыкка каршы яхшылык итү

*миһтәр* – иң олы, бөек

*мишет* (мәшиәт) – ирек

*могъаззам* – бөек, олы, хөрмәтле

*мона* – менә

*монча; мончалық* – бу хәтле; бу кадәр

*морад мөнтәһа* – ахыргы максат, соңгы теләк

*мордар* – әшәке, шакшы

*Мостафа* – сайланган (Мөхәммәд пәйгамбәрнең мактаулы исеме)

*мотигъ* – буйсынучы, сүз тыңлаучы

*мохтәсар* – кыска, кыскача аңлатма

*мөбариз* – пәһлеван, бергә-бер чыгып сугышучы баһадир

*мөгътәбәр* – хөрмәтле

*мөдам* – өзлексез, даими

*мөҗаувир* – шәкерт, күрше, дәрвиш

*Мөҗиб* – догаларны кабул итүче (Аллаһы Тәгалә)

*мөлек* – дәүләт, патшалык

*мөнаҗат* – догалар

*мөнасиб* – кулай, яраклы, уңайлы, әдәпле

*мөнтәбиһ* – уяу

*мөнтәзыйр* – интизар, зарыккан, өмет итүче

*мөсәлләм* – күндерелгән, канәгать

*мөсәххәр* – буйсындырылган

*мөстәдам* – даими, мәңгелек

*мөстәҗаб иткәй* – кабул итсен

*мөстәхәқ* – лаек

*мөфәххәр* – мактаулы, данлы

*мөфлис* – бөлгән, фәкыйрь

*мөфлисанә* – фәкыйрьләрчә

*мөхәррәр* – язылды

*мөхиб-ү-бинәва* – якын дус һәм фәкыйрь

*мөхкәм* – бәхәссез, нык, чыдам

*мөхкәм-ү-мөстәхкәм* – тотрыклы һәм ышанычлы

*мөшәррәф* – кадерле, хөрмәтле

*мөшк-ү-гъәнбир* – хуш исле матдә, хуш исләр

*мур* – кырмыска

*нагяһ, нагяһан* – кинәт, көтмәгәндә
*нагяһан йазыб йаңылса* – кинәт ялгышса
*назүк* – нәзек, нәфис, сизгер
*намидар (намдар)* – данлыклы, атаклы
*нар* – әнар, гранат җимеше
*нәбийү Аллаһи* – Алла илчесе, пәйгамбәр
*нәбийү әүвәл вә хатәм* – әүвәлге һәм соңгы пәйгамбәр
*нәбүвәт мәгдәне* – пәйгамбәрлек чыганагы
*нәгте рәсүлуллаһи саллаллаһу гәләйһи вәссәлләм* – пәйгамбәрне (аңа Аллаһның салаватлары һәм сәламнәре булсын) мактау
*нәдәм (нәдем)* – үкенеч
*нәҗат* – котылу
*нәзар* – карау, караш
*нәзыйр* – кебек, охшаган
*нәзым аймаҗга* – шигырь әйтергә
*нә ирсә* – нәрсә
*нәҗел, нәҗл* – ишеткәнне сөйләү, күчерү
*нәмәрсә, нимә* – нәрсә, әйбер
*нәүҗәван* – яшь егет
*нәчә, ничә* – күпме
*нийаз* – дога, ялвару
*ник-ү-нам (ник нам)* – яхшылык белән танылган
*ниһан* – яшерен, серле
*ноҗсан* – кимчелек, җитешсезлек
*носрәт-ү-фәтх* – җиңү һәм яулау
*нуре җәһан* – дөнья нуры
*нуш* – йоту, эчү
*озаҗҗы* – борынгы, элекке
*ойу* – йоклау
*орғыл җәдәм* – аяк бас, атла
*отру* – каршы

*өреттең* – тынычландырдың, ял иттердең

*падишаһи падишаһан* – патшалар патшасы
*паидар (пайдар)* – үзгәрми торган
*пайандә* – ахырында
*пакизә* – чиста, пөхтә
*пак-у-тәк* – изге һәм бөек
*парсы* – фарсы

*пәнаһ* – саклаучы, яклаучы
*пәнде хуш* – яхшы киңәш, нәсихәт
*Пәрвәрдигяр* – барлыкка китерүче (Аллаһы Тәгалә)
*пир* – рухи җитәкче, остаз, карт кеше, аксакал
*пире ләтыйф* – мөлаем аксакал
*пире никхаһ* – бик игелекле остаз
*пире хуш* – күркәм җитәкче
*пир-ү-җәван* – карт һәм яшь
*пөр қыйлғыл; пөр нур ирүр* – күм; нурга күмелер
*пөр чәмән* – чәчәккә күмелгән, чәчәклек
*пулча* – пул кебек, вак акча кадәр

*Рабб* – хуҗа, тәрбияче (Аллаһы Тәгалә)
*рави* – риваять итүче, сөйләүче
*раунақ* – якты, нурлы, бөек
*рафу (рофу) кыйл* – төзек ит, төзәт
*раһибәр (рәһбәр)* – юлбашчы, юл күрсәтүче
*рәва* – яраклы, тиешле, ятышлы
*рәван* – китүче, юнәлүче, рух, җан
*«Рәҗәғна мин җиһадил-ахирәти» (хәдис)* – Без бүтән җиһадтан кайттык
*рәнҗ-ү-михнәт* – авыру һәм михнәт
*рәсүл; рәсүлуллаһ; рәсүлел-ғаләмин* – пәйгамбәр; Аллаһ илчесе; ике дөнья илчесе
*рәушан вә ширин шәффаф-у абидар (абдар)* – нурлы, саф, пыяладай үтә күренмәле һәм ялтыравыклы
*рәфиқ* – иптәш
*рәхим-ү-шәфқәт* – рәхим һәм шәфкать
*рәхмәтән лил-ғаләмин* – дөньяларның рәхмәте
*ризван* – оҗмах, җәннәт
*рийазәт* – күп нәрсәләрдән суфиларча тыелу
*рисаләт* – илчелек, пәйгамбәрлек
*рузә-намаз* – ураза-намаз
*рузегяр (рузгяр)* – заман, вакыт
*рузи қыйлды* – насыйп итте
*рузи мәхшәр* – кыямәт көне
*руз-у-шәб* – көн һәм төн
*руйи зәмин* – җир йөзе

*сабиқ* – элек, алдан
*садиқ, садиқанә* – тугры, эчкерсез, чын, гадел
*садре җәлаләт* – иң югары дәрәҗәле, галиҗәнап

*садрел-кәрам* – иң кадерле, иң затлы
*сад һәзар* – йөз мең, чиксез күп
*сайәңезгә сыгыну* – күләгәгезгә сыенып
*сайд қыйлу* – ау аулап
*сакит* – дәшмәүче
*салим* – сәламәт, имин
*Самиг* – бөтен нәрсәне, дога-теләкләрне ишетүче (Аллаһы Тәгалә)
*самит* – дәшмәүче, тыныч
*сарих* – ачык, ап-ачык
*сарнычқа* – чикерткә
*сарыфы рәнж* – мәшәкать чигү, җәфалану
*сафа* – рәхәтлек, хозурлык
*сахибе миграж-у садрел-әнбийа* – мигъраҗга ашучы һәм пәйгамбәрләрнең юлбашчысы
*сахибе хөсн-ү-җәмаль* – гүзәллек иясе, бик чибәр
*сахих* – дөрес, чын
*сач* – чәч
*сачылыб* – чәчелеп
*сәвад* – караламаны язу, язып төгәлләү
*сәвар* – атлы, җайдак
*сәвәр* – сөяр
*сәвендергәй; сәвүнүб; сәвүнче* – сөендерер; сөенеп; сөенче
*сәгадәт* – бәхет, рәхәтлек
*сәгадәт мәгдәне* – бәхет чыганагы
*сәгид* – бәхетле
*сәйидел-кәунәйн* – ике дөнья патшасы
*сәна* – мактау
*сәрасәр* – башыннан ахырынача
*сәрвәр* – иң дәрәҗәле кеше
*сәха, сәхи* – юмартлык, юмарт
*сәхабә* – Мөхәммәд пәйгамбәрне күргән замандашы
*сәхавәт мәгдәне* – юмартлык чыганагы
*сәчәк* – чәчәк
*сипаһ* – гаскәр
*Сипаһ-салар мәйдани рисаләт* – пәйгамбәрлек мәйданының гаскәр башлыгы
*сискәнүбән* – сискәнеп
*собх-у-шам* – иртә һәм кич
*сойургал; сойургаса* – хан бүләге; бүләкләсә
*солтанәт* – патшалык, патшаларча
*сорса* – сораса
*соффә* – югарыга күтәрелү, дәрәҗә

*Сөбхан* – һичбер кимчелеге булмаган зат (Аллаһы Тәгалә)
*сөрәр ирде* – куар иде
*сөчүк* – татлы, тәмле, төче
*сусағай* – сусады
*сүзенгә; сүзләнүр* – сүзенә; сөйләнә
*сүзләгәй* – сөйләр, сөйләшер
*сыв* – су
*сыйддиқ; сыйддиқы әкбәр* – чын сүзле; иң туры сүзле
*сыйдық* – тугрылык, эчкерсезлек
*сынайын* – сыныйм
*сынған, сынуқ* – ватык, ватылган

*та, таки* – шуңарчы, аңа хәтле, чаклы, кадәр
*табғай; табғаймән; табқул; табмаз* – табар; табыйм; тап; тапмас
*табуғ, тәбуғ* – буйсыну, олылау, тугры хезмәт, каршысында
*тағ* – тау
*тағәт* – гыйбадәт, буйсыну
*таҗе сәр* – патшалык таҗы
*таза ут* – яшь үлән, яшел чирәм
*там* – дивар
*таңла* – иртән, иртәгә
*таңлар, таңлағай* – гаҗәпләнер
*таңсуқ* – тансык, кадерле
*тарқады* – таралды
*тасниф* – китап язу
*ташқару* – тышка
*«Тәбарәк»* – Коръәннең «Әл-Мөлк» сүрәсе
*тәвәккәлна ғаләл-Лаһи әманән, тәвәҗҗәһна иләл-Хаққи зәманән* – иминлегебезне Аллага тапшырдык, вакытлыча хакыйкатькә юнәлдек
*тәвәққығ* – өмет итү, үтенү, сорау
*тәғәйир, тәғйир* – үзгәрү
*тәдбире рай* – уйлап эш итү
*тәйеб, тәйү* – дип
*тәйер* – дияр
*тәк* – тик, кебек, охшаш
*тәкәллем* – сөйләү
*тәқи* – тагын
*тәқрир* – телдән аңлату
*тәмам* – тулы, бөтен, ахыр, соң
*тәнәғғем* – туклану, нигъмәттә булу
*Тәңрене берсене* – Алланың бер икәнен

*тәсаддық* – садәка, садәка бирү
*тәсаррыф* – эш йөртү, хуҗа булу
*тәслим* – тапшыру, бирү
*тәүә* – дөя
*тәхрир* – язу, язып аңлату
*тәшвиш* – борчылу, буталу, шик
*теләнү* – теләнеп, ялварып
*теркенчә* – ашыгып, тиз-тиз
*тиб, тийеб* – дип
*тиггәр* – тияр, чагар
*тигде* – тиде, җитте
*тигеш* – тиешле бүләк
*тигмә* – һәр, һәрбер, һәркайсы
*тигмәс* – тимәс
*тигрү* – хәтле, кадәр
*тигүреб; тигүрәйен* – җиткереп; тапшырыйм
*тигшүреб* – алмашып
*тимәде; тимәк* – димәде; әйтү
*тиңез* – диңгез
*тотқай* – тотар
*төрк; төрки рәсем* – төрки, төркичә
*төрлүк* – төрле
*ту* – саф, чиста
*туғса* – туса
*туз* – тузан
*туй* – зур бәйрәм
*туқуш* – сугыш
*тултурды; тулуғ* – тутырды; тулы
*тун* – өс киеме
*түзгәй* – түзәр
*түрт* – дүрт
*тынғай* – тынычлансын

*уға* – аңа
*Уған* – Аллаһ
*уза* – узып
*уқы пәйкәне* – угының очы
*улҗа* – сугышта алынган мал, трофей
*улмаз* – булмас
*ултур; ултурырда* – утыр; утырганда
*Урду* – Урда
*уруч, уруҗ* – ураза

*ус* – акыл, тәрбия
*ут* – үлән, печән
*уш* – бу, хәзер, инде
*ушал* – шул

*үгәр, үгде* – мактар, мактады
*үгрәндем; үгрәтәйем* – өйрәндем; өйрәтим
*үзә (үзрә)* – буенча, өстендә, янында, каршы
*үзенгә* – үзенә
*үкүш* – күп, бик күп, мул
*үчүр* – бетер, юкка чыгар

*фазлы* – өстенлеге
*«Фатиха»* – Коръәннең «Әл-Фатиха» сүрәсе
*фәйзъ* – файда, белем
*фәтх-ү-зафәр* – яулау һәм җиңү
*фәхер итәр* – горурланыр
*фәхре ғаләм* – галәм горурлыгы
*фәхре дин* – диннең даны
*фәхре җәһан* – дөньяның горурлыгы
*фәхрел-әнам* – шөһрәт иясе, данлыклы
*фәхрел-мөрсәлин* – пәйгамбәрләрнең иң мактаулысы
*фәхрел-өмәм; фәхре садиқ* – өммәтләрнең горурлыгы; тугрылык үрнәге
*фетнә-ү-тәшвиш* – фетнә һәм тәшвиш
*фиған* – аһ-зар, елау, зарлану, ярдәм сорау
*фикрәт* – фикер йөртү, уйлану
*фисқ-у-фәсад* – бозыклык һәм азгынлык
*фөзуль* – хаксыз хәрәкәт итү, арттырып җибәрү

*хазир* – катнашучы
*Хақ* – Аллаһы Тәгалә
*хали* – хәзер, хәзер үк
*хали булмас* – буш булмас
*халь тели (халь теле)* – мәсьәләнең торышы, вазгыять
*хасс-у-ғам* – халык, барлык кешеләр, югары катлау һәм гади халык
*хатәм* – иң соңгы
*хаша* – һичбер
*Хәбиб* – Аллаһы Тәгаләнең сөеклесе (Мөхәммәд пәйгамбәрнең мактаулы исеме)
*хәзин* – кайгылы, хәсрәтле

*хәзрәтеңдә* – хозурыңда, алдыңда
*хәйа* – оят, оятлылык, тыйнаклык
*хәйат* – тормыш, яшәеш
*хәким* – акыл иясе
*хәлаиқ* – халыклар, кешеләр
*хәләл* – зарар, кимчелек
*хәлвәт* – аулак-буш урын, ялгызлык
*хәлим-ү-хәйа* – сабыр һәм тыйнак
*хәляс* – коткару, азат итү
*хәммаль* – йөкче
*хәраб* – харап, җимерек
*хәрбенгә* – сугышуына
*хәреҗ* – тоту, чыгым
*хәтем қыйлдым* – тәмам иттем, төгәлләдем
*хәузы Кәүсәр* – Кәүсәр чишмәсе
*хәшер* – кыямәт көнендә бер урынга җыелу
*хиҗләт* – оялу, уңайсызлану
*хикәм* – хикмәтләр
*хилгәт* – югары хаким тарафыннан бүләк ителгән өс киеме
*химайәт* – яклау, саклау
*хирәд* – акыл, фикер, зиһен
*хитаб* – мөрәҗәгать итү, эндәшү
*хишем* – ярсулы ачу
*Ходавәндә* – Аллаһ, хуҗа
*хоршиде нур* – Кояш нуры
*хөрмәт-ү-гиззәт* – хөрмәт һәм гыйззәт
*хөррәм* – чәчәк атучы
*хөсне җәмаль* – күркәмлек, чибәрлек
*хур суы* – бәвел
*хури җинан* – җәннәт хурлары

*һатиф* – яшерен тавыш, изге рух
*һәвадар* – яхшылык теләүче
*һәйбәт* – дәһшәт, куркытырлык һәм хөрмәт иттерерлек көч
*һәмишә* – һаман, һәрвакыт, өзлексез
*һәмнешин* – әңгәмәдәш, иптәш
*һәргиз* – һичкайчан, һичбер
*һөмам* – һиммәт ияләре, киң күңеллеләр

*чәшмә* – чишмә
*чикеш (чигеш)* – кара: тигеш
*чөн* – өчен, чөнки, инде

*чөнкем* – чөнки
*чықалым* – чыгыйк

*шадиман* – шатлыклы, сөенгән
*шафиғ* – яклаучы
*шаһа* – шаһым
*шаһзадә, шаһизадә* – шаһ улы
*шаһи ғаләм, шаһи җәһан, шаһи дар* – дөнья шаһы
*шаһсәвар* – оста җайдак
*шәжәғәт бабыда* – батырлыкта
*шәремсар* – оятлы
*шәриф* – изге, кадерле
*шәрқ-ү-ғәрб* – көнчыгыш һәм көнбатыш
*шәрмәндә* – оятка калган, оятлы ителгән
*шәрр* – яманлык, зыян
*шәрх, шәрех* – аңлату
*шәфиғ; шәфиғел-мөзнибин* – арадашчы; гөнаһлыларны яклаучы
*шәфиқ* – шәфкатьле
*шәһид* – дин өчен корбан булган кеше
*шәһрейар* – хөкемдар, патша, дус
*шуридәи әхваль* – борчулы хәлләр
*шүр* – тоз, тозлы
*шүрстан* – тозлы туфрак, уңдырышсыз җир

*ырғады; ырғаса* – шатланды; шатланса

*эв* – өй
*эче-ташы* – эче-тышы
*эчийәм; эчкел; эчкүгә* – эчим; эч; эчәргә
*эчрә* – эчендә, өстендә

# «СҮЗЛӘРЕМНЕ ҮЗГӘРТМӘСЕННӘР...»

Мөхәммәдьяр әсәрләренең тулы килеш, төрле кульъязмаларны өйрәнеп һәм чагыштырып тәнкыйди текстлары тупланган китапның 1997 елда дөньяга чыгуы бик зур казаныш иде. Китапның мөхәррире сүзендә (4 нче биттә) «Бу китап Мөхәммәдьярны өйрәнүдә, аңлау-аңлатуда соңгы сүз рәвешендә каралырга тиеш түгел» диелгән һәм текстологиягә бәйле сәбәпләр күрсәтелгән.

Ул басмадагы текстологик кимчелекләр, кызганычка каршы, шактый иде. Алар турында галим Мәсгуд ага Гайнетдин тәфсилле күзәтүләре белән уртаклашты һәм аерым мисаллар күрсәтеп язды[1]. Ул шулай ук 1997 елгы басманы «хәзерге телгә (шактый күп хаталы) тәрҗемәләре белән...» дип тә искәртте[2]. Шулай ук Фәрит Яхин һәм башка галимнәр дә 1997 елгы басманың җитешсезлекләрен белдереп яздылар.

Әлеге мәсьәләгә 2009 елда дөнья күргән китапта һәм 2013 елгы мәкаләдә бу юлларның авторы шулай ук тукталды. Мәкаләдә мондый юллар бар иде: «Киләчәктә, Мөхәммәдьяр әсәрләренең яңа басмаларын әзерләгәндә, кульъязмаларның һәммәсе дә файдаланылырга һәм текстологик яктан җентекләп өйрәнелергә тиеш. Чөнки, әйтеп үткәнебезчә, текстларда аермалы һәм яңалык өсти торган урыннар бар. Мөхәммәдьяр әсәрләренең моннан уналты ел элек дөнья күргән басмасы инде искергән булуын да танымыйча мөмкин түгел. Андагы кимчелекләрне һәм ялгышларны төзәтеп, яңадан нәшер итү ихтыяҗы зур. Мөхәммәдьяр кебек борынгы әдипләрнең иҗади мирасы, һичшиксез, хәзерге фәнни таләпләр югарылыгында камилрәк рәвештә басылырга тиешле»[3].

---

[1] Гайнетдин М. Хакыйкать юлыннан: әдәби тәнкыйть. – Казан: Татар. китап нәшр., 2001. – Б. 97–113.

[2] Гайнетдин М. Мөхәммәдьяр Мәхмүд улы // Әд-дин вәл-әдәп. – 2009. – Май. – Б. 11.

[3] Мәрданов Р. Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы кульъязмалары // Чын мирас. – 2013. – №6. – Б. 38.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең 2021 елда чыккан, полиграфик сыйфаты бик күркәм соңгы басмасы – шул ук 1997 елгы китапның яңачарак кабатланган варианты. Анда кайбер структура үзгәрешләре булса да, аяныч ки, текстологик өлеше элекке китаптагыча калган диярлек.

«Нуры содур» әсәре ахырында Мөхәммәдьярның: «Әлфазымны тәгъйир итмәгәйләр...», ягъни «Сүзләремне үзгәртмәсеннәр» дип язганына мөмкин кадәренчә тугрылык саклануы зарур.

Шагыйрь әсәрләренең 1997 һәм 2021 елларда нәшер ителгән китапларында дөнья күргән «Нуры содур» текстларындагы җитешсезлекләрнең бер өлеше кереш мәкаләдә һәм әсәр текстының искәрмәләрендә күрсәтелде. Мәсәлән, бүлек исемнәренең тулы һәм дөрес итеп бирелмәүләре, «Нуры содур» поэмасының ачыкланган өстәмә икеюллыкларының кертелмичә калдырылуы һ.б.

Мөхәммәдьяр иҗатына игътибар киләчәктә дә кимемәячәген, һәрхәлдә, «Нуры содур»ның иҗат ителүенә 2026 елда 485 ел тулачагын һәм 500 еллыгы да ерак түгеллеген истә тотып, яңадан бастырганда «Нуры содур» текстындагы моңарчы булган кимчелекләр кабатланмасын иде дигән теләктә торабыз. Аеруча әһәмият бирелергә тиешле урыннарын искәртеп үтәбез.

Мондагы искәрмәләр 1997 елда дөнья күргән китаптагы тәнкыйди текстка һәм хәзерге татар әдәби теленә күчерелмәсенә нигезләнде. 1997 елгы китап төп хезмәт булып каралганга һәм монда күрсәтеләсе кимчелекләрнең тексттагы урынын тәгаенләү өчен шул ук басмадагы икеюллыклар (бәйтләр) санына ишарә итү кулайрак. Чөнки 2021 елгы китапта бәйт саннары куелмаган.

### «Нуры содур» текстын киләчәктә бастырганда<br>игътибар ителүе зарур урыннар

1. 1997 елда басылган китапның 170 нче битендә, әсәрнең иң башында хилафлык бар. Анда «Нуры содур» дип әсәрнең исеме бирелгән һәм шуннан соң «Һәза китаб бисмилләһ-ир-рахман-ир-рахим» гыйбарәсе язылган. Бу очракта кулъязма китаптан турыдан-туры күчерү акланмый. Билгеле булганча, һәрбер кулъязма китап башында иң әүвәл «бисмилла...» сүзе язылган. Кайбер китапларда әсәрнең исеме әлеге гыйбарә белән янәшәдә теркәлгән, ә атама озынрак булса «бисмилла»ның ике ягына бүлеп язу гадәте булган. 1997 елгы басмадагы «Нуры содур» текстының төп чыга-

нагы итеп алынган «В4417» (СПб-1) күчермәсендә дә нәкъ шулай: «бисмилла...»ның ике ягында – уң тарафта «һәза китаб» (бу китап), сул якта «Нуры содур» (бу нөсхәдә хаталы итеп: «Нур садаир») дип теркәлгән. Иске кульязмаларга хас булган андый ысулның 1997 елда басылган китапта бутап бирелүе зур ялгыш. Чөнки мәгънәсе: «Бу китап бисмиллаһи....» килеп чыккан. Шундый ук язылыш 2021 елгы басмада да (197 биттә) кабатланган.

2. 23 нче биттәге 172 нче бәйттә «уқы тигәнедин» дигән гыйбарә СПб-1 күчермәсендә «уқы йигәнедин», ә СПб-2 нөсхәсендә дөрес рәвештә «уқы пәйкәнедин» дип теркәлгән. Башка кульязмаларда да (Югары Курса, Олы Мәңгәр, Барда) «пәйкәнедин» дип язылган. «Пәйкән» сүзе фарсы телендә «ук очы» дигәнне белдерә. Шунысы кызыклы, 1997 елгы китапта төп текстта «уқы тигәнедин» (угы тигәннән) дип бирелгән гыйбарә тәрҗемә текстта (243 биттә) «ук очы» дип дөрес басылган.

3. 174 нче биттәге 59 нчы бәйттә «Сәлтанәт эчрә җәһанда иллә торсун» юлының соңгы сүзе турында төзүче «ике кульязмада да: къәрсун, ягъни, карысын-картайсын. Хәзерге шартлы рәвештә торсун (торсын – яшәсен) дип алам» дип искәрткән (230 бит). Бу сүз башка күчермәләрдә дә «карыйсын» дип ачык язылган һәм аның «солтан булып картайсын» дигән мәгънәсе мантыйкка туры килә.

4. 175 нче биттәге 68 нче бәйттә «би сүд саман» дигән гыйбарә бар, текстның тәрҗемәсендә (246 нчы биттә) ул «файдасыз» дип бирелгән. Әлеге сүзтезмә кульязма күчермәләрдә хаталы итеп теркәлгән: «бәни сүди сани» (СПб-1), «би сүди саман» (СПб-2), «би сүд саман» (Югары Курса, Олы Мәңгәр, Барда, Сарман). Бу гыйбарәнең дөресе – фарсы телендәге «бисәр-ү-саман» һәм ул «мескен, ярдәмчесез» дигән мәгънәгә ия.

5. Китапның 175 нче битендәге 73 нче икеюллыгына игътибар итик:

Илаһи, бу китаб булғай мөбарәк
Бәхаққы «Ғәммә», «Ихлас» вә «Тәбарәк».

Аның тәрҗемәсе 246 биттә:

И Илаһым, бу китап булсын котлы –
Нәби, ихлас һәм фатихаңа хуплы,

– дип басылган. Бу мәсьәләгә карата 303 биттәге искәрмәдә: «Мөхәммәдьяр поэмалары беренче тапкыр нәшер ителгәндә (1966,

83 б.) бу юлдагы «гаммә», «ихлас», «тәбарәк» сүзләре Коръәннең аерым сүрә исемнәре рәвешендә аңлатылган иде. Әлбәттә, болай аңлау мөмкинлеге бар. Әмма беренче сүзне «гаммә» («барысы») дип түгел, «гъәм» дип уку кирәклеге аңлашыла... Биредә нәкъ Мөхәммәд пәйгамбәргә мөрәҗәгать ителә. Ул арадашчы булганлыктан, шагыйрь аннан китапка фатиха бирүне сорый» дип аңлатылуы белән килешеп булмый. Китапның 227 битендәге 776 нчы бәйттә әйтелгән шигъри юл «Бә хәққи ғәм вә ихляс вә Тәбарәк» буларак кабатланган һәм 330 нчы биттәге тәрҗемәсендә «Мөхәммәднең ихлас хакына хуплы» дип бирелгән. Мондый аңлатмалар һәм тәрҗемәләр дөрес түгел.

«Гаммә» дип Коръәндәге «Ән-Нәбә» сүрәсен атап йөрткәннәр. Гарәп телендәге ике сүзнең: «ган» белән «ма»ның кушылмасы «гаммә» сүзе рәвешендә язылып, «нәрсә турында» дигән мәгънәне белдергән. Шунлыктан, әлеге сүзгә карата Ш.Абилов аңлатмалары ялгыш. Халык арасында «Тәбарәк» дип тә әйтелгәне – «Әл-Мөлк» сүрәсе («тәбарәк» – аның беренче гыйбарәсе)[4]. Ә пәйгамбәргә мөрәҗәгать итү рәвешендә сүз барганда беркайчан да «гъәм» диелмәгән. «Галәйһиссәлам» сүзенең кыскартылмасы – «гһм» (яки «гъм») – язма текстларда бары тик пәйгамбәрләрнең исемнәреннән соң яки «рәсүл, рәсүлулла, пәйгамбәр» кебек сүзләрдән соң теркәлгән.

6. 179 нчы биттәге 123 нче бәйттә «салыни» сүзенең дөресе «малыни» (малын) булырга тиеш иде. СПб-1 күчермәсендә ул «әлени» дип, ә СПб-2, Барда һәм Сарман нөсхәләрендә «малыни» рәвешендә – дөрес теркәлгән. Тәнкыйди текст өчен кулланылмаган Олы Мәңгәр һәм Югары Курса күчермәләрендә дә «малыны» дип язылган. Китапта бирелгән «сал» сүзенең «мал-мөлкәт, байлык» дигән мәгънәләре булмаса да, тәрҗемә текстта (китапта 250 биттә) ул сүз, ни гаҗәп, «малын» дип, дөп-дөрес басылган.

7. 187 нче биттәге 233 нче бәйттә «Ахирәт эшендин қылмас һич хәләл» дигән юл бар һәм андагы соңгы сүзгә карата 232 нче биттә: «каты «х» белән язылган, шунлыктан «а» аша бирергә туры килә, «халәл»(хәләл) – зыян, зарар, кимчелек, бозу» дигән искәрмә язылган. (Вәләкин китап текстында «хәләл» дип басыл-

[4] Халкыбыз телендә хәзер дә еш әйтелә торган «Тәбарәк» атамасы Казан ханлыгы чорыннан ук килә икән.

ган). Китапның аңлатмалар өлешендә (304 нче биттә) 40 нчы сан[5] астында шул ук сүзгә карата мәгълүмат бирелгән һәм «бу икеюллык каршылыклы фикерләр тудыра. Ул күчерүче тарафыннан өстәлмәде микән?» дигән шөбһә белдерелгән. Бу шигъри икеюллыкның кулъязмаларда үзгәрешсез теркәлгәнлегенә карағанда, аны күчерүчеләр өстәмәгән. Икеюллык ахырындагы сүзе исә төрлечәрәк: «хәлямил» (хаталы, СПб-1), «хәлил» (СПб-2), «хәләл» (Олы Мәңгәр, Сарман), «хиләл (хилял)» (Югары Курса) дип язылган. Автор текстында хәзерге телдән аермалырак «Ахирәт эшеннән зарар кылмас» дигәндә «Ахирәт эшенә зарар китермәс» мәгънәсе күздә тотылган.

8. 190 нчы биттәге 271 нче бәйттә «җәһд» дип язылган сүз ялгыш, аның дөресе бөтен кулъязмаларда теркәлгәнчә – «җиһәт» дип бирелергә тиеш.

9. 204 нче биттәге 461 нче бәйттә язылган «инҗү» сүзе һәм аның тәрҗемәдә (276 нчы биттә) «энҗе» дип бирелүе, шулай ук, әлеге сүз Мөхәммәд пәйгамбәргә карата кулланылган, дигән аңлатма (276 нчы һәм 305 нче битләрдә) дөрес түгел. Бу сүз кайбер кулъязмаларда «анча» дип ялгыш яки башкача бозып теркәлгән, дөресе – «инче» рәвешендә СПб-1, СПб-2, Барда һәм Сарман кулъязмаларында язылган. Тексттагы «сезгә ... инче бәндә булалым» дигәндә «сезгә ... хезмәтче кол булыйм» мәгънәсенә ия.

10. Әсәр текстының 205 нче битендәге 475 нче бәйтнең икенче юлында «дәүләт булур» дигән сүзтезмә бар. Тәрҗемәсендә (277 биттә) ул «бәхетле булыр» дип бирелгән. Ләкин «булур» сүзе бу очракта «булыр» мәгънәсендә түгел, ә «табар» дигәнне аңлаткан. Шул ук китапта бер икеюллыктан соң гына (477 бәйттә) «табар дәүләт» дигән варианты да шуны раслый.

11. 211 нче биттәге 560 нчы бәйттә «Җуркуғумдин сәңа йитеб сордым уш» дигән юлдагы «сәңа йитеб сордым» өлеше дөрес түгел. Бу сүзтезмә СПб-1 кулъязмасы буенча алынган. Ләкин Ш.Абилов эш иткән СПб-2, Барда, Уфа һәм Сарман күчермәләрендә ул гыйбарә «сискәнеб тордым» дип язылган. «Нуры содур»ның соңрак табылган кулъязмаларында да «сискәнеб тордым» дип

[5] Бу санны текстта тапмадык. Әлеге икеюллыкта, гомумән, аңлатмага ишарә итәргә тиешле бернинди сан да куелмаган. Бу бәйттән алдарак «35», арттарак «35г» дигән саннар бар.

теркәлгән. Ә менә 1997 елгы китапта әсәрнең тәрҗемәсендә, «Куркуымнан шунда сискәнеп тордым» дип, дөп-дөрес язылган.

12. Китапның 213 нче битендә 583 һәм 584 нче бәйтләрнең икенче юллары бер төрле үк: «Ибн Әсғәд ләшкәрени қырды ул». Аерма бәйтләрнең икенчесендә шул ук кешенең исеме «Ибне Ашғас» дип бирелүендә генә. Өстәвенә, 583 нче икеюллыкның рифмалашкан сүзләре «ул/ул», 584 бәйтнеке «йул/ул». Ә тәнкыйди басманы төзүче кулланган Уфа кулъязмасында бәйтләрнең беренчесенең икенче юлы «Ибне Ашгас ләшкәре сынды рәван» һәм икенче бәйтнеке «Ибне Ашгас ләшкәрене қырды ул» дип теркәлгән. Шул сәбәпле рифмалашкан сүзләр дә ике төрле: беренчесендә «нагяһан/рәван» һәм икенчесендә «йул/ул». Шундый ук рәвештәге язылышны Югары Курса (бу китапта 584 һәм 585 санлы икеюллыклар), Ижевск, Яңа Аккуҗа нөсхәләрендә дә күрәбез. Ә Олы Мәңгәр, СПб-1, Урта Шөн, Барда һәм Сарман күчермәләрендә һәм 1997 елгы китапта әлеге ике бәйт бергә кушылып, буталган.

13. 214 нче биттәге 593 нче бәйттә «имди» дип язылган сүз ялгыш, дөресе – «Изи» (Аллаһ).

14. 214 нче биттәге 595 нче бәйттә «Хәқлық өчен» гыйбарәсе тәрҗемәдә (286 биттә) «дөреслек-хаклык өчен» дип бирелүе ялгыш. Чөнки дөресе – «Алла хакы өчен» булырга тиешле.

15. 216 нчы биттәге 616 нчы бәйттә «...уқ атсаңыз төсаб» дип язылган һәм ахыргы сүзе тәрҗемә өлешендә (288 нче биттә) «төзәп» дип бирелгән. «Төсаб» язылышы күп хаталы кулъязма – СПб-1 күчермәсеннән алынган. Анда да бу сүзнең «саб» дигән иҗеге башта язылып «тө» иҗеге соңыннан өстәлгән. Башка барлык күчермәләрдә (Югары Курса, Олы Мәңгәр, Уразай, Ижевск, Урта Шөн, Барда, Сарман) әлеге хаталы сүз урынында «йасаб» (ясап) дип, дөрес вариант теркәлгән.

16. 216 нчы биттәге 628 нче бәйттә:

Ничә кем булса җәһанда – аны бел,
Ничә кем сүзләре эшлиди қал-у қил,

– рәвешендә, СПб-1 нөсхәсе буенча алынган һәм шуның нигезендә тәрҗемә ителгән өлеше дөрес түгел. Югыйсә, «аны бел» урынында СПб-1 һәм Барда нөсхәләрендә «ай бел», ә Сарман кулъязмасында «ай-йыл» рәвешендә теркәлгән. СПб-1 нөсхәсендә «эшлиди» дип бозып язылган сүз Барда һәм Сарман кулъязмаларында

«телдә» дип, «сүзләре» урынында «сүзләнсә» дип теркәлгән. Бу икеюллыкның дөрес тексты мондый:

Нәчә кем булса җәһанда – ай-у-йыл,
Нәчә кем сүзләнсә телдә қаль-у-қыйль.

17. Тәнкыйди текстта төрлечә укылу ихтималы булган кайбер катлаулы сүзләрнең яңа кульъязмалар ярдәмендә дөрес укылышларын элегрәк тә ачыклап язган идек[6]. Мәсәлән, 1997 нче елгы басмада 217 нче биттәге 631 нче бәйттә:

И догаларны ишеткән пак-ү тәк,
Хәзрәтеңә уш кылыб үзүм начакъ,

– дип язылган «үзүм начакъ» сүзтезмәсендәге икенче сүзне, күчерүчеләре тарафыннан хәреф нокталары урыннарын алыштырып язуларына карап, кульъязма текстларда төрлечә укырга мөмкин. Ш.Абилов биргән искәрмәдә (237 биттә) әлеге гыйбарәнең ике күчермәдә «йөзүм нәхак» дип, берсендә исә «йөзем нәҗакъ» дип язылганлыгы, ә дөресе «начакъ» (кәефсез) булуы әйтелгән. Ижевск нөсхәсендә әлеге сүзтезмә хәрәкәләр белән «йүзүм бүхак» дип язылган. Мондагы «бүхак» (бүхәк) сүзенең мәгънәсе – җиргә ору дигәнне, ягъни баш иеп йөзне җиргә тигерүне белдерә. Күчерүчеләр бу сүздәге хәрефләрнең нокталарын үзләре аңлаганча язып килгәннәр.

18. 218 нче биттәге 647 нче бәйттә «Рәхмәтеңнең тиңезендин ни қулар» дигән юл бар. Мондагы «қулар» сүзе китапны төзүче кулланган СПб-1 һәм Барда күчермәләрендә «қулар» дип һәм «қорар» дип тә укырлык дәрәҗәдә, аларда «ра» хәрефе «ләм» кебек озынрак язылган. Ләкин Сарман кульъязмасында «қорар» (корыр) дип ачык теркәлгән. Текстта «Чиксез рәхмәтең диңгезеннән ни кимер» дигән мәгънә әйтелгән һәм шуннан соңгы икеюллыкта Аллаһы рәхмәтенең бер тамчысыннан да барлык халык ярлыканыр дип әйтелгән.

19. 219 нчы биттәге 664 нче бәйтнең юллары СПб-1 кульъязмасындагыча (урыннары алыштырылган килеш) бирелгән:

Кичә тағәт берлә биш йөз йыл тәмам,
Көндүз уруҗ тотуб ул заһид мөдам.

---

[6] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмалары / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2009. – Б. 9–10.

Мондагы «уруж» сүзе Барда яки Сарман күчермәләреннән алынган дип аңладык. Чөнки СПб-1 нөсхәсендә «уруж» урынында «рузә» сүзе язылган. Бу икеюллыкның дөресе:

Көндүз уруж тотуб ул заһид мөдам,
Кичә тагәт берлә биш йөз йыл тәмам.

Бу икеюллык Ш.Абилов кулланган Барда һәм Сарман кулъязмаларында, шулай ук Олы Мәңгәр, Уразай, Ижевск, Урта Шөн, Яңа Аккужа һәм Югары Курса күчермәләрендә дә бер төрле үк теркәлгән.

20. 221 нче биттәге 684 нче бәйттә текстка өстәлгән «биш» сүзе артык. Китапта ул сүзгә карата аңлатма язылганын белдерә торган 69 саны куелган булса да, аңлатмалар бүлегендә саннар туры килмәгәнлектән һәм, гомумән, аны табып булмады. (Анда 69 саны астында 775 нче бәйткә аңлатма язылган). Әсәрнең бер күчермәсендә дә ул урында «биш» сүзе теркәлмәгән. Текстта заһид фәрештәгә үзенең йөз еллык гыйбадәтен тәкъдим иткән, ризалаша алмаганнан соң гына бөтенесен – биш йөз еллыгын да тапшырганлыгы турында сүз бара.

21. 221 нче биттәге 690 нчы һәм 691 нче бәйтләрнең урыннары төзүче тарафыннан алыштырылган. Гәрчә кулъязмаларның берсендә дә (Югары Курса, Олы Мәңгәр, Уразай, Ижевск, СПб-1, Урта Шөн, Барда һәм Сарман) андый үзгәреш юк. Димәк, ул бәйтләрнең урыннары алыштырылырга тиеш түгел.

22. 224 нче биттәге 727 нче бәйтнең беренче – «Чөн мөстәдим ирсә дөнйа эшени» юлындагы «мөстәдим» сүзе ялгыш һәм тәрҗемәсе дә дөрес түгел. Ул СПб-1 кулъязмасында хаталы итеп «мтдим» дип язылган сүз буенча бирелгән. Гәрчә Сарман нөсхәсендә ул «сынадым» дип дөрес теркәлгән. «Сынадым» сүзе бүтән күчермәләрдә дә (Югары Курса, Олы Мәңгәр, Уразай, Ижевск, Урта Шөн) үзгәрешсез язылган.

23. 224 нче биттәге 730 нчы бәйттә:

Кем мөбарәк Урдуга барсам үзем
Худның котлуг йөзүн күрсә күзем,

– дип бирелгән.

Абилов 1997 елгы тәнкыйди текстка нигез итеп алган СПб-1 кулъязмасының 66а кәгазендә хаталы итеп «хунның» рәвешендә теркәлгән сүзнең дөресе – башка күчермәләрдә (Югары Курса,

Ижевск, Урта Шөн, Сарман) «ханның» дип язылган. Ш.Абилов аңа карата искәрмәдә (238 биттә) «нөсхәдә: хут (балык) урынсыз» дип аңлаткан. (Гәрчә кулъязмада «хун» диелгән). Әмма Урдада «худның» (балыкның) йөзен күрү мәсьәләсе, беренчедән, үзе үк бөтенләй мантыйкка сыешлы түгел. Икенчедән, тексттагы бу юллар ханга мактау-мәдхия сүзләре белән бергә теркәлгән. 1997 елгы басманың тәрҗемә өлешендә (306 биттә) ул дөрес рәвештә «ханның» дип бирелгән.

1966 елгы басмада да (119 биттә) әлеге сүз «худ» дип бирелгән, китап ахырындагы сүзлектә мәгънәсе «үзенең» диелгән.

24. 224 биттәге 737 нче һәм 225 нче биттәге 746 нчы бәйттәге «күңел шәйхе» гыйбарәсенең «шәйхе» сүзе ялгыш «сәхи» дип басылган һәм тәрҗемә текстында да «юмарт» дип тәкъдим ителгән. Ш.Абилов өч күчермәдә дә бу сүз «шәйхе» дип язылган булуын әйткән, ләкин «шәйхе» сүзе ялгыш кулланылган, дөресе – «сәхи» булырга тиеш дип, 239 нчы биттә аңлаткан. Бу сүз әсәрнең бүтән күчермәләрендә дә «шәйхе» дип кенә язылган. Ә «күңел» – суфичылык әдәбиятында Аллаһының тәхете дип аңлатыла, «шәех» шулай ук диндарлыкның бөтен асыл сыйфатларын үзенә туплаган изге зат, юлбашчы дигәнне белдерә[7].

25. 226 нчы биттәге 757 нче бәйтнең беренче сүзе «төрки» дип ялгыш басылган, тәрҗемәдә (298 биттә) «төрле» дип дөрес бирелгән. Күчермәләрдә ул сүз «төрлүк» дип теркәлгән. 2021 елгы басмада да (254 биттә) «төрки» сүзе кабатланган.

26. 225 нче биттәге 743 нче бәйттә «Дөнйа без буланчә күрүнмәз күзенә» дигән юлдагы «буланчә» сүзе һәм аның тәрҗемәсе дөрес түгел. СПб-1 һәм Сарман күчермәләрендә ул «булҗа», «булча» рәвешләрендә язылган, бүтән кулъязмаларда да «булча» (пулча) дип теркәлгән. Билгеле булганча, «пул» – вак бакыр акча, китаптагы «без» дигән сүзнең дә дөресе – «бер». Ягъни, автор тарафыннан «дөнья бер пулча (пул хәтле дә) күренмәс күзенә» дигән мәгънә әйтелгән. Моңа охшаш чагыштыру «Төхфәи мәрдан» әсәрендә дә (шул ук басманың 42 нче битендә) бар.

---

[7] Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре: төрки-татар шигъриятендә динисуфичыл символлар, образлар, атамалар. – Казан: «Заман» нәшр., 1998. – Б. 211, 346.

27. 226 нчы биттәге 759 нчы бәйтнең икенче юлында тургайның «Бер саричә буйнын ағзыға алыб» дигәндә «саричә буйнын» өлеше ялгыш. СПб-1 күчермәсендә ул хаталырак итеп «сарытчык буйтын», Сарманныкында «сарынчак ботын» дип теркәлгән. Болардан «ботын» сүзе башка күчермәләрдә дә (Югары Курса, Уразай, Ижевск, Урта Шөн) бер төрле үк. Ә беренче сүзе Уразай нөсхәсендә – «санычка», Югары Курса белән Урта Шөннекендә «сарнычка», Ижевск кульязмасында «сарынчак» рәвешләрендә, төрлечә язылган. Әлеге сүзне Ш.Абилов (китапның 239 битендә) М.Кашгари сүзлегендә «сарычча – саранча» дип искәртсә дә, «саричә (сарыча)» дип аталган кечкенә бер кошчык дип аңлатуы дөрес түгел. Чөнки борынгы төрки телдә «сарнычка» – чикерткә дигәнне белдергән, «саранча» атамасы да шуннан килә. Димәк, автор тургайның чикерткә ботын кабып килгәнлеген тасвирлаган. Мантыйк буенча фикерләгәндә дә, бөҗәкләр белән тукланган һәм матур итеп сайравы белән дан казанган тургай һич тә ерткыч кош түгел, аның берничек тә үзеннән кечерәк бер кошны ботарлап, шуның муенын кабып, Сөләйман пәйгамбәр янына кунакка бару ихтималы була алмый. Китапның 759 битендәге тәрҗемә текстта бу юл «Саричә бер җимне авызына алып» дип, йомшаграк һәм, беренче карашка, яшерен-серлерәк итеп тәкъдим ителгән. 1966 елгы басмада да бу сүзтезмә «сарычык буйнын» (121 биттә), 2021 елгы китапта шулай ук «саричә буйнын» (254 бит) дип бирелгән. Ә 1992 елгы шигърият антологиясендә (164 биттә) «сарычык буйнын – чикерткә муйнын» дип дөрес басылган.

28. 227 нче биттәге 768 нче бәйттә «Хәзрәтеңез Дауд Сөләйман тәк ирер» һәм тәрҗемә өлешендә (299 нчы биттә) «Дауд Сөләймандагыдай...» дип тәкъдим ителгән юлда ялгышлык бар. «Дауд Сөләйман» дигән исемнәр арасында «улы» сүзе дә юклыгы, парлы исем дә түгеллеге үзе үк хата икәнлегенә ишарә итә. Китапта шулай бирелүенең төп сәбәбе – СПб-1 кульязмасындагы «Хәзрәтең дә ул Сөләйман» дигәндәге «дә ул» өлешләрен ялгыш «Дауд» дип танудан. Юкса, кульязмада ачык аңлаешлы язылган. Шулай ук Ш.Абилов кулланган Сарман нөсхәсендә дә дөрес теркәлгән. Башка күчермәләрдә дә (Югары Курса, Уразай, Ижевск, Урта Шөн) «Дауд» дип укырлык язылыш юк.

29. 227 нче биттәге 771 нче бәйттә «Қылғай ирдем мәрҗан берлә

мән доға» һәм аның 299 биттәге тәрҗемәсендәге «Мәрҗан тартып кылыр идем доганы» дигәндә «мәрҗан» сүзе СПб-1 күчермәсендәге хаталырак язылыштан алынган. Ләкин текстның «мәрҗан берлә» сүзтезмәсе урынында Сарман нөсхәсендә, шулай ук әсәр текстының бу өлеше сакланган башка кулъязмаларда (Югары Курса, Уразай, Ижевск, Урта Шөн) «җан барынча» дип, дөрес итеп теркәлгән.

30. 228 нче биттә 793 нче бәйттәге «деләгедин» сүзе СПб-1 күчермәсендә «дилләдин» дип язылганнан алынган. Ә бу сүз Сарман нөсхәсендә «дилләрдин» (әһле дилләрдин) дип, дөрес итеп теркәлгән. Югары Курса һәм Урта Шөн кулъязмаларында да нәкъ шулай.

Монда күрсәтелгәннәрдән 2, 6, 11, 23 һәм 25 саннары белән билгеләнгән пунктларда бер кызыклы нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Аларда күрсәтелгән төп текстларда хаталы язылган сүзләрнең китапның тәрҗемә өлешендә дөрес бирелүләре аптырашта калырлык. Шундый ук хәлне кереш мәкаләдә дә яздык – 275 нче бәйттәге ялгыш язылган «би-әдәб» сүзенең 262 нче биттәге тәрҗемәсендә «йөдәп» дип дөрес бирелгән. Ничек шулай икән – кыек атып туры тигәнме, әллә илаһи бер ишарә нәтиҗәсеме? Шигъри дулкында фикерләгәндә, күрәсең, күңел мәйданында бер төрле үк сүзләр пәйда була торгандыр.

***

Югарыда санап үтелгән 30 искәрмәдән башка да, 1997 елгы китапта текстологик мәсьәләләргә караган тагын дистәләрчә кимчелекләр һәм төгәлсезлекләр (кулъязмалардагы хаталарга иярүләр, ялгыш язылышлар, дөрес булмаган аңлатмалар һ.б.) бар. Китапның искәрмәләр һәм аңлатмалар өлешләрендәге саннарның шактый өлеше дөрес түгел һәм туры килми. Хаталарның барысына да тукталмадык. Андыйларның кайберләре М.Гайнетдинов, Ф.Яхин, без фәкыйрегез һ.б. авторлар тарафыннан элегрәк тә искәртелде-язылды инде.

Үзебезнең 2009 елда басылган китапта бирелгән фикерләребезнең бер өлешен монда искә алу комачау итмәс. Алар түбәндәгечә.

Тәнкыйди басмада гарәп хәрефләрен кириллицага күчергәндә турыдан-туры транслитерацияләү уңышлы килеп чыккан дип бул-

мый. Мәсәлән, борынгы кулъязмалардагы төрки-татар сүзләрендә «әлиф» хәрефе «а», «ә», «э» авазларын белдергән. Шунлыктан, поэманың кулъязма нөсхәләрендә сүз ахырында «әлиф» язылса да, аны һәр очракта «а» буларак күчерү дөрес түгел. Әйтик, «берла» дип түгел, ә «берлә» диелергә тиеш иде. Шулай ук, 289 бәйттәге «тәүәсина» сүзен дөрес рәвештә «тәүәсенә» дию, ә еш очрый торган «йәнаша» язылышын «йәнәшә» дип бирү зарур иде. Бу күренешкә капма-каршы булган, гарәп хәрефләре белән язылган һәм басылган текстлардагы сүз ахырында еш кына «а» авазын белдерү өчен «ә» (һаи рәсмия) хәрефе язылу гадәте дә исәпкә алынмаган. Мәсәлән, тәнкыйди текстта «андә», «барчә», «ачгунчә», «тазә» рәвешендә бирелгән сүзләрне «анда», «барча», «ачгунча», «таза» дип язу уңышлырак булыр иде. Бәйт ахырларындагы рифмадаш сүзләрдә «ы» һәм «е» (э) хәрефләренең «и» буларак язылышы да тотрыксыз. Әлбәттә, һәр очракта да «и»ләштерү мәгъкуль түгел. Ләкин шигъри аһәң таләбенчә үзеннән-үзе соралган урында, мәсәлән, 210 нчы бәйттәге «аны» белән «мәне» сүзләре «ани» һәм «мәни» дип бирелсә, текстологик шартларга ярашлырак булыр иде. Гарәп сүзләрендә «ләм» хәрефенең һәрвакытта да йомшак яңгырашын исәпкә алып, гарәби сүзләр ахырындагы «л» хәрефе артына нечкәлек билгесе куелганда дөресрәк укылыр иде. Югыйсә, китаптан файдаланучылар «хал», «хәммал», «фозул», «җәмал», «зөлал», «вәбал» кебек сүзләрне бозып укырга мәҗбүр. 179 нчы бәйттәге «ла-җәрәм» дигән сүзне дә «л» авазының йомшак укылышын тәэмин итәрдәй берәр хәреф белән язу отышлырак булыр иде. Югыйсә, бу гыйбарә шул ук китаптагы 439 нчы бәйттә «ля җәрәм» дип, дөрес яңгырашка якын басылган.

Әйтелгәннәргә өстәп, тагын кайбер хилафлыкларны искә алыйк. 1997 елгы басмада шагыйрь әсәрләренең хәзерге татар әдәби теленә күчермәләре «бүгенге көнгә тәрҗемә» дип аталуы дөрес үк түгел. Чөнки гарәп хәрефләрендә иске татар телендә язылган текстның хәзерге татар теленә күчерелүе – «тәрҗемә» була алмый.

Китапның 6 нчы битендә Н.Исәнбәтнең 1941 елда басылган мәкаләсе турында әйтелгәч «бер ел үткәч сугыш башлана» дигән сүзләре ялгыш. Чөнки Бөек Ватан сугышы мәкалә чыккан апрель санынннан соң ике ай үткәч башланган. Мондый ялгышлыкның

сәбәбе – Н.Исәнбәт үз мәкаләсендә әсәрнең кульязмасын 1940 нчы елның җәендә тапканлыгын язган һәм 1997 елгы китаптагы «бер ел үткәч...» дигән сүз дә шуңа нигезләнгән. Ләкин соңгы басмада 1940 елда табылганлыгы турында бөтенләй әйтелмәгән.

33 нче биттәге «моннан нәкъ 500 ел элек иҗат ителгән әсәрләр» дигән гыйбарә дә дөрес түгел. Чөнки 1997 елгы китап Мөхәммәдьярның тууына 500 ел тулу юбилее уңаеннан нәшер ителгән.

Татар әдәбияты тарихы сигезтомлыгының соңгы – 2022 елда нәшер ителгән басмасында «Йидер үтмәк...» һәм «Бу күңелдер...» дип башланган икеюллыклар[8] Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәреннән дип ялгыш күрсәтелгән. Чынлыкта, алар шул ук авторның «Төхфәи мәрдан» поэмасыннан.

***

Күрсәтелгән җитешсезлекләр әдипнең «Нуры содур» әсәрен яңадан бастырган вакытта исәпкә алынсыннар иде дип телибез. Шулай ук, без хәзерләгән шушы китапның кереш мәкаләсендәге, поэма текстындагы һәм аның искәрмәләрендәге бүтән төзәтмәләргә дә әһәмият бирелер дип өметләнәбез. Тәкъдим ителгән төзәтмәләр һәм поэманың текстологиясенә бәйле фикерләр фән даирәсендәге рәсми затлар тарафыннан «Бу фикер фәнни нигезсез түгел, шулай да әлеге әсәрне өйрәнү һәм аны әдәбият тарихында чагылдыру галимнең үз ихтыярындагы эше булып кала»[9] кебек, ярымсәер бәяләмәләр белән томаланып калмасын иде.

1997 елгы басмадагы хаталарның кайберләре таблица рәвешендә тупланды. Әйтелгәнчә, алар 2021 елгы китапта да кабатланган.

| **бит** | **бәйт** | **басылган** | **тиеш** |
|---|---|---|---|
| 170 | 2 | күтүрүр | күб торур |
| 174 | 53 | хәзретендин | хәзрәтендин |
| 175 | 65 | зинәт | зиннәт |

[8] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / төз. һәм фәнни мөх. Г.Дәүләтшин. – Яңарт. 2 нче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 2022. – Б. 128, 138.
[9] Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т. 2... – Б. 29.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 176 | 85 | бабларың | бабларын |
| 178 | 110 | нәфсәна | нәфсенә |
| 181 | 157 | йары | Бари |
| 182 | 168 | үзеңә | үзенгә |
| 188 | 247 | озақ | озаққы |
| 189 | 250 | ауға | туға |
| 194 | 323 | ғазилирдин | ғазилардин |
| 195 | 335 | хөсн | хөсне |
| 196 | 348 | пир лятиф | пире ләтыйф |
| 196 | 350 | пир хуш | пире хуш |
| 197 | 370 | хәзрәтегдин | хәзрәтендин |
| 205 | 479 | ил улусы | ил-улус |
| 207 | 505 | телне | телене |
| 208 | 516 | ошбулар | ошбулай |
| 209 | 533 | йөрүр даим үзи | йарыйур даим йөзи |
| 212 | 568 | дәмбәдем | дәмбәдәм |
| 212 | 570 | шәрмәндин | шәрмәндәдин |
| 213 | 575 | озаġи | озаġғы |
| 213 | 585 | улжқалари; әсри | улжқа, әй, әмир; әсир |
| 215 | 610 | тоттуыз | тоттуңыз |
| 216 | 625 | сафа | дога |
| 217 | 642 | ирүр мән; үшкүш | ирүрмән; үкүш |
| 218 | 648 | нә гиран | бигиран |
| 220 | 679 | сусагаи | сусагай |
| 221 | 686 | йүдаб | йөдәб |
| 223 | 720 | лу | ул |
| 223 | 721 | данйада | дөнйада |
| 224 | 739 | ғәзам | ғосса |
| 227 | 767 | хәзрәтенгә | хәзрәтеңә |

Фәнни җәмәгатьчелектә, гүяки, «Нуры содур» әсәре инде тулаем өйрәнелеп беткән, аның буенча бөтен нәтиҗәләр ясалган һәм аңа бернинди үзгәреш һәм яңалык керү ихтималы юк мәгънәсендәге күзаллау урнашкан. Әмма югарыда күрсәтелгән аерым мисаллар мәсьәләнең торышын ачык күрсәтә.

Казан ханлыгы чорының күренекле фикер иясе Мөхәммәдьяр әсәрләренең укучыларга мөмкин хәтле дөресрәк тәкъдим ителүе өчен барыбыз да җаваплы һәм ул өндәгән гаделлеккә омты-

лырга тиешбез. Шакир Абилов 1997 елгы китапта 31 нче биттә «...әсәрләрнең яңа күчермәләре табыла икән, төп нөсхәләргә ачыклаулар да булачак дип өметләнергә кирәк» дип искәрткән иде. Монда күрсәтелгән кайбер төзәтмәләр нәкъ менә яңа табылган күчермәләр нигезендә ачыкланганнарының бер өлеше инде.

# РЕЗЮМЕ

Тридцать пятая книга серии «Татарская археография» представляет собой публикацию текста поэмы «Нур-и судур» («Свет сердец») татарского поэта XVI века Мухаммедьяра, написанной в 1541 году.

Рукописи поэмы известны в настоящее время в семнадцати списках, которые хранятся в научных библиотеках Казани, Булгарской Исламской академии, С.-Петербурга, Уфы, а также в личных архивах учёных.

Публикуемый в данном издании список хранится в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан, который был передан библиотеке во время археографической экспедиции 17 июля 2024 года Л.Вахитовой, проживающей в деревне Верхняя Корса Арского района Республики Татарстан. Филиграни свидетельствуют, что бумага рукописи была изготовлена в России в 1739 году.

Среди всех известных семнадцати списков поэмы «Нур-и судур» по полноте текста эта рукопись занимает первое место, причём является единственным полным текстом из 12 единиц, хранящихся в г. Казани. В этой рукописи, также как и в других списках произведения, имеются немало текстологических особенностей, отличающих их от изданного в 1997 году критического текста поэмы, подготовленного учёным Шакиром Абиловым.

Особенно ценны неизвестные ранее четыре двустишия, имеющиеся в рукописях, а также краткие изречения из Корана и тексты хадисов, представленные в виде эпиграфов в семи главах поэмы.

Текст произведения представлен в транслитерации современной татарской графики.

В предисловии книги имеются археографические описания известных в настоящее время списков «Нур-и судур», относящихся XVII–XIX вв., также содержится информация о публикациях текста поэмы, начиная с 1941 г. по 2021 г.

Даны полное факсимиле публикуемой рукописи и фотокопии отдельных страниц других списков «Нур-и судур».

# «ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР

**(төзүчесе – археограф, текстолог Раиф Мәрданов; «Милли китап» нәшрияты)**

**Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты».** – Казан, 2008. – 88 б. – (1 нче китап). Шул ук. Икенче басма. – Казан, 2011. – 88 б.

**Түләк китабы: дастан.** – Казан, 2008. – 76 б. – (2 нче китап).

**«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар.** – Казан, 2009. – 92 б. – (3 нче китап).

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: әсәрнең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары.** – Казан, 2009. – 128 б. – (4 нче китап).

**Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... –** Казан, 2010. – 92 б. – (5 нче китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур.** – Казан, 2010. – 128 б. – (6 нчы китап).

**[Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы.** – Казан, 2011. – 68 б. – (7 нче китап).

**Сәяхәтнамәләр.** – Казан, 2011. – 84 б. – (8 нче китап).

**Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (9 нчы китап).

**Кыз хикәяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (10 нчы китап).

**Сөрген хатлары.** – Казан, 2013. – 103 б. – (11 нче китап).

**«Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр.** – Казан, 2013. – 128 б. – (12 нче китап).

**«Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре.** – Казан, 2014. – 119 б. – (13 нче китап).

**Гали авылы тарихы.** – Казан, 2014. – 164 б. – (14 нче китап).

**Тинчурин К. Каракүз: музыкаль мелодрама; Нәни абый: комедия.** – Казан, 2015. – 192 б. – (15 нче китап).

Тинчурин К. Чит илләрдә: хыялый комедия. – Казан, 2015. – 108 б. – (16 нчы китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер.** – Казан, 2016. – 124 б. – (17 нче китап).

**Сугыш һәм солдат бәетләре.** – Казан, 2016. – 264 б. – (18 нче китап).

**Дастане җайә (Мәликә китабы).** – Казан, 2017. – 148 б. – (19 нчы китап).

**Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898–1906 еллар.** – Казан, 2017. – 140 б. – (20 нче китап).

**Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар.** – Казан, 2018. – 180 б. – (21 нче китап).

**Солдат Ярулла дәфтәре: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. 1905–1906 еллар.** – Казан, 2018. – 92 б. – (22 нче китап).

**«Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар.** – Казан, 2019. – 288 б. – (23 нче китап).

**Халык җырлары: XVII–XX гасырлар.** – Казан, 2019. – 146 б. – (24 нче китап).

**Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре: Җиңүнең 75 еллыгына.** – Казан, 2020. – 276 б. – (25 нче китап).

**Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар.** – Казан, 2020. – 218 б. – (26 нчы китап).

**Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар.** – Казан, 2021. – 252 б. – (27 нче китап).

**Шәҗәрәләр.** – Казан, 2021. – 196 б. – (28 нче китап).

**«Утызынчы елларда...»: халык тормышының фаҗигале сәхифәләре.** – Казан, 2022. – 180 б. – (29 нчы китап).

**Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә.** – Казан, 2022. – 250 б. – (30 нчы китап).

**Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә.** – Казан, 2023. – 234 б. – (31 нче китап).

Килешү-хокук язмалары (XVIII–XX гасыр башы). **– Казан, 20**23. – 224 б. – (32 нче китап).

**Нигъмәтулла Солтанбәков әсәрләре.** – Казан, 2024. – 248 б. – (33 нче китап).

**Мәрданов Р. Гарәп хәрефле татар кулъязмаларының палеографик үзенчәлекләре.** – Казан, 2024. – 248 б. – (34 нче китап).

# ЭЧТӘЛЕК

«АТАМ – МӘХМҮД, ДОГАЧЫ – МӨХӘММӘДЬЯР»............ 3
Әсәрнең исеме һәм авторы ................................................ 10
Язылган елы ..................................................................... 15
Авторның мөҗавирлеге мәсьәләсе.................................... 20
«Нуры содур»ның кульязма нөсхәләре ............................ 24
Кульязмалардагы текстлар күләме................................... 69
Күчермәләрнең текстологик һәм палеографик үзенчәлекләре............................................................................ 75
Басмалар ........................................................................... 86
Әсәрдәге Коръән аятьләре һәм хәдисләр.......................... 95
Эчтәлеге............................................................................ 105
Исемнәр һәм атамалар...................................................... 114
Текстның шигъри төзелеше............................................. 116
Бу китаптагы текст үзенчәлекләре.................................. 121

НУРЫ СОДУР
Нәгъте рәсүлуллаһи саллаллаһу галәйһи вәссәлләм ...... 124
Дәр мәдхе падишаһи зәман вәли ма даимән әфзале әс-сәлятыйнез-зәмани гадел ........................................... 125
Әүвәл баб. Гадел кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур ....... 131
Әл-хикайәте гадел Нәүширван.................................. 133
Икенче баб. Рәхим-шәфкать сүзләрене бәйан кыйлур... 135
Әл-хикайәт ................................................................... 136
Өчүнче баб. Сәхавәт сүзләрене бәйан кыйлур ............... 138
Әл-хикайәт ................................................................... 139
Түртенче баб. Хәйа сүзләрене бәйан кыйлур ................. 141
Әл-хикайәт ................................................................... 144
Бишенче баб. Газат кыйлмак сүзләрене бәйан кыйлур.. 148
Әл-хикайәт ................................................................... 150
Алтынчы баб. Сабыр кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур...153
Әл-хикайәт ................................................................... 155
Йитенче баб. Вафа кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур .... 158
Әл-хикайәт ................................................................... 160

Сәкезенче баб. Сыйдық сүзләрене бәйан қыйлур .......... 162
Әл-хикайәт ........................................................................ 164
Тукузынчы баб. Самит кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур.... 167
Әл-хикайәт ........................................................................ 167
Унунчы баб. Гафу кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур...... 170
Әл-хикайәт ........................................................................ 171
Әл-хикайәт ........................................................................ 177
Әл-хикайәт ........................................................................ 185

ИСКӘРМӘЛӘР
«Нуры содур»ның бүлек атамалары ................................ 189
Бу басма өчен нигез итеп алынган Югары Курса кульъязмасының палеографик хасиятләре һәм текст бирелешенең үзенчәлекләре ............................................ 198

ЮГАРЫ КУРСА КУЛЪЯЗМАСЫНЫҢ ФАКСИМИЛЕСЕ .. 216
ЮГАРЫ КУРСА КУЛЪЯЗМАСЫНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ .... 271
СҮЗЛЕК ........................................................................ 277
«СҮЗЛӘРЕМНЕ ҮЗГӘРТМӘСЕННӘР...» ............................ 296
РЕЗЮМЕ ........................................................................ 311
«ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР ........................................................................ 312

**ПРОИЗВЕДЕНИЕ МУХАММЕДЬЯРА**
**«НУР-И СУДУР»**
*(на татарском языке)*

Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Ирина Мещанинова

Басарга кул куелды 16.05.2025. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 100 данә. Заказ №499.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86.

Подписано к печати 16.05.2025. Формат 60х84 1/16.
Тираж 100 экз. Заказ № 499.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.